ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№3 (362)
МАРТ 2022

АСЫЛ УЛЛАРНЫҢ АСЫЛ АНАЛАРЫ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская,
Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Анна Белозерова, Нурия Маннапова,
Эльмира Салахова
Фотограф: Александр Ефремов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Лайсән Һадиева
Тышлыкта: Ләйлә һәм Данат Сафиннар.
Рамил Гали фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны кучереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: О–0601
Басарга кул куелды: 11.03.2022
Басмадан чыкты: 17.03.2022

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

ЯЗЛАР КИЛӘ, ЯЗЛАР...

Дөньяда барган ыгы-зыгыга карамастан, җиһанга яз килде. Ул бер дә үзгәрмәгән. Шулай ук күңелне, җаннарны җылыта. Ул безгә өмет, шатлык дәрте бирә.

«Мин язларга гашыйк. Һәр яңа яз
Килгән саен җаным яңара.
Һәр яңа яз яңа ялкын бирә
Якты хисләр белән янарга», – дип язган шагыйрә Салисә Гәрәевага ияреп, елмаясы, күкрәк тутырып сулыйсы, тормыш ямен тоясы килә. Ышаныч арта... Яшеллек, сафлык белән бергә ил-көннәргә тынычлык, иминлек кайтыр. Барысы да яхшы булыр. Күңел төшенкелегенә бирелмичә, язның һәр көнен файдалы итеп үткәрик.

Сезнең өмет белән яшәүче редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **960 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре
бары тик ТАТАРСТАНДА

АЛЕКСАНДР БОНДАРЕНКО МИРАСЫ

Татарстан башкаласы мэры булып иң озагы украинлы Александр Бондаренко эшли. Винница өлкәсе Слободище авылында туып-үскән фронтовик-разведчик 1965 елда Казан башкарма комитеты рәисе булып эшли башлый һәм егерме ел дәвамында әлеге вазыйфаны үти. Университетның биек биналары, Яшьләр үзәге, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры, цирк, «Казан» ММҮ, «Татарстан» кунакханәсе, Танкодром, Горки, Елга аръягында беренче микрорайоннар – болар һәм башка бик күп биналар Бондаренко заманында төзелә. Ул эшләгән чакта Казан миллионлы шәһәргә әверелә һәм метро төзү планы туа. Бүгенге мэр сүзләренә караганда, хәзерге башкалада «Бондаренко башлангычларының гамәлгә ашуын күрәбез». Казанның Яңа Савин районы урамнарының берсе аның исемен йөртә.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

5. Мәхәббәт ятьмәләре
Цифрлы заманда ничек танышырга

8. Язгы чирләрнең кискенләшүе турында
Бу чыннан да шулаймы

12. Асыл улларның асыл аналары
«Татарстан» журналының махсус проекты

26. Редакция кухнясы
Ләйлә Сафинадан затлы ризык пешерү серләре

30. Ветераннарыбыз
Читек кигән заманда...

32. Биеклеккә омтылыш
Ни өчен бизнеста ханымнар уңышка ирешә

Татарстан юбилярлары

45. Демидовлар династиясе вәкиле
Тарихны язучы шәхесләр турында

62. Игелекле кешеләр авылы
Урта Девятово авылы нәрсә белән данлыклы

мәңгелек кыйммәтләр

80. Мөхлисә Бубый
Ислам тарихында беренче хатын-кыз казыя

84. Теркәлгәнбез дәфтәрләрдә,
яки Метрика язмаларында халык тарихы

90. Татар авыллары
Казакларда кемнәр яши

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

11.02

Әгъзам Гобәйдуллин, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы рәисе:

– Яңа муниципаль реформаның иң бәхәсле маддәсе – җирле үзидарәнең беренчел буыны булган авыл җирлекләрен бетерү. Шуңа күрә, законнарга үзгәрешләр керткәндә, иң мөһим көнкүреш проблемаларын хәл итәр өчен, хакимиятнең халык өчен якынлыгын гарантияләячәк чараларны алдан күзалларга кирәк.

18.02

Андрей Никитин,Түбән Новгород өлкәсе губернаторы, – Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов белән «Алабуга» махсус икътисадый зонасында очрашу вакытында:

– Татарстан бүген сәнәгать һәм мәгариф үсешенең иң алдынгы юнәлешләрендә әйдәп бара. Иң яхшылардан нәрсәдер өйрәнә, алар тәҗрибәсенә таяна, алар белән бергә эшли, һәм бергә алга бара алуыбыз безнең өчен бик мөһим. Махсус икътисадый зонаны формалаштырганда, без Татарстан идея һәм үрнәкләрен исәпкә алачакбыз.



ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

17.02

Кэнго Кума, япон архитекторы, Г.Камал театры өчен яңа бина проекты авторларыннан берсе:

– Безнең концепциядә елның төрле фасылларын һәм, әлбәттә, боз капланган күлле һәм ап-ак карлы кышны чагылдыру мөһим иде. Боз кристалларына хас очлылык, омтылучанлык, векторлык – татар халкының мөһим асылы. Безгә сөйләгәннәрдән аңлашылганча, ук рәвеше татар мәдәниятенә хас билгеләрдән берсе.

Фото: ©Рамил Гали, philologist.livejournal.com/11534050, decor.design

Игелекле эшләр

Акыллы гамәлләр/

Мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Мәгълүмати технологияләр мәхәббәткә **НИЧЕК** йогынты ясый

Язгы чирләрнең кискенләшүеннән **НИЧЕК** котылырга

НИ ӨЧЕН әни һәрвакыт хаклы

ЯЗ, ЯЗ, ЯЗ КИЛӘ...

Кояш көлеп карый безгә,

Күзләр чагыла.

Елгалардан бозлар ага

Диңгез ягына...

Елның иң гүзәл фасылларының берсе – яз җитә. Кояшның юмарт нурлары җирне җылыта... Әмма кеше, шул нурларда иркәләнсә дә, кошларның дәртле җырын тыңласа да, нигәдер язгы «плюслар» белән рухланмый, бармакларын бөгә-бөгә «минусларны» саный:

Язгы чирләрнең кискенләшүе... – Хәзер массакүләм психоз башланачак...

Тагын шул мәхәббәт... – Үбешү-кочаклашулар, карап торуы ук ачуны китерә...

Авазлар һәм исләр... – Өй кыегында март мәчеләре мыраулый...

Бер тынычлык юк...

«ТАТАРСТАН» пессимистларга ЯРДӘМГӘ КИЛӘ һәм язгы тормыш белән яшәргә комачаулый торган мифларны тарата. Яз елга бер генә мәртәбә килә, шуңа күрә аның исен, җылысын тоеп, авазларын ишетеп яшик.

Журналыбызның март саны МӘХӘББӘТ, ЯЗГЫ ЧИРЛӘРНЕҢ КИСКЕНЛӘШҮЕ, асыл ир-атлар тәрбияләүче АСЫЛ ХАНЫМНАР, кырыс ХАТЫН-КЫЗ БИЗНЕСЫ һәм башкалар турында сөйли.



ЦИФРЛЫ ЧОРДА МӘХӘББӘТ. КӨЧЛЕРӘГЕ ҖИҢӘЧӘК

Олеся Бондаревская

Мәгълүмати технологияләр безнең мөнәсәбәтләргә нинди йогынты ясый

«Костюм, галстук. Бигрәк чиктән тыш инде бусы...», – дип уйлап куйды 27 яшьлек Казан кызы Алина, «Тиндер»да үзен ошатып тамга куйган егетнең фотосына төбәлеп. Кандидат бик һавалы тоелса да, бер фотосына лайк куярга булды.

Егет шактый тиз җавап язды һәм очрашырга тәкъдим итте. Алина ризалашты. «Нишләрбез соң?» – дигән соравына егет: «Шахмат уйнарбыз», – дип җаваплады. Икесе дә анкеталарында шахматны хоббилары итеп күрсәткән иде. Чыннан да, беренче ике очрашуларында Алина белән Андрей (егетне шулай атыйк) Казандагы антикафеларның берсендә шахмат уйнадылар. Берберсен ошаттылар, бер елдан соң өйләнештеләр дә. Дөрес, бераздан проблемалар башланды. Аерылыштылар.

– Аерылышу сәбәбе безнең мобиль кушымта аша танышуыбызда түгелдер, дип уйлыйм. Әгәр безне дусларыбыз таныштырган булса да, Андрейның миңа ошамаган сыйфатлары шундук күзгә бәрелмәс иде, – ди Алина. – Минем кеше булып чыкмады ул.

КҮПЙӨЗЛЕ МИН

Узган ел РБК порталы Superjob компаниясе тикшеренүе нәтиҗәләрен бастырган иде. Иң еш танышу урыннарына багышланган сораштыруда 2 мең россияле катнашкан. Тикшеренү мәгъ-

Фото: depozitphotos.com

луматлары буенча, хатын-кызлар Интернетта (19%) эштәгегә (17%) караганда ешрак таныша, ир-егетләр исә киресенчә (12% һәм 11%) икән. Сораштырылганнарның 11%ы үзенең булачак парын – урамда, 7%ы дуслары компаниясендә очраткан, респондентларның 4%ы – мәктәптән, 4%ы университеттан бирле таныш булган, тагын 4%ы кафе яки ресторанда танышкан. Бөтен аралашулар кебек үк, «бер күргә гашыйк булу» да онлайнга күчә бара. Офлайн-танышулар нигә кими икән соң?

– Бервакыт үзем белән бер компаниядә эшләүче һәм хәтта офиста да очраткалаган бер егет танышу сайтында мине ошатуын белдереп тамга куйды. Мин моңа гаҗәпләндем һәм аның ни өчен яныма килеп танышмавын сорадым. Ул исә «Тиндер»дагы һәм эштәге кызның бер үк мин икәнен аңламаган да булып чыкты, – дип сөйли Алина. – Эштә мин – директор урынбасары, һәм кайбер егетләр минем яныма килергә дә кыймый. Бу егет исә мине бөтенләй кияүдә һәм балаларым бар дип уйлаган, чөнки минем «Инстаграм»дагы сәхифәмдә бертуганымның балалары белән төшкән фотоларны күргән.

Алина әйтүенчә, «мэтч»лар (инглизчәдән «тәңгәллек» дип тәрҗемә ителә) партнерыннан нәрсә көтүне төгәл күрсәткәндә аеруча нәтиҗәле эшли. Хәзер кыз инде берничә ай буе бер егет белән дуслашып йөри. Аның «Тиндер» һәм «Инстаграм»дагы профильләрен өйрәнеп, Алина үзе беренче булып сүз кушкан.

КҮП БЕЛДЕРҮЛӘРДӘ «ИНТИМ ТӘКЪДИМ ИТМӘСКӘ!» ДИП ЯЗЫЛГАН, ЯГЪНИ АЛАРНЫҢ АВТОРЛАРЫ СӨЙЛӘШЕРГӘ ГЕНӘ ТЕЛИ.
Сәгатенә 150–500 сумга, мәсәлән, воцапта, нинди дә булса темага аралашу тәкъдим ителә. Илебездәге дуслык һәм бер-береңә ярдәм итү кебек идеалларда тәрбияләнгән кешеләргә мондый күренеш гайре табигый тоелырга мөмкин. Әмма хәзер бу күңелен тынычландыруга мохтаҗларга ярдәм итү өчен менә дигән чара булып тора.

– Кушымта булмаса, без берничек тә таныша алмас идек, – ди Алина. Хәзер аңа 32 яшь, янәшәсендә шундый ышанычлы кеше булуына ул бик шат. Кыз фикеренчә, таныштыру платформаларында мондый яшьләр шактый.

– Мин үз һөнәре, торагы булган, сәяхәт итәргә яраткан берничә егет белән биредә танышып, очраштым. Чынбарлыкта үз парын эзләүгә аларның вакыты юк. Мин аларның кайберләрен «Инстаграм»да күзәтеп барам, һәм әле һаман ялгыз булуларын күрәм, – ди Алина.

Үзе әйтүенчә, әлеге очрашуларда кызның әле бер тапкыр да нинди дә хәвефле хәлләргә юлыкканы юк икән.

ФИЛЬТР

– Онлайн-аралашу – нинди дә бер фильтр ул. Хәбәрләрнең ешлыгы, стиле, риторикасы буенча нинди дә нәтиҗәләр ясарга һәм әлеге кеше белән аралашуны дәвам итәргәме-юкмы икәнне билгеләргә була, – ди Казаннан психолог Ирина Лапина. – Онлайн-элемтә офлайн-стадиягә күчкәндә үкенмәслек булсын өчен, башта «Кем мин?», «Нәрсә кирәк миңа?», «Бу кеше белән аралашу нигә кирәк миңа?» кебек сорауларга гадел җавап табу мөһим.

Психолог анкетаны мөмкин кадәр төгәлрәк, гаделрәк тутырырга киңәш итә.

– Әгәр сезнең билгеле бер төрле шартларыгыз бар икән, аларны шундук күрсәтергә кирәк. Бу сезне кирәкмәгән элемтәләрдән һәм вакытыгызны бушка әрәм итүдән саклаячак, – ди Ирина Лапина. – Кайвакыт безгә, үзебездә булмаган нинди дә сыйфатлар һәм мавыгуларны ялганлап язып куйсак, алар бездә пәйда булыр кебек тоела. Юк, пәйда булмаячак. Ә мимикрия бик күп ресурслар таләп итә. Ялганга корылган мондый аралашуның нигә кирәге бар соң?

ГАИЛӘ КОРУ СӘНГАТЕ

Социаль статус, психотип, дөньяга караш һәм башка сыйфатламалар – Казанда туйлар алып баручы Марсель һәм аның хатыны Энҗе оештырган «Сине көттем» тибындагы проектта катнашырга теләүчеләр онлайн анкетада боларның барысын да күрсәтергә тиеш. Яңа никахлашучылар белән күпьеллык аралашу үзләре инде 12 ел бәхетле гаиләдә яшәүче ир белән хатынны башкаларга да булышуга этәргән. Нәкъ менә шуңа күрә аларның анкетасында берничә дистә пункт тутырылырга, шулай ук кандидатларның фотолары һәм видеопрезентациясе куелырга тиеш. Ир белән хатын егет-кызларның анкеталарын җентекләп тикшерә һәм әлеге дә баягы «мэтч»ларны компьютерсыз да табарга тырыша.

Бер пар, Гүзәл һәм Ильяс, партнерның таләп ителгән яше буенча тәңгәл килмәгән, әмма Марсель белән Энҗе аларны читтән торып кына барыбер таныштырып караган. Уңышлы булып чыккан. Әмма тулыканлы танышуга әле бик ерак булган. Башта «мэтч»лар җитди сынаулар – гаилә тормышы психологиясе буенча семинарлар, мөнәсәбәтләрне кору буенча осталык дәресләре, Telegram каналында видеоэлемтә буенча психологик тәңгәллеккә тестлар үткән. Барлык бу этапларны уңышлы үткәннән соң гына яшьләргә үзара аралашу мөмкинлеге бирелгән. Марсельнең иманы камил: мондый сынауларны узган кандидатлар арасындагы мөнәсәбәтләр күпкә ныграк булачак.

– Соңгы елларда илебездә 100 никахка 70 аерылышу туры килә. Без әлеге статистиканы бераз гына булса да үзгәртергә телибез. Еш кына кешеләр эндорфиннар тәэсирендә бергә булырга карар кыла һәм көнкүрештә, социаль статуста, тормышка караште аерымлыкларга игътибар бирми, шунлыктан никах таркала. Аңлап якын



килү исә әлеге хәвефләрне киметергә булыша, – ди Марсель. – Без рухлары, күңеле бер-берсенә якын кешеләрне таныштырабыз. Мөнәсәбәтләрне ничек саклап калу турында сорауларга җаваплар исә психологиядә дә, традицион диннәрдә дә (безнең очракта бу ислам) бар. Без боларның барысыннан да файдаланабыз.

Берничә пардан аермалы буларак, Гүзәл белән Ильяс барлык сынауларны уңышлы үткән һәм өйләнешкән. Әлеге уңыштан рухланып, Марсель белән Энҗе үз проектларын алга таба да үстерергә җыена, әмма камилрәк алгоритм табарга – «мэтч»ларның күбрәк булуына ирешергә тели.

– Без кешеләрнең гаилә корырга теләвен күрәбез. Безгә авылда үз бизнесы булган тырыш егетләр дә, башка шәһәрләрдән карьера турында хыялланмаган хатын-кызлар белән танышырга теләүче саллы ир-атлар да мөрәҗәгать итә. Балалы хатыннар да үз тиңен табудан өметен өзми. Барысына да булышасы, һәркайсын бәхетле итәсе килә, – ди Марсель.

ИНТИМ ТӘКЪДИМ ИТМӘСКӘ

Марсель кебек, заманча технологияләр ярдәмендә замандашларын ялгызлыктан коткарырга омтылучылар шактый. Интернетта яучыларның игъланнары да, «бер сәгатьлек дус», «авыр хәлдә әңгәмәдәш» кебек тәкъдимнәр дә байтак. Күп белдерүләрдә «Интим тәкъдим итмәскә!» дип язылган, ягъни аларның авторлары сөйләшергә генә тели. Сәгатенә 150–500 сумга, мәсәлән, «Воцап»та, нинди дә булса темага аралашу тәкъдим ителә. Илебездәге дуслык һәм бер-береңә ярдәм итү кебек идеалларда тәрбияләнгән кешеләргә мондый күренеш гайре табигый тоелырга мөмкин. Әмма хәзер бу күңелен тынычландыруга мохтаҗларга ярдәм итү өчен менә дигән чара булып тора.

– Без хәзер еш кына дусларны мәнфәгатьләребез буенча түгел, бәлки нинди дә булса проблеманы хәл иткәндә файдалы булуын истә тотып сайлыйбыз. Әмма мин, мәсәлән, бизнестагы дустыма зарлана алмыйм, ул мине бөтенләй аңламаячак. Кайчандыр институтта бергә укыган дус кызыма да зарларымны сөйли алмыйм. Чөнки без инде күпме ел рәтләп аралашмыйбыз да, һәм минем аны үз проблемаларым белән борчырга әхлакый хокукым юк. Минем аның белән һәм башкалар белән бары тик аралашу өчен генә аралашасым килә, тик андый мөмкинлегем юк, – ди Ирина Лапина. – Мин үземнең бөтен ресурсларымны гаилә иминлеген саклауга сарыф итәм, яхшы әни, хатын, кыз, профессионал, эшкуар булырга тырышам. Әгәр минем ихтыяҗым булса, мондый коммерцияле үзара мөнәсәбәтләр миңа идеаль туры килер иде. Мин сәгатенә 300 яки 500 сум түлим дә, рәхәтләнеп зарымны түгәм, әңгәмәдәшемне исә тыңларга да кирәкми.

Әмма безнең рухи аралашуда шундый кыенлыклар туган икән, бәлки партнер-андроидлар булдырыргадыр? Кеше кебек хисләрен белдерә алучы нейрочелтәр төзү эшләре инде күп еллардан бирле алып барыла. Бу юнәлештә бигрәк тә Sonantic проекты уңышлы эшли. Аларның алгоритмы тавышның төрле интонацияләрен, шул исәптән флирт вакытындагысын да, кабатларга өйрәнгән инде.

ТЕРЕ АРАЛАШУСЫЗ СУЛАБЫЗ

Ирина Лапина фикеренчә, мондый аралашуның нәтиҗәсе максатка бәйле. Әгәр бу вакытлы алмаш, әйтик, сез Антарктидага киттегез һәм аннан чын партнерыгызга шылтырата һәм сөйләшә алмыйсыз икән, бу очракта чат-бот яки хәләлегез ролен үтәүче нейрочелтәр файда гына китерер. Әмма инде кеше мондый алыштыргычлардан даими файдалана икән, бу аны һәлак итәчәк.

– Беренчедән, ниндидер моментта ул үз-үзе белән сөйләшә башлый – роботтан үзе ишетергә теләгән сүзләрне әйттермәкче була. Шунлыктан идеаль коммуникация иллюзиясе туа, һәм бу куркыныч – мондый коммуникация чынбарлыкта мөмкин түгел. Икенчедән, кеше үзе дә сизмичә үзен алгоритм кебек тота башлый. Димәк, аңа тере әңгәмәдәш белән аралашу кыенлаша бара, – ди психолог. – Ә тере аралашудан башка без сулабыз. Танышу өчен яхшы булган онлайн-формат та мөнәсәбәтләр өчен нәкъ шул сәбәпле начар. Без элемтәнең әллә нинди алдынгы технологияләренә ия булсак та, психикабыз, миебез һәм тәнебез шулай яратылган ки – үзен тере итеп тояр өчен, кешегә янәшәсендә башка тере кеше булу зарур.

ТЕРЕ АРАЛАШУДАН БАШКА БЕЗ СУЛАБЫЗ. ТАНЫШУ ӨЧЕН ЯХШЫ БУЛГАН ОНЛАЙН-ФОРМАТ ТА МӨНӘСӘБӘТЛӘР ӨЧЕН НӘКЪ ШУЛ СӘБӘПЛЕ НАЧАР. Без элемтәнең әллә нинди алдынгы технологияләренә ия булсак та, психикабыз, миебез һәм тәнебез шулай яратылган ки – үзен тере итеп тояр өчен, кешегә янәшәсендә башка тере кеше булу зарур.

ЯЗ ҖИТКӘЧ, ЧИР КӨЧӘЯ

Анна Белозёрова

Казандагы сәүдә үзәкләренең берсенә килгән ир-ат, ишек төбендәге сакчының qr-код күрсәтү таләбен ишетүгә, ярсып китә, тыңламыйча, сәүдә залының эчке ягына йөгерә. Сакчы аны куып җитә алмый. Кайсыдыр бер мизгелдә ул, кул селтәп, бу ниятеннән баш тарта: янәсе, нишләтәсең инде ул тилене... «Язын чирләре көчәя аларның!» — дип аңлата сакчы керергә чиратта торучыларга.

Кар әле эри генә башлады, без инде тирә-ягыбыздагы һәр әдәпсез гамәлгә, тәртипсезлеккә сәбәп табып, аны «язгы феномен» дип аклый башладык. Ә чынлыкта нәрсә соң ул «язгы феномен», ул бармы?

БАРЫСЫНА ДА ҺАВА ТОРЫШЫ ГАЕПЛЕМЕ

Күптән түгел генә булган хәл. Казан янындагы Столбище авылы. Шәхси йортта яшәүче берәү үзенең коймасы янына куелган машинаны кар белән күмеп маташа. Иренми – түбәсенә хәтле диярлек өеп куя!

– Монда кемдер машинасын куйган, минем йорт каршына! Мин бу тирәне үзем өчен кардан чистарттым, ә ул куйган да киткән. Акылы алтын икән! Менә хәзер аны күмеп куям, – ди ул, барысын да үз смартфонына төшереп.

Тагын бер-ике көннән матбугатта башка бер вакыйга турында шаулаштылар Татарстан башкаласында машина кую урыны өчен чын-чынлап сугышып киткәннәр. Араларыннан берсе хәтта күсәк тә әләктереп чыккан. Бәхеткә, кызып киткән автомобильчеләрне шул тирәдән узып баручылар аера алган.

«Язгы-көзге чир кискенләшү!» – дип нәтиҗә ясый комментаторлар. Чыннан да, язын психик авырулар арта, көчәя дип сөйлиләр. Алиса турында экияттәге Чешир мәчесе әйткәнчә: «Без барыбыз да бераз тилергән». Тик белгечләр бу хакта ни дия соң?

Психик тайпылышларның яз көне көчәюе турында уйдырманы җәмгыятьтә иң киң таралган ялгыш фикерләрнең берсе дип саный **Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсенең амбулатория-сырхауханә бүлеге мөдире Ольга Башмакова.**

– Бу нәрсә белән бәйле соң? Минемчә, җавапны төрле психик авыруларның тасвирламасында булган Пирогов симптомында табарга була. Бу симптом кешенең һава торышына артык сизгерлеген аңлата. Һава шартлары сизелерлек алмашынганда, кеше үз гәүдәсендә төрле күңелсез үзгәрешләр тоя башлый. Баш авыртулары көчәю, кәефнең кинәт үзгәрүе, кайчагында йокысызлык – һава торышына бәйлелек үзен шул рәвешле сиздерергә мөмкин. Әлеге күренеш психиатриядә генә түгел, гомуми медицинада да билгеләп үтелә. Миңа синоптиклар фаразы да, барометр да кирәкми, буыннарым, йөрәк тибешем, артериаль

Фото: ua.depositphotos.com

кан басымым уйнавы белән һава торышын үзем фаразлый алам, дип турыдан-туры әйтә торган пациентлар бар.

Димәк, әлеге дә баягы «чир көчәю» дигән нәрсәне һава торышының сизелерлек үзгәрешләре – температура сикерешләре, атмосфера басымы уйнавы китереп чыгара... Чыннан да, язын без мондый күренешләрне еш күзәтә алабыз. Хәер, андый көннәр көзен дә күп, кайчак кышын-җәен дә булыштыра.

ТРОЛЛЬЛӘР ҺӨҖҮМ ИТӘ

Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге соңгы биш елда рунетта агрессия дәрәҗәсе үзгәргәнме-юкмы икәнен ачыкларга булган. Чыннан да, интернеттан файдаланучыларның 42 проценты кимсетүле постлар һәм шәрехләмәләрнең саны артуын билгеләп үтә. Сораштыруда катнашкан кешеләр дорфалыкка шаһит кына булып калмыйча, үзләре дә троллингтан һәм мыскыллаулардан интеккәнлекләрен, җенесләре, яшьләре яки карашларына бәйле рәвештә кимсетелгәнлекләрен сөйләгән. Хәтта янау-куркыту очракларын да искә алганнар.

Чынбарлыктагы тормышта без агрессиянең ел фасылына бәйлелеген раслаган дәлилләр тапмадык, бәлки, андый күренешләр онлайн мохиттә күзәтеләдер?

– Юк, мин мондый фикерне раслый алмамдыр, – дип җавап бирә бу сорауга **«Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең гаммәви мәгълүмат чаралары департаменты җитәкчесе Арсений Соколов.** – Социаль челтәрләр белән инде шактый вакыт эшләсәк тә, комментарийларда сезонлы агрессивлыкны беркайчан да сизгәнебез юк. Безнең күзәтүләр буенча, барысы да нинди мәгълүмат тәкъдим ителүгә бәйле. Шул ук вакытта бәйрәмнәр, күңелле вакыйгалар алдыннан ачу-нәфрәт градусы һәрвакыт кими. Монысы – факт.

Эксперт сүзләренчә, челтәрдәге агрессия дәрәҗәсенә җәмгыятьтәге гомуми социаль киеренкелек йогынты ясый. Андый киеренкелек көчлерәк булган саен, тискәре, усал комментарийлар арта бара. Хәер, әлеге аралашу стиле хупланмаса да, моны тыймый торган интернет-сәхифәләр җитәрлек.

– Модераторлары микроклимат турында кайгыртмаган, ягъни мыскыллы, кимсетүле язмалар

Ачу-усаллык иң тиз тарала торган хис булып тора һәм, чылбыр реакциясе рәвешендә кабынып, бик тиз көчәеп китә ала. Шулай булгач, челтәрдә аралашу гигиенасын саклау һәм үз тирәңдә нинди мохит формалашуын күздән ычкындырмау мөһим.



бетерелми, кешеләр бер-берсе белән әйткәләшә торган төркемнәрдә агрессив тон нормага әверелә диярлек. Һәм менә бу очракта инде интернетта үз-үзеңне әнә шулай ямьсез тоту гадәте формалашуы турында сүз алып барырга була.

Сүз уңаеннан, «Фейсбук» социаль челтәреннән файдаланучы 700 мең кеше катнашында Корнель университеты галимнәре тарафыннан үткәрелгән эксперимент челтәрдәге эмоцияләрнең «йогышлы» булуын күрсәткән. Бу очракта ачу-нәфрәт тә искәрмә түгел. Моннан тыш, башка тикшеренүләрнең нәтиҗәләре шуны исбатлаган: ачу-усаллык иң тиз тарала торган хис булып тора һәм, чылбыр реакциясе рәвешендә кабынып, бик тиз көчәеп китә ала. Шулай булгач, челтәрдә аралашу гигиенасын саклау һәм үз тирәңдә нинди мохит формалашуын күздән ычкындырмау мөһим. Карл Маркс сүзләре белән әйткәндә, вөҗүд аңның нигезендә ята, ә интернет чоры башлану бу кагыйдәне бер дә үзгәртмәде.

Интернетта явызлыктан, кызып китүдән ничек сакланырга? Сүз безгә карата әйтелгән усал сүзләр турында гына бармый, үзебезгә ничек бу процесска кушылмаска, тыныч калырга соң? Арсений Соколов бу мәсьәләне чишү өчен төгәл алгоритм тәкъдим итә.

– Иң мөһиме – сез интернетка багышланырга тиешле вакыт күләмен алдан билгеләп куярга тиеш. Смартфоныгызга вакытны чикли торган махсус кушымталар урнаштырыгыз. Үзконтроль турында онытмагыз. Теге яки бу интернет-ресурска күпме вакыт бирәчәгегезне уйлап, билгеләп куегыз. Радикаль характердагы күңел ачу контентын артык куллану, мәсәлән, гел мемнар карау рухи деградациягә һәм эмоциональ тотрыксызлыкка китерә. Мин ресурсларның төрле эчтәлекле булуы яклы.

ТЫНЫЧСЫЗ КЕШЕ

Соңгы берничә елда россиялеләр әйләнә-тирәдәгеләр арасында ресентиментның (дошманлык хисләренең) көчәюен ешрак сизә башлаган. «Левада үзәге» экспертлары әнә шундый нәтиҗә ясый. Тикшеренүләр берничә ел дәвамында алып барылган. Нәтиҗәләр түбәндәгечә: 2017 елда тирә-якта агрессия күренешләренең үсүе турында респондентларның 37%ы телгә алса, 2021 елда бу сан 57% тәшкил итә. Кешеләр депрессив астеник карашларның да бераз ешаюын сизә башлаган: 2017 елда – 40%, 2020 елда – 54%, 2021 елда – 48%.

– Күпләрне пандемия «аяктан екты», кайберәүләр үзизоляциядән һаман чыга алмый, – дип сөйли рус телле «Аноним депрессивлар» (ДА) төркеме координаторларыннан берсе Алексей Матюхин.

Аның күзәтүенчә, кешеләр арасында борчылу, хәвефләнү хисләренең көчәю сәбәбе, әлбәттә, ел фасылына түгел, ә бәлки эшсез калу, якын кешеләр белән мөнәсәбәтләр бозылу, туганнар яки дуслар тарафыннан яклау тапмау кебек социаль факторларга бәйле. Болар барысы да тормыштан канәгатьсезлеккә һәм аның мәгънәсен югалтуга китерә.

ДА берләшмәсе кешедәге хәвефләнү-борчылуларга каршы көрәшергә ничек булыша дигән сорауга Алексей: «Төркемдәшләр ярдәме, «12 адым» программасы нигезендә эш алып бару һәм медикаментлар белән дәвалау», – дип җавап бирә. Сүз уңаеннан, ДАның «ВКонтакте»дагы төркемендә берничә мең кеше исәпләнә, чынлыкта анда катнашучылар саны күбрәк, әлбәттә. Төркем әгъзалары арасында Татарстан кешеләре дә бар, алар да онлайн уза торган әңгәмәләрдә ярдәм алу мөмкинлегенә ия.

– Әлбәттә, җәмгыятьтә, кеше арасында яшәп, стресс йогынтысына эләкмәү мөмкин түгел, – ди **Ольга Башмакова**. – Әмма стресс тәэсирләренә тискәре реакцияңне мөстәкыйль рәвештә киметергә өйрәнергә була.

Мондый тозакка эләкмәс өчен, белгеч стресс тәэсирләре исемлеген кыйммәтләре һәм әһәмияте буенча язып чыгарга киңәш итә. Аларны бәяләргә һәм чынлыкта нинди хәл килеп туганын аңларга кирәк. Стресс реакцияләренең, астеник халәтнең көчәюенә бигрәк тә вакыт җитмәү, билгеле бер вакыт аралыгында башкару мөмкин булмаган эшләрнең күплеге йогынты ясый. Мондый хәлне булдырмас өчен, үз вакытыңны һәм эшлисе эшләрне төгәл планлаштыру зарур. Әгәр артык күп эшнең берсеннән булса да котылу мөмкинлеге бар икән, бу форсаттан файдалану мәслихәт.

– Үзеңә көч-дәрман бирә торган шөгыльләрне һәм активлыкны ачыклагыз, – дип киңәш бирә психолог. – Сүз ләззәт, җиңеллек китерә һәм игътибарны стресс йогынтысыннан уңайлы һәм рәхәт халәткә күчерә ала торган нәрсәләр турында бара. Бу исә спорт, төрле кул эшләре белән шөгыльләнү, табигатьтә ял итү, гаилә һәм дуслар белән аралашу, китап уку булырга мөмкин...

СТРЕССТАН КАЧЫГЫЗ!

Үзеңдәге хәвефләнү-борчылу хисен һәм агрессивлык дәрәҗәсен киметү мөмкин, дип раслый Ольга Башмакова. Моның өчен нәрсә эшләргә кирәк?



1. Сезнең өчен хәзерге вакытта нәрсәнең иң мөһим һәм иң кыйммәтле икәнен күңелдән анык билгеләргә.

2. Үз алдыңа ирешә алырдай, төгәл максатлар гына куярга. Үзеңә аңлы рәвештә артык эшләр һәм җаваплылык йөкләмәскә: «Мин үти алырдай эшләрне генә башкарам – мөмкинлекләремә туры килмәгән нәрсәләргә алынмыйм».

3. Йокыны киметүдән тыелырга. Йокы – нерв системасын торгыза торган бик көчле фактор. Физиологик яктан иң яхшы һәм дөрес йокы – кичке сәгать ун белән төн уртасына кадәр аралыкта. Шушы вакытта йокларга ятыгыз һәм йокының идеаль озынлыгына омтылыгыз – 8 сәгать йокларга тырышыгыз.

4. Яз фасылы өчен хас күренеш – аксым һәм витаминнар кытлыгын булдырмаска. Туклану рационын баетыгыз, сәламәтлеккә бәйле рәвештә ниндидер тыю юк икән, аңа синтетик витаминнар да өстәгез.

5. Стресс гаиләдә, җәмгыятьтә нормаль тормыш алып барырга комачауларлык дәрәҗәгә җиткән очракта, психик саулык белгеченә мөрәҗәгать итәргә кирәк.



АСЫЛ УЛЛАРНЫҢ АСЫЛ АНАЛАРЫ



1 ӘНИ ҺӘРВАКЫТ ХАКЛЫ...

2 МИН КАЙЧАН ЯЛГЫШКАНМЫН...

3 АНА ҺӘМ УЛНЫҢ ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛЕ...

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ ИҢ БУЛДЫКЛЫ УЛЛАРЫН ТӘРБИЯЛӘГӘН ҺӘМ ТӘРБИЯЛӘҮЧЕ, ҮСТЕРГӘН ҺӘМ ҮСТЕРҮЧЕ ИҢ УҢГАН АНАЛАРЫН БЕРЛӘШТЕРГӘН МАХСУС ПРОЕКТЫ.
БАРЛЫК ГЕРОЙЛАРЫБЫЗ ДА ӨЧ СОРАУГА ҖАВАП БИРДЕ, АЛАРНЫҢ ҖАВАБЫ ТАТАРСТАННЫҢ АСЫЛ ИР ЗАТЛАРЫН ХАТЫН-КЫЗЛАРЧА НИЧЕК ДӨРЕС ТӘРБИЯЛӘРГӘ КИРӘКЛЕГЕН КҮРСӘТӘ.

Фото гаилә архивыннан

ГӨЛНАРА, ТИМУР ҺӘМ ИНИЛ ГАБДРАХМАНОВЛАР

ГӨЛНАРА ГАБДРАХМАНОВА, ТР АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ РӘИСЕ, ҺӘМ УЛЛАРЫ ТИМУР БЕЛӘН ИНИЛ.

1

Инил:

– Беркайчан да бирешергә ярамый, дип өйрәтеп, **ӘНИЕМ ХАКЛЫ БУЛГАН,** дип саныйм. Тормышта сыйфатлы яхшы белем алу кирәклегендә дә, теләсә нинди хәлләрдә дә кеше булып калырга өндәгәндә дә хаклы ул.

Тимур:

– МИН ҺӘРВАКЫТ ӘНИЕМ КИҢӘШЛӘРЕНӘ КОЛАК САЛАМ. Теләсә кайсы мәсьәләне аның белән уртага салып тикшерәм. Һәм, минем фикерне исәпкә алып, карарны бергәләп кабул итәбез.

2

– ҮКЕНЕРЛЕК МИЗГЕЛЛӘР БУЛМАДЫ, ДИП УЙЛЫЙМ. Мин педагог, бәлки, шуңа да минем барлык тәрбия чараларым уйланган булгандыр... Хәтта нинди дер җәза биргәндә дә, улларыма мин ни өчен икәнен аңлата идем. Һәм хәзер алар безгә – әти-әниләренә – моның өчен рәхмәт әйтә. Мактанасым килми, әмма без аларны тәрбияләү белән җитди шөгыльләндек. Түгәрәкләргә һәм секцияләргә йөртеп кенә калмадык, кайдадыр үзебезнең үрнәк белән, кайдадыр сүзебез белән тәрбияләдек. Күптән түгел ресторанда 23 февральне бәйрәм иттек. Тормышта нәрсәне үзгәртер идек, шул турыда сөйләштек... Барлык сәфәрләребезне, балык тотуларны, төнге чәй эчүләрне, укуларын, кино-концертларга бергәләп йөрүләрне искә төшердек... Һәм барыбыз да бер фикергә килдек – мөмкин булса, бернәрсәне дә үзгәртмичә, тагын бер тапкыр нәкъ шулай яшәр идек.

3

ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛ...



– ...Улларымны тәүге тапкыр кулыма алган мизгелләр – иң бәхетлесе. **Үзеңнең Әни булуыңны аңлау иң зур бәхет ул!** Минем өчен улларым һәрвакыт беренче урында. Минем теләсә кайчан ярдәм итәсен алар яхшы белә. Алар минем алтыннарым.

Инил:

– ...Бәхетле мизгелләрем балачак белән бәйле: **әни белән Казанга аквапаркка, аттракционнар паркына килүләребез, шәһәр буйлап йөрүләребез...**

Тимур:

– ...Миңа операция ясаганда, **әнинең ишек артында уйлары, күңеле белән миңа көч биреп торуын сизеп яттым.** Наркоздан соң беренче аны күрдем һәм тынычландым. Минем ӘНИЕМ!

PRESSA

ГӨЛЧӘЧӘК ШӘЙХЕТДИНОВА ҺӘМ СӘЙЯР СИРАҖЕТДИНОВ

ГӨЛЧӘЧӘК ШӘЙХЕТДИНОВА, «ЛИЗИНГСТРОЙМАШ ТК» ҖЧҖ БАШ БУХГАЛТЕРЫ УРЫНБАСАРЫ, ҺӘМ СӘЙЯР СИРАҖЕТДИНОВ, ТАБИБ ТРАВМАТОЛОГ-ОРТОПЕД, ТӨБӘКАРА КЛИНИКА-ДИАГНОСТИКА ҮЗӘГЕНЕҢ (МКДЦ) ТРАВМАТОЛОГИЯ БҮЛЕГЕ МӨДИРЕ, «КЫЗЫЛ ЗОНА» МЕДИГЫ.

1

– Мине табиб булырга үгетләп, **ӘНИЕМ ДӨРЕС ЭШЛӘГӘН.** Мәктәптә укыганда, мин физика белән мавыктым, киләчәгемне шуның белән бәйләргә, МФТИга укырга керергә җыендым. Ә әнием һәм бабам безнең табиб булуыбызны теләде. Әнием бик озак үгетләгәч, мин медицина университетына керергә ризалаштым. Һәм моңа бер дә үкенмим. Киресенчә, әлеге һөнәрне сайлавыма бик шатмын. Бу бик кирәкле һөнәр, бигрәк тә хәзер.

2

– Сәйярне тәрбияләүдә һәм үзара мөнәсәбәтләребездә **МИН БЕРНӘРСӘНЕ ДӘ ҮЗГӘРТМӘС ИДЕМ.** Минем хыялымны тормышка ашырып, табиб һөнәрен сайлавы өчен мин аңа бик рәхмәтлемен. Ул бик яхшы белгеч, мин моны әнисе буларак кына түгел, аның пациенты буларак әйтәм. Студент чагында ук Сәйяр минем каты авырган этиемә бик булышты. Ул аның гомерен озайтты. Аннары миңа операция ясады, соңыннан да бик ярдәм итте. Мин Сәйярне игелекле, ярдәмчел, җаваплы, тәвәккәл булуы өчен хөрмәт итәм. Без барыбыз да аның белән горурланабыз.

3

ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛ...

– ...**Балаларым белән үткәргән һәр мизгел бәхетле.** Балачактан ук алар бик акыллы, тыңлаучан булды. Сеңлесе Сабрина тугач, Сәйяр аны караштты, тәрбияләүдә катнашты. Хәзер дә Сабрина һәрвакыт абыйсының кайгыртуын тоеп яши. Мин үзебезнең шундый шәп балалар үстерүебезгә бик сөенәм.

– ...**Бу минем 131 нче лицейга укырга кергән көнем.** Мин анда 6 нчы сыйныфтан соң керергә әзерләндем. Шактый авыр имтиханнар бирергә кирәк иде. Әнием һәр имтихан алдыннан бик борчылды. Ниһаять, укырга керүчеләрнең исемлеге эленер көн җитте. Әнием белән икәү киттек. Анда минем фамилиямне күргәч, әнием сөенечтән елап җибәрде.

Фото: Александр Ефремов

Фото Шайдуллиннар архивыннан

СӘВИЯ ҺӘМ МАРСЕЛЬ
ШӘЙДУЛЛИННАР

СӘВИЯ ШӘЙДУЛЛИНА (ӘЛМӘТ РАЙОНЫ КӘЛӘЙ АВЫЛЫНДА БАЛАЛАР БАКЧАСЫ МӨДИРЕ БУЛЫП ЭШЛӘГӘН) ҺӘМ МАРСЕЛЬ ШӘЙДУЛЛИН, АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ – РАЙОН СОВЕТЫ РӘИСЕ.

1

– ӘНИЕМ ҺӘРВАКЫТ ХАКЛЫ! Һәм мин һәрвакыт аның киңәшләренә колак салырга тырыштым. Дөрес, бер тапкыр тыңламадым. Әнинең мине медицина институтына укырга кертәсе килде, табиблар һәрвакыт кирәк, дип үгетләде. Әмма мин әтием юлыннан киттем һәм ветеринар булдым.

2

– Улымның табиб булуын теләп һәм аны медицина институтына кертмәкче булып, **МӨГАЕН, МИН ЯЛГЫШКАНМЫНДЫР.** Ул башка һөнәр сайлады – «ветеринария табибы» белгечлеге буенча Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясен тәмамлады. Һәм әлеге һөнәре аңа алдагы тормышында бик кирәкле булып чыкты. Һөнәр сайлаганда, балаларга үзләренә ирек бирергә кирәктер, дип уйлыйм хәзер, бигрәк тә Марсель кебек үзенә нәрсә кирәген яхшы белүчеләргә.

3

ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛ...

– ...Мин беренче сыйныфка укырга барам, мин инде дәү үстем, бакча баласы түгел! Әнием янәшәдә, үзе яныннан җибәрәсе килмәсә дә (ул балалар бакчасы мөдире иде), ул да бик шат һәм мине инде зур һәм мөстәкыйль булуым өчен мактый, җәй буена 20 сантиметрга үсүемә мин бик сөенәм. **Минем өстә – өр-яңа мәктәп формасы, аркамда – менә дигән букча, кулымда букет, янәшәмдә әни – шәп егеткә бәхет өчен тагын нәрсә кирәк булсын!!!**

– ...Кайвакыт улыма карап сокланам – нинди олы, җаваплы инде ул, җилкәсендә – тулы бер район бит, барысы да яхшы, минем ярдәмем кирәк түгел – үзе булыша. Әмма ул гел яныма килә, шалтырата, киңәш сорый – **һәм мин аның шундый әйбәт булуына бик бәхетлемен.** Үземнең шундый ул әнисе булуына көн саен сөенәм.

Фотолар Бикчәнтәевләрнең гаилә архивыннан

НАИЛӘ ГӘРӘЕВА ҺӘМ ФӘРИТ БИКЧӘНТӘЕВ

НАИЛӘ ГӘРӘЕВА, РОССИЯНЕҢ АТКАЗАНГАН, ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК АРТИСТКАСЫ, ҺӘМ ФӘРИТ БИКЧӘНТӘЕВ, Г. КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНЫҢ БАШ РЕЖИССЕРЫ, ТР ҺӘМ РФНЕҢ АТКАЗАНГАН СӘНГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ.

1

– **ӘНИ ХАКЛЫ БУЛГАН ИКӘН!** Мин аны бүген дә шулай дип саныйм. Шуңа күрә кайсыдыр очракны аерып әйтә дә алмыйм – әни минем өчен гел хаклы! Бу язылмаган закон кебек...

2

– Хәлдән килгәннең барысын да өйрәттем кебек. Ләкин бу сорауга җавап биргәндә бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк – кызганычка, Фәрит этисез үскән бала. Шуңа күрә ана ничек кенә тырышса да, ата тәрбиясе бирә алмый, бу мөмкин түгел! Бала эти белән дә үсәргә тиеш. **ФӘРИТКӘ ЭТИСЕ ҖИТМӘВЕН ГЕЛ СИЗЕП ЯШӘДЕМ.** Хәтта улым өйләнгәндә дә: «Эх, этисе янында булса иде», – дип уйладым.

3

ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛ...

– ...**Фәритнең 1991 елда ГИТИСны тәмамлап, Камал театрына эшкә кайтуы.** Бу минем хыял түгел, ә бик зур теләк иде. Улымның этисе юлыннан китүен бик теләдем. Һәм бу шулай булды да. Фәритнең театр дөньясында кайнавын табигый дип кабул иттем, ул кечкенәдән сәхнә артында, сәхнәдә үскән малай. Аның менә оста режиссер булуы, монысы минем өчен мәртәбә.

– Биш яшемдә әни мине укырга өйрәтте. Бүгенгедәй күз алдымда – әни ризык әзерли, ә мин аңа кычкырып китап укыйм. **Әни мактый, ә минем сөенечем эчемә сыймый... Булдырдым бит, тәки булдырдым!**

Фото: Александр Ефремов

СВЕТЛАНА ҺӘМ БӘХТИЯР
ИЗМАЙЛОВЛАР

СВЕТЛАНА ИЗМАЙЛОВА, ТР МИЛЛИ МУЗЕЕ ГЕНЕРАЛЬ ДИРЕКТОРЫНЫҢ ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА УРЫНБАСАРЫ, ҺӘМ БӘХТИЯР ИЗМАЙЛОВ, ТР ФА Ш.МӘРҖАНИ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНЫҢ ДИСЦИПЛИНААРА ТИКШЕРЕНҮЛӘР БҮЛЕГЕ МӨДИРЕ.

1

– ӘНИЕМ ҺӘРВАКЫТ ХАКЛЫ! Ул һәрвакытта да нишләргә кирәген төгәл белә һәм теләсә нинди хәлдә дә югалып калмый торган кеше. Әхлакый ориентир һәм абруйлы үрнәк. Мәсәлән, әнием һәрчак, үзеңә ошаган юлдан гына барырга кирәк, ди иде. Әйе, гел җиңел булмаячак, әмма әкренләп бу уңыш китерәчәк. Шулай булып чыкты да.

2

– Искиткеч улларым булуга мин бик бәхетле. Бәхтияр – олысы. Без ирем белән икебез дә галим, һәм аңа үзенчәлекле исем сайладык. Фарсы теленнән ул «бәхет өчен туган» дип тәрҗемә ителә. Бәхтияр – «студент чак» баласы, ул туганда, ирем – университетның бишенче курсында, мин әле өченче курсында гына укый идек. Ул яшь галимнәр даирәсендә, кызыклы аралашу һәм иҗат мохитендә үсте. Мондый балачак улларыбызга ошагандыр, дип уйлыйм – икесе дә гаилә традициясен дәвам итте, тарихчы галим юлын сайлады һәм уңышка иреште. Димәк, барысын да дөрес эшләгәнбез! **ӘММА БЕР НӘРСӘНЕ ҮЗГӘРТЕР ИДЕМ.** Минем олы улым – үтә дә җаваплы. Эшеннән канәгатьлек кенә алсын өчен, әлеге сыйфатны бераз гына киметү яхшы булыр иде.

3

ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛ...

– ...Бервакыт ирем белән бик каты бәхәсләшә башладык. Инде шактый соң иде, балалар үз бүлмәләрендә йоклый. Кинәт ишектә кыңгырау чылтырады. Ачсам – Бәхтияр басып тора! **Балконга чыгып, икенче каттан төшкән дә, баскычтан менгән. Безнең бәхәсне туктатыр өчен!** Дөрес уйлаган булып чыкты. Без шаккаттык. Бәхәсне дәвам итәсе килмәде инде шуннан соң.

– ...Балачактан хәтердә кадерләп саклаган бер истәлек бар – шуннан һаман көләбез әле. Мәктәптә әти-әнием турында инша язарга кирәк иде. Һәм мин: **«Минем әтием бик шаян, әнием исә үз эшен бик ярата һәм өйгә соң гына кайта»**, – дип язганмын. Күп еллар үтте, әмма әнием үзгәрмәде: ул үз эшен һаман да шулай ук ярата һәм һаман кичкә кадәр тоткарлана әле.

REWORK
OUTDOORS DISCOVERING

ЛӘЙЛӘ ҺӘМ ДАНАТ САФИННАР

ЛӘЙЛӘ САФИНА, SIGN URBAN («СЫЙФАТ ФАБРИКАСЫ» ҖЧҖ) КОМПАНИЯСЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ДИРЕКТОРЫ ҺӘМ ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫННАН БЕРСЕ, УЛЫ ДАНАТ БЕЛӘН.

1

– Мине йөзүгә биреп, **ӘНИЕМ ДӨРЕС ЭШЛӘДЕ.** Ә мене музыка мәктәбенә гитара классына бирүе дөрес түгел. Мин гитарада уйнарга яратмыйм, әмма әнием, өйрәнгәч, әле үзенә рәхмәт тә әйтәчәкмен, ди. Укыйм инде анда да, баш тартып булмый бит!

2

– Данатны хоккейга биреп, мөгаен, **МИН ЯЛГЫШКАНМЫНДЫР.** Өч ел буе шөгыльләнсә дә, спортның әлеге төре аның холкына бер дә килешми иде, шунлыктан барыбер ташларга туры килде. Әмма тискәре тәҗрибәнең дә файдасы булды. Хәзерге акылым булса, мин аны баштан ук йөзүгә бирер идем дә бит. Ул анда зур уңышларга ирешә, дөнья чемпионы Яна Мартынова белән шөгыльләнә.

3

ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛ...

– ... Иң бәхетле мизгел – Данат улым туган көн.

– ... Әнием белән икәү Америкада тау аттракционында шуганда.
Бик куркыныч та, бик рәхәт тә булды.
Мин шулчакта үземне бик бәхетле итеп сиздем.

РЕДАКЦИЯ КУХНЫ

ЛӘЙЛӘ САФИНАДАН ДОРАДО БАЛЫГЫ БЕЛӘН ШПИНАТ

Татьяна Вафина

«Татарстан»ның редакция кухнясы»нда хатын-кызлар бәйрәменә каты әзерлек бара. Нәрсәдер чыжлый, кайный, искиткеч хуш ис тарата. Бүгенге пешекчебез, SIGN URBAN* («Сыйфат фабрикасы» ҖЧҖ) компаниясенең генераль директоры һәм оештыручыларыннан берсе Ләйлә Сафина ике тәгам – йогуртлы соуста шпинат белән дорадо балыгы, баллы-горчица һәм кабак соуслары белән руккола һәм үрдәк итеннән салат әзерли... Вакытның бик аз, ә рецептлардагы ингредиентлар санының гаять күп булуын исәпкә алып, ярдәмгә кулинария артиллериясе – Ләйләнең улы Данат килә.

ГАИЛӘМДӘГЕ ИРЛӘРДӘН УҢДЫМ

– Данат бик тәмле пешерә безнең, – ди Ләйлә. – Ул җиденче сыйныфта укый, әмма мәктәпкә киткәнче бөтенебез өчен иртәнге аш әзерли, укудан кайткач, сеңлесен ашата ала. Гомумән, мин гаиләдәге ир-ат затыннан уңдым: ирем дә, улым да тәмле пешерә, ә кайнатам исә – бик оста. Кыяр-помидорларга кадәр үзе тозлый! Кышлыкка ул әзерләгән чөгендердән исә борщны өч минутта пешереп була!

– Мондый кулинарлар командасы булганда сезгә бөтенләй ашарга әзерләмәсәгез дә була икән.

– Безнең гаиләдә кем тели – шул пешерә, кем эштән иртәрәк кайта – башкалар кайтканчы рәхәтләнеп кичке аш әзерләп куя. Дөресен әйтим, миңа еш пешеренергә туры килми, нигездә ял көннәрендә генә эләгә. Мин ниндидер катлаулы ризыклар – тәмле ризотто, суган ашы, том-ям пешерергә яратам...

ИНТЕРВАЛЛЫ АЧ ТОРУ?

– Әни шундый берәр ят ризыкны ике атнага бер пешерергә мөмкин, – дип төгәллек кертә Данат. – Мәсәлән, диңгез ризыклары белән кара макарон... Әти исә атна ярымга бер тапкыр стейк әзерли.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

Төп ризык өчен:

- Дорадо балыгы – 4 данә;
- Каперслар – 200 г;
- Лимон – 1 данә;
- Тоз – тәменчә;
- Прованс үләннәре – тәменчә;
- Туңдырылган шпинат – 80 г;
- Үсемлек мае – 10 г;
- 33% лы сөт өсте – 60 г;
- Тоз – тәменчә;
- Зәйтүн – 8 данә;
- Сөт өсте – 120 г.

Үрдәкле салат өчен:

- Руккола – 20 г;
- Ысланган үрдәк түше – 20 г;
- Черри помидорлары – 50 г;
- Соус яки серкә.

Кабак соусы өчен:

- Кабак – 500 г;
- Су – 300 г;
- Кокос сөте – 200 г;
- Тоз – 10 г;

Баллы-горчицалы соус өчен:

- Үсемлек мае – 200 г;
- Бал – 10 г;
- Соя соусы – 20 г;
- Бөртекле горчица – 10 г;

*САЙН УРБАН

Фото: Ната Смирнова. РЕКЛАМА 16+

– Ә башка вакытта кем пешерә? Әллә сезнең интерваллы ач торумы: ике атнага бер, атна ярымга бер...

– Башка вакытта исә гадәти ризыклар, – дип көрсенә Данат.

– Бүген исә гадәти түгел, – дип елмая Ләйлә һәм безгә гөмбәгә охшаган кабак күрсәтә. – Кабакны турыйбыз да, пешәргә куябыз, кокос сөтен дә шунда өстибез. Барысы бергә пешеп чыккач, блендерда издерәбез дә, бик тәмле соус килеп чыгачак. Һәм бик тиз дә.

Ләйлә бик җитез генә салат җыя: башта тәлинкәгә кызгылт-сары төстәге кабак соусыннан күлләвек-«мендәр» җәя. Аннары аның өстенә рукколадан «юл» сала. Үрдәк итен һәм яртылаш киселгән черри помидорларын җилпәзә кебек итеп тезә. Барлык бу матурлык өстенә башта баллы-горчицалы, аннары бальзамик соусын сибә.

Йә, шундый матурлыкны ничек ашарга инде хәзер, ә?

НӘТИҖӘ КЕШЕСЕ

Данат, оста пешекче кебек перчатка киеп, балык эченә каперсларны тутыра һәм 20 минутка газ миченә куя. Һәм әнисе белән шпинатка тотына – аны табадагы сөт өстендә томалап пешереп алырга кирәк. Ләйлә чәчрәгән тамчыларны шундук сөртеп куя бара.

– Пешерү һәм җыештыру арасыннан мин җыештыруны сайлар идем, – дип елмая ул.

– Ә инде җыештыруны яки эшне сайларга кирәк булса, әлбәттә, эни эшне сайлаячак, – дип өсти Данат. – Сеңлем белән миңа исә җыештырырга туры киләчәк...

– Җитәкчеләр шундый инде алар. Усал, әмма гадел. Үзләрен дә, хезмәткәрләрен дә аямый. Сез дә шундый җитәкчеме?

– Мин усал түгел, кырыс, – дип каршы төшә Ләйлә. – Һәм бик таләпчән. Миңа нәтиҗә мөһим. Мин хезмәткәрләремә дә, балаларыма да: процесс яхшы ул, әмма аның һичшиксез нәтиҗәсе булырга тиеш, дим. Бигрәк тә эштә. Мин – нәтиҗә кешесе.

– Һәрнәрсәдә нәтиҗәгә ирешәсез, дигән сүзме бу? Хәтта хыялларыгызда да?

– Балачагымда хыялым бар иде минем – курчак җитештерү предприятиесен булдыру. Бик матур, зәвыклы киенгән курчаклар – совет кибетләрендә андыйларны табып булмый иде. Мин инде ул чакта ук акча эшләргә, һәм шул ук вакытта бер дигән продукт җитештерергә теләгәнмен. Үсеп җиткәч, хыялым үзгәрде. Курчаклар ясамасам да, безнең SIGN URBAN компаниясе ял итү өчен уңайлы һәм рәхәт урам җиһазлары җитештерә. Безгә урамнарны уңайлык, матурлык белән тутыру ошый. Тормыш белән! Безнең балаларыбызның комфорт һәм эстетика мохитендә үсүендә үзебезнең дә өлеш барлыгын тою бик рәхәт, бу аларның мәдәниятлелек дәрәҗәсенә һичшиксез йогынты ясаячак. Сабыйларның да, өлкән яшьтәгеләрнең дә матур һәм рәхәт урамда аралаша, ял итә алуы бик шәп бит! Республика һәм дәүләт программалары кысаларында без нәкъ менә шундый җәмәгать мәйданнары булдырабыз да инде.

Әшебезгә бирелгән иң дулкынландыргыч бәя исә мондый: «Мин моны 38 ел буе көттем!» – диде миңа Казан ишегалларыннан берсендә яшәүче бер ханым. Мондый сүзләрне ишеткәч, көтелгән нәтиҗәгә ирешүне аңлыйсың да инде.

ИХ, ЧӨГЕНДЕРЛЕ БАЛЫК ТА БУЛСА...

Бүгенге кулинария нәтиҗәсе исә көтелгәннән дә шәбрәк булды. Бизәлү ягыннан да, тәм ягыннан да тел тидермәслек иде.

– Тәмлеме балык?

– Әйе! – дип башын селки Данат, әнисе әзерләгән тәгамны тәмләп ашый-ашый. – Моның янына әле чөгендерле сельдь балыгы да булса, тагын да шәбрәк булыр иде...



БИЗНЕС-ЛЕДИ: ҮР АРТЫННАН ҮР ЯУЛАП

Лиана Баһавиева,
«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» ТТИО президенты

Эшкуар хатын-кыз, уңышлы бизнес-леди... Килешәсездер, бүген моның белән беркемне дә гаҗәпләндереп булмый. Эшкуар хатын-кызның бизнеста уңышка ирешү ихтималы ир-ат коллегаларына караганда күпкә күбрәк, дигән фикер бар. Биредә кешелекнең гүзәл яртысына хас сыйфатлар – максатчанлык, оешканлык, җаваплылык мөһим роль уйный.

Болар барысы да дөрес, гәрчә көчле затларның иң яхшы вәкилләренә дә әлеге сыйфатлар шул ук дәрәҗәдә хас булса да. Әмма безнең иң яхшы бизнес ханым-туташларыбызның үргә ничек күтәрелүен бәяләгәндә, аларның нәтиҗәгә эшлеклелек һәм башка шундый мәгълүм инструментлардан файдаланып кына ирешмәве ачыклана. Хатын-кыз табигате ул сәнгатьтәге иҗат чаткысы кебегрәк: бизнес-бурычларны хәл итү өчен, шундый даһи ысуллар таба ки, андыйларны ирләрдәгедәй исәп-хисап һәм салкын анализ юлы белән табу бөтенләй мөмкин түгел.

Ә таулар күчерергә сәләтле хатын-кыз энергетикасы турында ни әйтерсез? Аның белән табигатьтә тиңе булмаган мәңгелек двигатель генә ярышырга сәләтле. Хатын-кыз мөлаемлыгы, гүзәллеге, әдәплелеге һәм сизгерлеге хакында исә әйтеп торасы да юк, гәрчә нәкъ менә шул сыйфатлар аларның партнерларын, коллегаларын, тулаем коллективларын әлеге галәмәт зур планнарның тормышка ашуы өчен бөтен көчен бирергә мәҗбүр итә дә инде. Башкача әйткәндә, хатын-кыз эшкуарлыгы – һәрвакытта да традицион критерийлар ярдәмендә бәяләп булмаслык үзгә бер сфера ул. Бәлки моңа безнең бизнес туташ-ханымнарыбызның үз эшләрен бик хатын-кызларча – яратып, ихлас йөрәктән башкаруы сәбәпледер. Һәм аларның яраткан эшләренә үз балаларына карагандай мөнәсәбәтедер. Шунлыктан нәтиҗә дә бик яхшы булып чыга.

ТАТАРСТАН БИЗНЕС-ЛЕДИЛАРЫНЫҢ ШӘХСИ ТАРИХЛАРЫ (ҺӘМ УЛ ХАКТА ГЫНА ДА ТҮГЕЛ) ТУРЫНДА БИРЕДӘ УКЫГЫЗ...

ЧИТЕК КИГӘН ЗАМАНДА...

Руфия Фазылова

Март санына үзенчәлекле һөнәр иясе булган берәр гүзәл затны күрсәтәсе килде. Дөресрәге, шундый һөнәр иясе турында язасы. Кем булырга мөмкин ул дип эзләнеп утырганда, редакциябезгә бизәкле чүәк кигән бер ханым килеп керде. Аралаша башлагач, бу чүәкләрнең заманында Дөбъяз Милли аяк киемнәре тегү фабрикасында эшләнгәнен белдек. Язма тарихы әнә шуннан башланды.

АТАКЛЫ ФАБРИКА

Фирадия Сабирова исеме шул як кешеләре өчен яхшы таныш – өч дистә елдан артык Дөбъяз Милли аяк киемнәре фабрикасын җитәкләгән хатын-кыз ул. Бүген Әтнәнең үзендә яши, җитмеш ике яшен тутырган. Ә гомеренең күп өлешен Биектау районы Дөбъяз авылында уздырган. Яшьли кавышкан сөйгән яры белән ике ул үстергәннәр. Гомер көзенә аяк басканда, язмыш әлеге тырыш ханымны нык сынаган – алтмыш ике яшендә яраткан ире мәрхүм булып куйган. Бер мәл тормышының кызыгы калмаган...

Фирадия апа алты елдан соң Әтнәдә яшәүче тол ир Данил абый белән таныша. Спортчы, мәрхүм ире кебек үк танылган мөгаллимне ул бер күрүдә ошата. Нәтиҗәдә, ике ялгыз йөрәк озакка сузмый кавыша – матур итеп никах укыталар. Бер-берсенә терәк булып, унҗиденче ел инде әнә шулай яшәп яталар.

Ни кызганыч, Дөбъяз Милли аяк киемнәре фабрикасының ишегенә бүген йозак эленгән. Ә бит заманында ул Татарстанны гына түгел, союздаш республикаларны да читек, чүәкләр белән тәэмин иткән.

Дөбъяз фабрикасының тарихы бер гасырлык. XX йөз башларында ук бу як халкы аяк киеме тегү һәм чигү белән шөгыльләнгән. Шыпшыйк авылының Сиражи бай кушаматлы кешесе, тирә-як авылларда да читек, чүәк эшләүне җайга салган. Халыкны кирәк-яраклар белән тәэмин итеп, заказга аяк киемнәре тектергән. Совет власте урнашкач, Сиражи бай бу эшен туктаткан. Ләкин әлеге эшкә өйрәнгән халык барыбер читек, чүәк ясауны ташламаган. Хәтта сугыш вакытында бирегә олтан салырга фронттан итекләр дә кайтарганнар. Ә илленче елларда күрше Суыксу авылында бик зур тегү һәм чигү әртиле барлыкка килгән. Соңрак бу әртилне бинасы белән бергә Дөбъяз авылына күчергәннәр. Нәтиҗәдә, алтмышынчы елларда авылда йөз илле кешелек эш урыны булган чигү һәм тегү фабрикасы оешкан. Заманына күрә зур булган ул – җиде бүлмәсе утын мичләре белән җылытылган. Анда чигү, тегү, олтанга утырту цехлары, хәтта фотога төшерү һәм чәч кисү кебек бүлекләр дә эши башлаган. Алай гына да түгел, күрше авыллардан килеп эшләүчеләр өчен тулай торак та булдырылган. Дөбъязга кайткан беренче телевизор да нәкъ менә фабрикада була. Эшчеләр эштән соң җыелып телевизор караган.

Әнә шулай гөрләп эшләп ятканда, 1965 елда фабрикада янгын чыккан. Агач бина санаулы минутлар эчендә көлгә әйләнгән. Бары кайбер тегү җиһазларын гына коткарып кала алганнар. Тик шул ук елның җәендә кызыл кирпечтән яңа бина салып куялар. Нәтиҗәдә, фабрика яңа сулыш белән яши башлаган.

Шунысын әйтим: бу як кешеләре өчен фабрика бик кадерле, һәм ул тормышларында зур роль уйнаган. Ни өчен дигәндә, кемнеңдер әнисе,

Фото: Александр Ефремов

апасы, күршесе биредә эшләгән. Шуңа да кечкенә балалар курчаклы түгел, ә итек, читек тегешле уйнаган. Ә чыгарылыш сыйныф кызлары, мәктәпне тәмамлагач та, бу юнәлештә укырга барырга хыялланган.

УЙЛАМАГАН ҖИРДӘН...

Фирадия Сабирова исә, укытучы булам, дип янып яши. Тик сигезенче сыйныфны тәмамлагач, тегүчелеккә укырга кереп куя.

– Тумышым белән Биектау районының Урта Алат авылыннан мин, – дип сүзен башлады әңгәмәдәшем. – Әти-әни гади колхозчылар иде. Ләкин нәсел тамырларыбыз бик әйбәт – әнинең әтисе Мәскәүдә алтын кибете тоткан. Әти ягыннан да бабай авылның атаклы кешесе саналган. Әти бишкә генә укыган, тәрбияле иде. Кулак баласы булганга, яхшы эшләргә урнаша алмаган ул. Бик ачуы килгәндә: «И, надан сез!» – дип әрләр иде. Әтидән башка бер әшәке сүз дә ишетмәдек. Тик кызганыч, кыска гомерле булды ул... Исән булса, бәлки мине тегүчелеккә җибәрмәс тә иде. Хәер, үзем дә укырга керермен дип уйламадым. Казанга имтиханнарга баруымның сәбәбе – сыйныфташ кызым бик сорады. «Иптәшкә бар», – диде. Рус Алаты мәктәбенә документларны алырга төшкәч тә, мәктәп директоры шаккатты: «Фая, син бит укытучы булырга хыялландың!» – диде. Ә мин һич кенә дә шикләнмичә: «Мин барыбер ул техникумга керә алмыйм, бер дә әзерләнмәдем. Шуңа күрә яңадан тугызынчыга кайтам», – дидем.

Ләкин язмыш дигәнең бөтенчә хәл кыла – Фирадия Казан җиңел промышленность техникумының кичке бүлегенә укырга керә, ә иптәш кызы имтиханнарны тапшыра алмый. Нәтиҗәдә, ул яңадан укыган мәктәбенә кайтып китә.

– Кичке бүлектә укыгач, эшкә дә керергә ниятләдем, – дип шул чакларны искә алды Фирадия апа. – Чөнки авылда әнидән ярдәм көтәргә өмет юк. Абый мин укырга кергән елны армиягә китте, өйдә сеңел белән энекәш калды. Шулай итеп, техникум янәшәсендә киемнәр тегә торган нәфис эшләнмәләр фабрикасына эшкә урнаштым. Көндез эшлим, кич укыйм. Йокы туймый... Тамак ачлы-туклы... Ел ярым әнә шулай газапландым. Аннан «Спартак» фабрикасына һөнәрем буенча урнаштым. Әлбәттә, тагын укып эшләдем.

Яшь кыз күннән аяк киемнәрен тегәргә әнә шунда өйрәнә. «Спартак» аның өчен тәҗрибә мәктәбе генә түгел, тамагын туйдырырлык, өс-башын карарлык эш урынына да әйләнә. Фирадия авылда яшәгән әнисен, туганнарын да кайгырта башлый. Әле абыйсына да туй үткәрергә булыша.

Әнә шулай эшләп укып, яшь кыз кулына диплом ала. 1971 ел була ул. Шул вакыт аны югары белем алырга чакыралар. Тик кыз каршы килә – Казанда яшәргә урыны юк. Аннары Фирадия Дөбъяз Милли аяк киемнәре фабрикасы юлламасы белән техникумда укыды бит. Димәк, анда кайтырга кирәк.

– Әлбәттә, югары белем алырга калам дисәм, Дөбъязда каршы килмәсләр иде, – диде Фирадия апа. – Тик мин туган якка кайтырга карар кылдым. Ул чагында Дөбъяз Милли аяк киеме фабрикасының көчле чагы. Гаҗәп: заманнар алга китсә дә, һаман да кул белән кисеп эшләү иде. Кисүчеләр башта чүәк, читек размерын үлчи, аннан кисә. Әзер комплект тегү цехына чыгып китә, анда эшләүче кызлар без белән тегә... Хезмәт юлымны әнә шулай башладым.

– Сездә гел хатын-кызлар гына эшләдеме? – дим.

– Ир-атлар да бар иде. Алар чүәкнең табанына кадак какты.

– Фабрикада сезнең кебек махсус белем алган кешеләр күп идеме?

– Юк, әлбәттә. Эшчеләрнең барысы да диярлек бу хезмәткә үзлегеннән өйрәнүчеләр иде.

1972 елны Дөбъяз Милли аяк киеме фабрикасын Арчаныкы белән берләштерәләр. Нәтиҗәдә алар Арча Милли аяк киемнәре фабрикасының бер филиалы булып кала, ә Дөбъяз фабрикасының җитәкчесе Камил Сәйфуллинны Арчага директор итеп алалар.

– Камил абый үзе урынына Гайнетдинов Ядкарь абыйны калдырды, – диде Фирадия апа. – Ни кызганыч, ул озак эшләмәде – Арчага фабрика эшләре белән барган җиреннән фаҗигале рәвештә һәлак булды. Мин ул вакытта декрет ялында идем. Шуннан Камил абый мине чакырып чыгарды. «Белемең, тәҗрибәң бар. Әйдә, Дөбъяз филиалын җитәклә», – диде. Әлбәттә, башта каушап калдым. Яшь бит, кечкенә балам да бар. «Ярдәм итәм, борчылма», – дип, Камил абый күңелне күтәрде. Чынлап та, үзе дә шунда эшләп киткән кеше буларак, ул безгә карата гел хәерхаһлы булды.

1973 елдан башлап Фирадия апа Дөбъяз фабрикасын җитәкли. Утыз елга якын эшләү дәверендә нинди генә очракларны хәл итәргә туры килми. Ләкин аларның бригадасы бер дә сынатмый – Арча филиаллары арасында гел беренчелектә баралар. Шулай булуга карамастан, фабрика эшләүдән туктый. Башта кеше санын киметәләр, аннан инде бөтенләй ябылалар.

– Милли аяк киемнәргә сорау артты кебек. Ни өчен шундый көчле эшләгән фабрика бөлгенлеккә төште? – дим.

– Төп сәбәп – заказлар булмады. Соңгы елларда гына миллилек модага керде. Ә 2000 нче елларда халыкның бик исе китми иде. Аннары, читек, чүәкләрнең бәясе кыйммәт бит. Ә ул чорда күпләп Кытайдан арзанлы аяк киемнәре кайта башлады. Нәтиҗәдә, без яңа шартларда эшли алмадык.

Фирадия апа, фабрикадан киткәч, берничә ел балалар бакчасында мөдир булып та эшләгән. Бүген инде җәмагате белән тыныч кына яшәп, дин гыйлемен өйрәнәләр:

– Аллаһы Тәгалә кешегә үзе юл күрсәтә икән, – диде ул. – Һөнәр сайлавым, ирем мәрхүм булгач, яңадан гаилә коруым... Барысы да Аның кулында. Һәр көнгә рәхмәтле булып, сөенеп яшәргә кирәк. Инде мин моны тәгаен беләм.

КЫЮЛЫК БУЛГАН ҖИРДӘ...

Руфия Фазылова

Теләчедә сөт-май заводы ябылуын белгәч, көрсенеп куйган идек. Инде аның яңадан эшли башлавын ишеткәч сөендек – димәк, җирле халыкка эш булган, район халкы табигый ризык ашый дигән сүз. Саный китсәң, аның уңай яклары тагын күп инде. Сөт заводы ничек аякка баскан? Аның башында кем тора? Язма шул хакта.

ЯҢА КОМБИНАТКА – ЯҢА ҖИҺАЗЛАР!

Биредә яшәүчеләр әле дә хәтерли: 2014–2015 елларда банкротлыкка чыккач, Теләче сөт-май заводы эшен туктата. Җиһазлары сатылып бетә, эшчеләргә исә яңа хезмәт урыны эзләргә туры килә. Ә бит 2000 нче елларда Теләчедә ясалган майның даны бөтен республикага таныла. Һәм менә, төрле сәбәпләр аркасында, шулай гөрләп эшләп торган завод ишегенә йозак элена. Зур бина ташландык булып, үзенең язмышын көтә. Күпләр аның яңадан эшли башлавына өметен югалта. Ә көннәрдән бер көнне могҗиза чынлап та була – 2018 елда районга инвестор килә. «Нәүрүз» кооперативы сөт-май заводын үз канаты астына алырга карар кыла. Район җитәкчелеге бу хәбәрне ике куллап хуплый. Гаҗәп тә түгел – гади халыкка эш урыннары, ә район бюджетына яхшы гына керем дигән сүз ләбаса. (Салым акчасы районга кала бит!)

Бүген Теләче сөт-май комбинатын **Раилә Нәкыйп кызы Хисмәтуллина** җитәкли. Яшь булуына карамастан, авыл хуҗалыгы өлкәсендә тәҗрибә туплаган белгеч ул.

– Банкротлыкка чыккан заводны без лизинг компаниясеннән алдык, – диде җитәкче. – Элеккеге җиһазларның барысын да чыгардык, чөнки алар яраксыз иде. Алар урынына яңаларын алып кайттык. Заводны яңадан эшләтеп җибәрү өчен бер елдан артык вакыт кирәк булды. Кыюлыкны җигеп, шулай 2019 елда эшли башладык. Әлбәттә, күңелдә икеләнү дә бар иде: завод зур бит. Алай-болай эш барып чыкмаса, сөт җыю урыны буларак кулланырбыз дигән уйлар да килде. Аллага шөкер, ике ел эчендә предприятие тулы көченә эшли, үз кулланучыбызны таптык дип әйтә алам.

Теләче сөт-май комбинатында бүген җитмештән артык кеше хезмәт куя. Биредә нигездә сыр җитештерәләр, көнгә алты-җиде тонна ясыйлар. Сырдан артып калган сөттән май атлыйлар. Анысы тонна-тонна ярымлап була икән.

– Без ике төрле сыр – «Голландский», «Российский» сортларын җитештерәбез, – диде Раилә Нәкыйп кызы. – Сөтне исә Кукмара, Теләче, Балтач районнарыннан сатып алабыз.

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

Быел кышын сөтне сатып алу бәясе дә, табигый ки, сырның да хакы арткан. Мисал өчен, сөт илле тиенгә артса, сырның бәясе биш сумга арта. Шунсыз сөт-май заводы минуска эшли башлый.

Теләчедә җитештерелгән сөт-май әлегә зур сәүдә челтәр кибетләрендә юк. Алар күбрәк күпләп сату белән шөгыльләнә – зур фураларга төяп, сырны Новосибирск, Санк-Петербург, Түбән Новгород, Мәскәүгә озаталар. Татарстанда исә, Теләчедән башлап, якын-тирә район кибетләрендә сатып алырга була, шулай ук Казан базарларында заводның аерым нокталары бар.

– Бер зур йөк машинасы унтугыз тонна продукция алып чыгып китә, – диде җитәкче. – Атнасына шулай ике фура озатабыз. Ике-өч ел эчендә эшне җайладык – продукция урнашып бара. Әлбәттә, алга таба җитештерүне арттыру турында уйлыйбыз. Татарстан буенча да күбрәк сатасы иде.

ӘТИ КЫЗЫ

Раилә Хисмәтуллинаның үзе белән якыннанрак танышабыз – зифа буйлы, чибәр туташ ул. Банкротлыкка чыккан оешманы күтәрергә алынырга җөрьәт тә итәргә кирәк бит.

– Эштән курыкмыйм мин, – диде яшь җитәкче. – Сөт сату, җыю буенча тәҗрибә бар. Әлбәттә, мондый комбинатның эш үзенчәлекләрен белми идем. Бәхеткә, шушы өлкәне яхшы белгән, тәҗрибәсе булган белгечләр таптык. Баш инженер Кукмарадан, биредә озак еллар эшләгән технологны чакырдык. Бик күп заводлар, ярминкәләрдә йөрдек – эш үзенчәлекләрен, яңа технологияләрне өйрәндек. Күп кеше белән аралаштык.

Раилә Хисмәтуллина тумышы белән Кукмара районының Югары Шәмәрдән авылыннан. Бүген дә Теләчегә туган авылыннан йөреп эшли.

– Теләчедә генә торып эшләп булмыймы? – дидем. – Көн саен йөздән артык чакрым йөрү рәхәт түгелдер бит...

– Әйе, юл бик якын түгел, Теләче белән Югары Шәмәрдән арасы алтмыш чакрымга җыела. Тик мин юлның авырлыгын сизмим. Һәр көн әти-әнием янына кайтам. Анда мине кайнар аш, ягылган мунча көтеп тора. Өч кызның иң төпчеге мин. Әллә шуңа да әти-әнием белән бәйлелек көчле.

Раилә Нәкыйп кызының әти-әнисе чын җир кешеләре. Күп итеп мал асрап, хәләл көчләре белән тормыш алып барган кешеләр.

– Безнең әти гомер буе механизатор булып эшләде, – дип балачак хатирәләре белән бүлеште җитәкче. – Үземне белгәннән бирле әтинең тракторына утырып йөргәнне хәтерлим. Кечкенәдән рульгә утырдым, хәтта комбайн да йөртә идем. Печән өсте җиткәч исә трактор арбасына әти төйи, ә мин рульне йөртәм. Гаиләдә малайлар булмагач, әти мине улы урынына күрде ахры. Әни дә ярым шаяртып: «Кызым, малай гына буласың калган», – дип әйтә иде. Чынлап та, техникага мөкиббән инде мин. Машина йөртә башлаганыма да егерме еллап бар.

Бүген Теләче сөт-май комбинатын Раилә Нәкыйп кызы Хисмәтуллина җитәкли.

Төпчек кыз иркәрәк булырга тиеш кебек, Раилә Нәкыйп кызы очрагында алай дип әйтеп булмый. Кыз туганнарның аралары икешәр ел гына булганга, алар үзара дуслар кебек үскән.

– Әти-әни безне тигез тәрбияләде, – диде әңгәмәдәшем. – Биш чакрым араны җәяү йөреп укыдык. Мин дә апалардан калмадым. Әни фермада сыер сава, иртән, кичен аны күрмибез. Шуңа күрә апалар белән бөтен эшнең рәтен белеп үстек – кечкенәдән сыер да саудык. Өйдәге эш бүленгән иде – беребез аш пешерә, икенчебез өй җыештыра, өченчебез маллар янында. Өчәр сыер асрадык. Әле малларны бетергәнгә ике генә ел, әти-әни җиде дистәне тутырды инде.

Раилә Нәкыйп кызы кечкенәдән эшкә өйрәткәннәре өчен әти-әнисенә бик рәхмәтле. Зур ихтирам, хөрмәт белән сөйли ул алар турында. Бүгенге уңышларында да аларның өлеше зур, ди.

«БЕЗНЕҢ СЫРНЫ ГЫНА АЛЫГЫЗ»

Сөт-май комбинатына яңа җитәкчеләр килсә дә, эш тәртибе үзгәрмәгән. Әйе, җиһазларның барысы да яңа. Ләкин эшнең асылы – продукцияне фәкать чын сөттән генә җитештерү принцибы шул ук калган.

Заводка керәп, эш барышы белән дә таныштык. Сөт заводка кайткач та, башта лаборатория аша уза. Монда чималның сыйфатын тикшерә торган өч лаборатория бар. Сөтнең сыйфаты физик, химик күрсәткечләр буенча дәүләт стандартларына туры киләме, майлылыгы, тыгызлыгы һәм башка төр үзенчәлекләрен тикшерәләр. Төрле консервантлар, майлар, өстәмә тәмләткечләр турында сүз да булырга мөмкин түгел. Шунысын да әйтергә кирәк, заводка ветеринария хезмәте белешмәсе булмаган сөтне керми.

– Дусларга, танышларга бездә җитештерелгән сыр, майны гына алырга кушабыз, – диде **микробиолог Миләүшә Насыйбуллина**. – Үзебез эшләгәч, йөз процент инанып, безнең продукция сыйфатлы, дип әйтә аласың. Балалар ризыклары да ясыйбыз бит.

Миләүшә Насыйбуллина элек тә биредә эшләгән булган. Май заводы ябылгач, төрле җирләрдә хезмәт куйган. Һәм 2019 елда янә аны монда чакыралар. Миләүшә ханым теләп ризалаша. Ни дисәң дә белгән, яраткан эше.

– Элеккеге шартлар белән бүгенгесе аерыламы? – дидем микробиологка.

– Бүген эшләргә җиңелрәк кебек. Элек без иске җиһазлар белән эшләдек. Алар йә ватыла, йә продукциянең сыйфатын киметә иде. Аннары, хәзер заводка кайткан сөтнең сыйфаты да яхшы. Фермаларда кул хезмәте бетеп бара, аппаратлар эшли, савылган сөт пычрак бидоннарга салынмый, ә турыдан-туры зур савытка җыелып бара. Контроль зур булганга, сыер асраучы хуҗалыклар сөтнең сыйфатына бик игътибар бирә. Ул бит акча белән бәйле – югары сортлы сөткә бәя кыйбатрак.

Баш **технолог Гүзәл Кузьмина** белән исә тәмле темага сөйләштек – сыр ясау. Гүзәл ханым да биредә эшләп киткән булган. Дөрес, элек Теләче сөт заводы сыр ясамаган, ә фәкать сыер мае җитештергән. Тик тәҗрибәле ханымнар яңа өлкәне дә тиз үзләштергән.

– Өй салуның ние бар, мүклисе дә чутлыйсы, дигән ди бит бер бабай, – дип елмайды технолог. – Эш тәртибен бер өйрәнгәч, авырлыгы юк. Сыр ясауның үз технологиясе бар: җылы сөткә катырылган оеткы салабыз да, ярты сәгать эчендә ул ойый. Оеткы катырылган килеш кайта, тере бактерияләр ул, җылыга салгач уяна. Нәтиҗәдә, эремчек сыман катнашма барлыкка килә. Аннан ул тозлы суга салына. Сыр ясалганчы берничә этап уза. Иң соңыннан аны формага салып, пакетларга төрәбез.

– Сыр ничә тәүлектә әзер була? – дим.

– Кырык биш-алтмыш көн эчендә өлгерә. Аның өчен бинада тугыз-ун градус җылы булырга тиеш.

Теләче комбинатында җитештерелгән сырлар дүрт ай саклана икән. Озаграк торган саен, аның тәме әйбәтләнә генә бара, диделәр. (Сүз формадагы, киселмәгән сыр турында бара.)

...Ихластан сөенеп чыктык Теләче сыр-май комбинатыннан. Ният булгач, эшләргә кешесе, кулланучысы да табылган. Кайчандыр йозак элнгән заводның әнә шулай тулы көченә эшли башлавы район гына түгел, республика өчен дә зур вакыйга, шатлык. Аның чибәр җитәкчесенә, уңган эшчеләренә тагын да зуррак уңышлар теләп калабыз.

ТАТЬЯНА РЕЧКУНОВА: «ТРАНСФОРМАЦИЯ КҮП ОЧРАКТА КОМАНДАГА ДА, АНЫҢ ҖИТӘКЧЕСЕНӘ ДӘ КИРӘК»

Психолог, коуч һәм Татарстанның HR-берлеге координаторы эш дәрте, Саклык банкының тормыш мәктәбе, тулы бер компанияләрне үзгәртеп корырга ярдәм итә торган туры сүзлелек турында сөйли.

ҖӘЛЕП ИТ ҺӘМ САКЛАП КАЛ

Персонал белән идарә итү өлкәсендә заманча трендны мин «сыйфатлы» кадрлар өчен көрәш бара» дигән сүзләр белән тасвирлар идем. Әйе, андый хезмәткәрләр күп түгел. Аларны ничек табарга, ә аннары компаниядә ничек саклап калырга – иң көнүзәк мәсьәләдер бу, мөгаен. Хәзер эш бирүчеләр озак эшләргә теләк тудыра торган шартлар булдыру турында уйлана, well-being* пакетларын гамәлгә кертә башлады. Алар яңа корпоратив культура формалаштыру кирәклеген һәм бу процессның тиз генә эшләнмәвен аңлый. Мондый мөнәсәбәт хөрмәт уята.

Компания хуҗалары һәм генераль директорлар, бизнестагы яңа максатларга ирешү өчен таләп ителгән идарәчелек компетенцияләрен һәм җитәкчеләр командасын үстерү нияте белән, мине көннән-көн ешрак чакыра. Бу – этаплап башкарыла торган эш. Мин диагностикадан башлыйм, команданың нидән гыйбарәт икәнен аңларга тырышам. Киләчәктә шуларга таяну өчен, аның уңай якларын да, һәм, эш барышында исәпкә алып, төзәтмәләр кертү максатында тискәре тарафларын да ачыклыйм. Ә аннары команда һәм стратегия сессияләрен, күнекмәләр тренингларын һәм акыл штурмнарын, шәхси консультацияләрне башлыйм... Бу – бик колачлы, зур процесс, анда барысы да, шул исәптән заказ бирүче үзе дә катнаша, чөнки трансформация күп очракта командага да, аның җитәкчесенә дә кирәк.

ЫШАНЫЧ ТУРЫНДА

Беләсезме, бүген хезмәт коллективларында нинди тенденция бара? Җитәкче кеше компаниягә персонал белән бәйле бурычларны хәл итү өчен берәр белгеч чакырганда, хәзер хезмәткәрләр куркуга төшми. Элек реакция башка: «Әгәр ул нәрсә дә булса казып чыгарса?!» – дип уйлыйлар иде. Юк, бүген хезмәткәрләр мөмкин кадәр туры сүзле һәм ачыктан-ачык сөйлиләр. Алай гына да түгел, проблема ачыкланыр һәм аны, ниһаять, хәл итәрләр дип көтәләр. Һәм күп очракта без аны табабыз да. Бу проблеманың барлыгын һәркем, шул исәптән җитәкчелек тә, сизгән-чамалаган, әмма аның турында сөйләшү генә булмаган. Без, ниһаять, аны ачып күрсәтәбез, мәсьәләнең ни рәвешле үзен күрсәтүенә һәм нәрсәләргә тәэсир итүенә карыйбыз.

Гадәттә, эш башында клиентка сорау бирәм: хезмәткәрләр белән әңгәмә вакытында күңелгә бер дә хуш килмәгән нәрсәләр ачыкланса, нишлибез? Әгәр проблеманы иң өске киштәгә салып куярга җыенасыз икән, эшне башларга да кирәкми. Чөнки аннан ни файда? Кул астындагы хезмәткәрләр алдында җитәкчелеккә бер «минус» кына. Компания хуҗасы белән шунда ук килешеп куярга яратам: бер үк хисапнамәне һәр катнашучының шәхсән үзенә җибәрәм, шул исәптән хуҗаның үзенә дә, җитәкчеләргә һәм интервьюда катнашучыларның барысына да. Бу миңа бөтен команданың ышаныч дәрәҗәсен арттыра – һәм без ачыктан-ачык сөйләшә башлыйбыз. Системаның югары баскычы да үзгәрергә әзер икәнлеген аңлагач, кешеләр дә үзләрен яхшырту юнәлешендә эшләргә әзер булуларын белдерә. Шуңа күрә миңа, коуч буларак, җитәкче, хуҗа кеше һәрвакыт үрнәк алу өчен модель булып тора. Биредә әйдәп баручы, үрнәк затсыз бернишләп булмый.

«ДӘРТ-ТЕЛӘК МӨҺИМ!»

Егерме елга якын мин башта Алтайда, аннары Татарстанда Саклык банкының HR-бүлекчәсен җитәкләдем. Хезмәттәшләрем арасында: «Әгәр син Сбербанкта эшләгәнсең икән, сиңа инде берни дә куркыныч түгел!» дигән ярымшаярулы әйтем бар. Саклык банкы мәктәбе, чыннан да, яхшы мәктәп. Мин компаниягә барысы өчен, шул исәптән һәртөрле кыенлыкларга карата куәтле «иммунитет» булдырган өчен рәхмәтле. Шуңа күрә илле ике яшемдә «иректә» тормышка аяк басып, шәхси эшмәкәргә әйләнү минем өчен стресс булмады, моны, дөресрәге, кызыклы сынау дияргә мөмкиндер. «Хәзер дә булмаса, тагын кайчан инде?» – дип кенә уйладым.

Дәрт-теләк белән янып тору мөһим! Бүгенге тормышым мине бик күп кызыклы кешеләр, компанияләр, бизнес-процесслар белән таныштыра, үз белемнәремне эштә куллану гына түгел, һәрвакыт уйланырга, иҗади эш йөртергә мәҗбүр итә. Мин бүген Татарстанның алты йөзгә якын профессиональын үз эченә алган HR-берлегендә координатор вазыйфамны дәвам итәм. Казанның Беренче инженерлык лицеенда психологик хезмәт кураторы булып эшлим, чөнки балалар – киләчәккә кертемебез ул. Психолог һәм коуч буларак, клиентларга шәхси консультацияләр үткәрәм. Кайчагында миннән шундый эшкә сәләтлелекнең сере нидә дип сорыйлар. Бернинди сер дә юк – мин үземә ошаган нәрсә белән шөгыльләнәм.

** well-being пакетлары – хезмәткәрләрнең сәламәтлеген һәм тормыш иминлеген тәэмин итү программалары.*

Фото Татьяна Речкунова архивыннан алынды. РЕКЛАМА

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘРЕ УҢ БУЛСЫН

Яшь, дәртле, матур... **Альбина Сергееваны** күргәч, өлкәннәр һәм инвалидлар өчен «Добрые истории» пансионатлар челтәрен булдыру нияте белән янып йөрүче һәм аны оештыручы нәкъ менә шушы ханым икәнен күз алдына китерүе дә кыен.

– Нигә кирәк бу сиңа дип еш сорыйлар миннән, – дип елмая Альбина ханым. – Стереотип кына ул, башка нәрсә түгел! Мин үзем дә бер тапкыр стереотипка бирелдем – матурлык салоны ачкан идем. Бәхеткә, бу эшнең миңа бернинди рухи канәгатьлек китермәвен бик тиз аңладым, салонны саттым да, бөтенләем белән әбекәйләремә әйләнеп кайттым. Менә бу, чыннан да, минеке! Моның сәбәбе дә бар, чөнки безнең гаилә өчен «Добрые истории» бик шәхси хатирәгә әйләнде.

ИСЕМЕ ҮК КЫЧКЫРЫП ТОРА!

«Миңа монда ошый. Мөнәсәбәт тә, дәвалау да, безне кайгыртулары да... Мин бирегә килгәндә йөри алмый идем, ә хәзер – үз аягымда!» – дип сөйли чәчләренә чал кунган, әмма һаман да энергияле, җитез ханым. Кечкенә генә видеоролик тамашачыларына үз яшен дә әйтә – инде 90 га җитеп килә икән!

«Монда минем белән шөгыльләнә башладылар һәм менә – кулым эшли! Мин барысына да бик рәхмәтле!» – дип елмая объективка шактый яшь ханым. Ул да пансионатта тәрбияләнә.

Бу кадрларны карагач, Альбина Сергеева 2016 елда нигез салган пансионатлар челтәренең ни өчен «Добрые истории» дип аталуы сорау тудырмый.

– Без бу кешеләрнең тормышына уңай үзгәрешләр кертергә тырышабыз, – ди Альбина. – Минем хыялым бар – алар турында чын фильм төшерү. Безнең тәрбиядәгеләр арасында кызыклы шәхесләр бик күп– язучылар, спортчылар, хәрбиләр... Күптән түгел бездә шактый өлкән яшьтәге бер апа кунак булды – аңа 94 яшь! Әмма бу апаның энергиясе, дәрте, физик формасы, яхшы күренү теләгенә яшьләр дә көнләшерлек. Ул көн саен саф һавада зарядка ясый, инде бик күптән якты дөньяны күрүдән мәхрүм булуы да аны туктатмый. Менә тормышка шундый мәхәббәт!

Яшәү теләген ничек саклап калырга, ә кемдәдер ничек кабызып җибәрергә икәнен пансионат үз тәҗрибәсендә белә. Өлкән кешеләр белән озак еллар эшләү, дөньядагы иң нәтиҗәле тәҗрибәләрне һәм яңа фәнни ачышларны өйрәнү Альбинага һәм аның фикердәшләренә геронтологиядә иң заманча ысулларны куллану мөмкинлеге бирә. Мәсәлән, үз пансионатларында алар озак вакытлы тәрбияләү системасын уңышлы гамәлгә кертәләр. Әлеге комплекслы программаның мөһим элементларыннан берсе – өлкән яшьтәге кешеләр һәм инвалидларның тәрбиягә булган ихтыяҗын ачыклау һәм шул рәвешле аларда үз күнекмәләрен мөмкин кадәр саклап калу.

– Әгәр элек карап-тәрбияләп торучы хатын-кыздан барлык гигиена процедураларын – өлкән кешене ашату, киендерү кебек эшләрне тиз-тиз башкарып чыгару таләп ителсә, бүген без мөмкин кадәр күбрәк функцияләрне ул әби-бабайның үзенә калдырырга тырышабыз, – дип аңлата Альбина. – Кулы белән мөстәкыйль эшли аламы? Бик әйбәт, ашасын, кырынсын, киенсен – без моның өчен күпме вакыт кирәк, шулкадәр сабыр гына көтәчәкбез! Бу – мускуллар эшләсен өчен, когнитив сәләтләр саклансын өчен кирәк. Әлеге юнәлештә эшне кешенең сәламәтлеген генә түгел, биографиясен дә өйрәнүдән башлыйбыз. Ул гомере буе нәрсә белән шөгыльләнгән, аны нәрсә мавыктырган? Мондый алымның нәтиҗәсен сез үзегез күрәсез.

СТЕРЕОТИПЛАРНЫ ҖИМЕРЕП

Мондый пансионат ачу нияте Альбинада очраклы гына тумаган. Кызганыч хәл күз алдында, аның туганнары гаиләсендә килеп чыга. Өлкән кешене даими карау зарурлыгы аларның гадәти тормыш рәвешен җимерә, эшләрен ташларга мәҗбүр итә,

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

Фото А. Сергеевадан алынды. РЕКЛАМА

ә көн саен җыела килгән арыганлык акрынлап өметсезлеккә илтә…

– Без бу хәлдән чыгу юлларын эзләдек, – дип сөйли Альбина. – Һәм аны, чит ил тәҗрибәсен өйрәнеп, таптык. Өлкән яшьтәге кешеләр өчен уңайлы, яхшы тәрбия һәм игътибар күрсәтелә торган пансионатлар тарихы анда дистәләрчә еллар белән исәпләнә. Мин бу идея белән кызыксынып киттем! Барлык сорауларга да җавап эзләп, төн йокыларым качты, бу пансионатның иң яхшы европача үрнәктә булуын теләдем. Туганнарым файдалы киңәшләре белән булышты, чөнки безнең гаиләдә педагоглар да, табиблар да бар.

Хәзерге челтәрнең беренче пансионаты бу максатта тулысынча җиһазландырылган кечкенә коттеджда ачыла. Төзекләндерелгән территория, уңайлы мохит, өйдәгечә җылылык, игътибарлы персонал... Эш уңай бара, ныгый, үсә башлый. Әлбәттә, әлеге уңышның төп нигезен Альбинаның тырышлыгы тәшкил итә. Ул һәр кешенең тормыш тарихы, авыру-кайгылары белән кызыксына, аларның туганнары белән шәхсән аралаша. Бу вакыт эчендә аңа никадәр иллюзия һәм стереотипларны җимерергә туры килә! Өстәвенә, читләрнекен генә түгел, үзенекен дә.

– Минем башымда тулысынча идеальләштерелгән манзара иде: аралашучан, игелекле холыклы өлкән кешеләр ниндидер иҗат белән шөгыльләнә, кызыклы аралашуга шатлана, – дип искә ала Альбина. – Тик иллюзия чынбарлыкка бәрелеп челпәрәмә килде. Бездә, нигездә, когнитив тайпылышлары, терәк-хәрәкәт аппараты проблемалары һәм сәламәтлегендә башка җитди кимчелекләре булган кешеләр тәрбияләнде. Кыскасы, аларны җитди тәрбияләп-күзәтеп, даими карап торырга кирәк.

Өстәвенә, Альбина шөгыльләнергә карар иткән эшчәнлеккә карата җәмгыятьтә мөнәсәбәт шактый четерекле. Бүген дә вазгыять әллә ни үзгәрмәде әле.

– Әнине, әбине пансионатка урнаштыру, димәк, үз әти-әниеңне картлар йортына олактыру дип кабул ителә. Әнә шундый борынгы стереотип яши бездә. Бу – Россия җәмгыятенең чын-чынлап авырткан урыны, – ди Альбина. – Әле күптән түгел генә бер ир-ат шылтыратты: тавышында кайгыборчу, шик сизелә, ул нәрсә эшләргә, алга таба ничек яшәргә белми... Безнең кебек пансионатларның ничек эшләве турында бик азлар гына сөйли, бик азлар гына күрсәтә. Монда бик зур мәгърифәтчелек эшчәнлеге кирәк.

Альбина сүзләренең һәм эшенең сыйфатын иң кадерле кешеләре – үз туганнары белән раслый. Аның яраткан әбисе Түбән Камадагы «Добрые истории» пансионатында тәрбияләнүчеләрнең берсе була. Әйе, аларның гаиләсе дә өметсезлек халәте белән күзгә-күз очраша, тик, бәхеткә, алар иде нишләргә кирәклеген белә, чөнки «Добрые истории» ул вакытка, барыннан да элек пансионатларны оештыручыларның үзләренә, ниятләрнең иң яхшы рәвештә тормышка ашырылганын раслаган була!

Бүген пансионатлар челтәре – гаиләнең уртак эше. Альбинага аның ире, әтисе, сеңлесе кушыла. Алар бу идея белән бергәләп янып йөри, фикердәшләр туплый. Геронтология өлкәсендә бергә зур мәгърифәтчелек эше белән шөгыльләнәләр. Мәсәлән, деменциянең нәрсә икәнен, аның беренче билгеләрен ничек танып алырга һәм ни рәвешле вакытында кисәтергә кирәклеген киң аудиториягә аңлатырга тырышалар. Еш кына бу мәгълүмат өлкән кешеләрнең туганнары өчен чын ачыш була, әби-бабайларның «картлык кирелеге»нә башка яктан карарга, өлкәннәр белән нәтиҗәлерәк аралашырга, бу кирәкле белемнәрне исәпкә алып, көнкүрешне үзгәртеп корырга мөмкинлек бирә.

– Кызганыч, безнең җәмгыятьтә өлкән яшьтәге кешеләр темасы һаман да үзенә күрә тыелган пәрдә артында, – ди Альбина. – Ә бүген шәхси генә түгел, хәтта дөньякүләм җитди проблемага әйләнгән когнитив тайпылышлар турында илебездә күптән түгел генә сөйли башладылар. Еш кына андый авыруларның туганнары бу кайгыларын ялгыз гына җиңеп чыга алмый, алар җәмгыять тарафыннан гаепләнүдән курка һәм безгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүне суза. Ә чит илдә бу эш киң таралган, ул өлкән яшьтәге кешеләргә уңайлы, кызыклы тормыш белән яшәргә, квалификацияле ярдәм алырга, ә аларның туганнарына үзеңне җәфа-изалардан коткарып, җиңел сулап куярга булыша.

Агарту-мәгърифәт өлкәсендә эш Альбинага әле бик озак вакытка җитәчәк, шуңа да карамастан, аның хезмәт җимешләрен инде бүген үк тоемлап була. Еш кына аларның пансионатларына чираттагы еллык ял вакытына өлкән яшьтәге туганнарын калдырып торырга дип мөрәҗәгать итәләр. Ышаныгыз, проблемаларны онытып, ике-өч атна ял итү алар өчен күкрәк тутырып бер сулыш алу кебек, шул да тормышка оптимизм өсти. Көтелмәгән хәлләр була: кайчак, әйтик, вакытлыча тәрбияләнүчеләр мондый ялдан соң аларны яңадан пансионатка илтеп куюларын сорый. «Сездә күңеллерәк, аралашу да күбрәк!» – ди алар.

– Безнең командага сыналган кешеләр генә эләгә, – дип ышандыра Альбина. – Елмаюлы йөзле, кайгыртучан тәрбияче ханымнардан тыш, үз терапевтлары да, шәп аниматорлары да бар. Пандемиягә кадәр безгә концерт, спектакльләр, осталык дәресләре белән шулкадәр күп волонтер килә иде, янәшәбездә игелекле кешеләр күпме икәнен белсәгез! Без хәзер дә, карантин вакытында да, күңелсезләнеп ятмыйбыз. Халыкның аң-белемен күтәрү, дәвалау физкультурасы, ялны оештыру мәсьәләләрендә төрле интернет-мәйданчыклар белән хезмәттәшлек итәбез, #мывместе һәм «Бабушка-online» проектларында актив катнашабыз. Безнең тәрбиядәге әби-бабайлар өчен мондый формат уңышлы булмас дип уйлаган идек башта. Тик, беләсезме, тәҗрибә күрсәткәнчә, теләсә кайсы кешегә ачкыч табарга мөмкин икән. Бигрәк тә, моңа теләгең булганда. Ә бездә андый теләк бар, чөнки бу эшнең безгә билгеләнгән юл икәненә ышанабыз!

ХАТЫН-КЫЗГА НИ КИРӘК?

«Ирең белән әрләшүдән ничек туктарга?», «Бизнес һәм гаиләне ничек бергә алып барырга?», «Ни өчен мин теләгемә ирешә алмыйм?»– бу сораулар бик күп гүзәл затларның көн дә башын катыра. Әнә шуңа күрә Чаллы кызы Ләйсән Хәбибрахманова хатын-кызлар клубы оештырып җибәрә, чөнки сорауларга җавап эзләгәндә, иң мөһиме – ярдәм кулы сузу.

– Беренче чиратта – эзлеклелек, дисциплина кирәк. Тәртип юк икән, һичнәрсә бармый, – ди алып баручы. Клуб әгъзалары уңайлы кафеда утыра, ә читтән чакырылган белгеч аларга финанс грамоталылыгы турында сөйли. Гаилә бюджеты – бер нәрсә, ә үз проектың өчен акча эзләү – бөтенләй башка. Бизнес, финанс, маркетинг мәсьәләләренә багышланган даими очрашулар – Ләйсән Хәбибрахманова клубын бүтәннәрдән аерып торган үзенчәлек. Хатын-кызның эшлекле мохиттә үз урынын таба белү темасын ул иң мөһимнәрдән берсе дип саный.

КӨНДӘЛЕК ТӨССЕЗЛЕКТӘН – АЧЫШЛАРГА

– Берәүләр эшмәкәр буларак үз юлын табарга, икенчеләре күңелле вак-төякләр өчен үзләрен өстәмә хезмәт хакы белән тәэмин итәргә тели. Әмма моңа керешеп китү өчен күпләргә тәвәккәллек җитми. Шуңа күрә мин нетворкинг форматында очрашулар үткәрергә булдым, анда һәр кунак үз идеяләре белән уртаклаша, үз бизнесын яки күрсәтә торган хезмәтләрен тәкъдим итә ала, киңәш, ярдәм сорарга, потенциаль клиентлар аудиториясен һәм фикердәшләрен дә табарга мөмкин, – ди Ләйсән Хәбибрахманова. Берничә ел элек ул, укып, коуч дипломын ала һәм хәзер, клуб эшеннән тыш, консультацияләр үткәрә, клиентларга инде үзләрендә булган мөмкинлекләр, беренче чиратта – интеллектуаль һәм коммуникатив ресурслар нигезендә максатка таба хәрәкәт планын төзергә ярдәм итә.

Үзара мөнәсәбәтләрдән башлап, базарда үз брендыңны үстерүгә кадәр теләсә нинди мәсьәләләр хакында фикер алышып, файдалы һәм рухландыргыч җавап алып була торган хатын-кызлар берләшмәсе – Ләйсәннең

чынга ашкан хыялы. Әмма бу хыялга юл җиңелләрдән булмый.

Беренче белеме буенча Ләйсән – акушер-гинеколог. Чаллыга ул ире белән 2013 елда күчеп килә. Шәһәр поликлиникасына эшкә урнаша. Аннары икенче баласы белән декрет ялына китә. Ә аннары күпләргә таныш халәт – һәр узган көн кичәгесенә охшаган, бертөрлелек, тилерткеч көндәлек мәшәкатьләр.

– Кайсыдыр мизгелдә үземнең элекке эшемә әйләнеп кайтырга теләмәвемне аңладым. Мин нишләргә белмәдем, депрессия башланды. Иремнән башка мине һичкем тыңламый да, булышмый да иде – әнә шунысы тагын да авыррак, – дип искә ала Ләйсән. Бервакыт танышы аңа онлайн-тренингларны челтәрле сату программасында катнашырга тәкъдим итә. Ләйсән ризалаша. Программага башта клиент сыйфатында, аннары инде партнер буларак кереп китә. Программа кушымтасында шәхси үсеш тренинглары вебинарларын өйрәнергә тәкъдим ителә. Кыз аларны йотлыгып карый. Күп кенә идеяләр аңа бик якын булып чыга. Ләйсән, әйтерсең, үз тормышына, үз мөмкинлекләренә бөтенләй башка күз белән карый. Компаниядә ул озакламый уңышка ирешә, тик сатучылык баскычыннан бик тиз югары күтәрелә. Ни дә булса үзенекен булдыру теләге туа.

– Әйләнә-тирәмдә көндәлек мәшәкатьләргә, көнкүреш вак-төягенә башы-аягы белән чумган, үз-үзләре белән шөгыльләнү мөмкинлеген һәм теләген югалткан бик күп хатын-кызларны күрә идем, – ди Ләйсән. – Ләкин безнең һәркайсыбыз кабатланмас, тиңсез шәхес, без бит бәхетле булу һәм янәшәдәгеләрне бәхетле кешеләр итү өчен туган. Үзара ярдәм, кызыксындырып җибәрү, илһам – боларның барысын да без, хатын-кызлар, бер-беребезгә бирә алабыз.

Героебыз хатын-кызлар өчен офлайн чаралар үткәрә башлый. Акрынлап аларда даими катнашучылар төркеме барлыкка килә. 2019 елның көзендә Чаллыда Ләйсән Хәбибрахманова тантаналы рәвештә хатын-кызлар клубын ачып җибәрә.

БАШ РОЛЬ

Өстәлгә матур уен кыры җәеп салынган. Хатын-кызлар чиратлап шакмакны ташлый, ул күпме кристаллны алырга яки бирергә кирәклеген күрсәтә. Уенчылар алдындагы карточкалар кристалларны югалту яки арттыру мөмкинлеге бирә торган тормыш хәлләрен күрсәтә. Уенда алар энергияне гәүдәләндерә. Уен кырында сигез роль сурәтләнгән, һәм катнашучылар аларның һәркайсында уйнап карарга тиеш. Мондый трансформацияле уен хатын-кыз башкара торган төрле рольләрнең хәзерге заманда тулы канлы рәвештә бергә яшәвенең психологик методикаларына нигезләнгән.

– Без еш кына бер нәрсәгә артык игътибар бирәбез. Ир-ат белән мөнәсәбәттә үз урыныбызны билгеләргә маташабыз яки үзебезне тулысынча балаларга, һөнәри үсешкә, карьера төзүгә багышлыйбыз, – ди Ләйсән. – Ул вакытта башка сыйфатларыбыз кулланышсыз кала, ә яратырга, эшләргә, яңага омтылырга көч һәм теләк булсын өчен, безгә гармония кирәк.

Ләйсән – уен техникасы һәм уен практикасын куллануда сертификацияле белгеч. Ул үзе һәм аның коллегалары клуб әгъзалары өчен дә, барлык теләүчеләр өчен дә трансформацияле уеннар үткәрә. Уен мохитенә чумганда, кеше үзенең төрле сәбәпләр белән арткы планга күчкән сыйфатлары белән күзгә-күз очрашу мөмкинлеге ала. Клуб чаралары программасын Ләйсән хатын-кыз тормышының һәр тарафын колачларлык итеп төзергә тырыша: монда кулинария, макияж буенча осталык дәресләре, диетологлар, психологлар,физик сәламәтлек буенча белгечләрнең сессияләре, ниһаять, матур урыннарда йөреп кайту һәм киного бару бар – клуб тормышы кайнап тора. Хәзер анда 60 тан артык хатын-кыз исәпләнә, әмма очрашуларга һәркем үзенчә йөри. Кемдер айга берничә тапкыр, кемдер ярты елга бер тапкыр килә.

– Җәен без кызлар белән спа-бәйрәмнәр үткәрәбез. Гадәттә, җомга көнне, чөнки бу – Венера планетасы көне, атна азагы, иң мөһим эшләр инде хәл ителгән һәм ял итә аласың. Чынлыкта, моны өйдә дә эшләргә була. Бөтен кирәк нәрсә– шәмнәр, ванна һәм хуш исле тоз, – ди Ләйсән. – Бу атмосфера көч-куәтне кайтарырга, хисләрдән бушанырга, тынлыкта ял итеп алырга булыша. Хатын-кыз судан Венера алиһә кебек гүзәл һәм көч-дәртле булып чыга. Ә бу бик мөһим, чөнки нәкъ менә хатын-кыз гаиләне җылылык һәм мәхәббәт белән тәэмин итеп тора. Җәмгыятьнең цифрлы трансформациясе һәм күп полярлыгы чорында психология, физиология һәм социологиянең төп принципларын беркем дә кире какмады әле.

Ләйсән үзе гел хәрәкәттә – коучинг консультацияләре алып бара, спикерлар белән килешүләр төзи, «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» ассоциациясе чараларында катнаша, клуб әгъзалары белән аралаша һәм үзе дә төрле курсларга, тренингларга йөри.

– Бүген безгә эш бик күп өелгән. Без һәрвакыт ашыгабыз, йөгерәбез, бер үк вакытта берничә эш башкарабыз, безгә зур җаваплылык йөкләнгән, – ди героебыз. – Ә кайчагында үзебезгә ошаган кафега керәсе, кофе алып, һични турында уйламыйча, борчылмыйча бераз утырасы килә. Әгәр сез миннән бүген хатын-кызларга ни кирәк, алар нәрсә тели дип сорасагыз, җавабым бик гади булачак. Хатын-кыз супергерой булудан туктарга һәм гап-гади хатын-кыз булырга тели. Сөйкемле, ягымлы, назлы, кайчагында яклауга да мохтаҗ хатын-кыз. Әмма безгә моны өйрәнәсе бар әле.

Чаллыда Ләйсән Хәбибрахманованың хатын-кызлар клубы аккаунты: @womens_club_chelny @leisan_habibrahmanova

Фото Ләйсән Хәбибрахмановадан алынды. РЕКЛАМА

КРИСТИНА ПЛАТОНОВА: «МИН БАРЫ ТИК ГАИЛӘ ДИНАСТИЯСЕН ДӘВАМ ИТТЕМ ГЕНӘ»

«Бизнес Решения»* компаниясен гамәлгә куючы һәм директоры – һөнәре, заман һәм үзе турында

ХИСАПЧЫ – ИҢ КҮҢЕЛСЕЗ ҺӨНӘРЛӘРНЕҢ БЕРСЕМЕ?

Хисапчылык – ул эчпошыргыч эш, ә хисапчылар барысы да җитди чырайлы кешеләр дигән стереотип яши инде. Әмма бу бөтенләй алай түгел. Монда торгынлык бөтенләй булмый. Икътисадый вазгыять шулкадәр тиз үзгәрә ки, яңа кагыйдәләр иясә законнарга яңа төзәтмәләр кереп кенә тора. Мин ай саен нәрсәгә булса да өйрәнәм – вебинарлар, семинарлар, форумнар, очрашулар, бер сүз белән әйткәндә, һәрвакыт хәрәкәттә.

НИ ӨЧЕН МИН БУ ҺӨНӘРНЕ САЙЛАДЫММЫ?

Минем алда һөнәр сайлау мәсьәләсе тормады, мин гаилә династиясен дәвам иттем генә. Әнием һәм әбием баш хисапчы булып эшләделәр, мин дә алар үрнәгенә иярдем. Бала чактан ук зур-зур ЭВМнарны һәм бер кочак хисап кәгазьләрен хәтерлим. Алар кебек үк кабинетта утыруымны һәм эшемнең бик мөһим булуын күз алдына китерә идем. Казан финанс-икътисад институтын тәмамлаганнан соң, эшкә кердем, ә дүрт ел элек хисап эшенең тулы исемлеген тәкъдим итә ала торган үз фирмамны ачтым.

НИЧЕК БЕЗНЕҢ КЛИЕНТКА ӘВЕРЕЛЕРГӘ

Әгәр берничә ел элек безгә яңалар кемнеңдер тәкъдиме буенча килсә, бүген инде безнең турында күбрәк мин исәп-хисап темаларына блоглар алып бара торган мессенджерлардан беләләр. Үзем эксперт сыйфатында чыгыш ясый торган интернет-платформаларда һөнәри тематика буенча бик күп язмаларым бар. Мин «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» берләшмәсендә торам, без очрашуларда бизнес яңалыклары буенча фикер алышабыз, тәҗрибә уртаклашабыз, киңәшләр бирәбез. «Ак Барс Лабс» эшкуарлар клубына да йөрим, бу шулай ук файдалы бизнес-очрашулар, яңа танышлыклар дигән сүз. Клиентлар һәм партнерларымның минем турыда «Кристина – шәп хисапчы!» дип әйтүен ишетү бик күңелле. Мин яңа хезмәттәшлеккә һәрвакыт әзер.

БИЗНЕС, ОЧРАШУЛАР, ГАИЛӘ. НИЧЕК ӨЛГЕРЕРГӘ

Ноутбугым гел үзем белән һәм клиентларым өчен мин һәрвакыт онлайн. Төшенкелеккә бирелергә тырышмыйм. Әгәр авырлыклардан һәм проблемалардан барыр урын калмый икән, җиңемне сызганып аларны хәл итәргә тотынам. Мин бик энергияле кеше һәм тормышны яратам. Сүз уңаеннан, үземнең ике улымны да тормышка оптимизм белән карарга өйрәтәм.

МИНЕМ ИҢ ДӨРЕС ЯЛЛАРЫМ

Ул якшәмбе көн, малайлар белән озаграк йоклый алабыз, чөнки башка көннәрдә мәктәп, балалар бакчасы, өй эшләре, телләр өйрәнү. Күптән түгел генә бөтен гаиләбез белән бокска йөри башладык. Башта олы улым шөгыльләнә башлады, аннан кечкенәсенең йөрисе килде, алардан соң минем дә үземне сынап карыйсым килде – ошады. Беләсезме, бокс «пар чыгару» һәм яңа энергия туплау өчен менә дигән ысул икән.

КИЛӘЧӘККӘ ПЛАННАРЫМ

Катлаулы мәгълүматны җиңел тел белән аңлата алам, шуңа күрә хисапчылык буенча онлайн курслар ачып җибәрәсем килә. Офлайн форматта зур аудитория каршында уза торган чараларда спикер ролендә чыгыш ясарга планлаштырам. Бер сүз белән әйткәндә, планнар тау кадәр! Килешәсездер, исәп-хисап һәрвакыт булды, бар һәм булачак. Чөнки базар шартлары үзгәреп тора, бизнесның яңа юнәлешләре пәйда була, димәк, хисапчы хезмәте дә һәрвакыт кирәк булачак. Т

* «Бизнес Решения» компаниясен исәп-хисап ясау, финанс аудитын үткәрү, юридик хезмәт күрсәтү һәм салымнар буенча консультацияләр бирү эшләрен башкара.
Тел. 8-967-463-47-77

Фото В. Кулаев. РЕКЛАМА

ҮЗ-ҮЗЕН ИЯРЛИ АЛГАН ДӨНЬЯ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТӘ

Татарстанның «Ментор» коучинг академиясе кеше өчен төп байлыкларның берсе – үз тормышың белән идарә итү ирекен табарга ярдәм итә.

Академиягә нигез салучы **Анастасия Гыйльманурова** бу юлны камилләшү турында әле берән-сәрән кеше генә уйланган чорда уза. Чаллының мәктәпкәчә белем бирү системасында күп еллар эшләгәч, Анастасия бервакыт алга таба үсәргә теләвен аңлый.

– Мәгълүматы булган зат дөнья белән идарә итә. Мин нинди дә булса гаҗәеп мәгълүмат алырга теләдем. Мин һәрвакыт иң алдынгы курсларда укыдым. Ул вакытта шәхси үсеш тренинглары иде алар. Билгеле бер вакытта мин башка кешеләргә тормышта нәрсәдер үзгәртергә, аларга чынлыкта үзләре теләгәнчә яшәргә мөмкинлек бирү өчен белемем җитәрлек икәнен аңладым. Мин нәкъ менә шуның белән шөгыльләнәчәкмен дип ниятләдем, – ди Анастасия. Ире аның карарын тулысынча хуплый һәм 2005 елда алар бергәләп «Ментор» академиясен оештыра. Хәзерге вакытта ирле-хатынлы Гыйльмануровлар, сертификацияләнгән коучлар булып, академиядә укыта һәм шәхси консультацияләр алып бара.

Академия Татарстанда коучларны укыта торган беренче лицензияле белем бирү оешмасы була. Академия базасында Анастасия Гыйльманурова һәм аның коллегалары республикада беренче ICBT халыкара бизнес-тренерлар мәктәбен ачып, уен техникасы һәм уен практикасын куллану нигезләрен укыта башлый. 2018 елда «Ментор» кече һәм урта бизнес оешмаларының «Алтын йөзлек» республика конкурсының «Хезмәт күрсәтү өлкәсе» номинациясендә җиңү яулый. Академия портфолиосында һөнәри һәм шәхси үсеш буенча берничә эчтәлекле программа бар.

Коучинг һәм менторлык уку йортының принципиаль юнәлешләре булып кала. Ментор белгеч кеше мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмый торган төрле кризис халәтләрен, читен хәлләрне, стрессны кичерүдә ярдәм итә. Коуч белгеч шәхеснең яшерен ресурсларын ачыкларга һәм бу ресурсларны шәхси һәм бизнес-максатларны аңлауга, аларны тормышка ашыру юлларын табуга юнәлтергә булыша. Академиядә укучылар коуч һөнәре нигезләрен үзләштерә, киләчәктә бу уникаль белем базасын коучингның аерым тар юнәлешләрендә камилләшү өчен куллана ала.

Программаларны эшләгәндә, «Ментор» белгечләре клиентларның ихтыяҗларына, социумда барган инновацияле алымнарга һәм процессларга йөз тота.

– Технологик яктан караганда, без зур-зур адымнар белән хәрәкәт итәбез. Тик психик һәм физиологик яктан йөз ел элек нинди булганбыз, шундый ук диярлек булып калабыз. Шуңа да еш кына көч-хәлебез җитеп бетми. Яңа үрләргә омтылып, максатка ирешкәч ничек яшәргә кирәклеген онытабыз, хис-кичерешләр упкынына эләгәбез. Профессиональ, эмоциональ яктан яну-көю – зур компанияләр өчен дә, шәхси эшмәкәрләр өчен дә көнүзәк тема. Соңгы вакытта безгә нәкъ менә шундый мәсьәләләр белән ешрак мөрәҗәгать итәләр, – ди Анастасия. Ул үзе җитәкче, остаз, хатын, дүрт кызның әнисе һәм әби ролен бергә бик көйле башкара һәм әйткәннәре гамәленә туры килә торган профессионал образын гәүдәләндерә.

Даими үсеш өчен профессионалларга фикердәшләр белән аралашу кирәк, шуңа күрә «Ментор» үзләрендә укып чыккан белгечләр белән очрашулар, төрле семинарлар һәм башка чаралар уздыра. Күптән түгел академия «Ментор»ның даими конкурсын оештырган. 2021 елда Татарстан компанияләренең 40 белгече менторлык һәм осталык технологияләрен кертү буенча үз проектларын тәкъдим иткән, 6 җиңүче билгеләнгән. Республикада профессиональ коучлык хәрәкәтен киң җәелдерү өчен, Анастасия киләчәктә дә бу юнәлештә эшләргә ниятли.

«Ментор» академиясе Татарстанда 17 елдан артык эшли. Бу вакыт эчендә биредә 1,5 меңнән артык коуч, ментор, бизнес-тренер, уен техникасы белгечләре, остаз белем алган. Коучлыкка укыту Халыкара коучинг федерациясе программасы буенча алып барыла. Тренерлар исә ICBT бизнес-тренерлары мәктәбенең (Мәскәү) эксклюзив программасы буенча укытыла. Академияне тәмамлаучылар һөнәри әзерлек турында диплом һәм уку-укыту программаларын узу сертификаты ала. Академиянең партнерлары арасында «Аудэкс», «Мегафон», ICL, X5 Group, «ТМС групп», «Корд Оптика» компанияләре, «Этажи», «Флэт» агентлыклары һәм башка тармаклардагы әйдәп баручы ширкәтләр бар.

Фото Анастасия Гыйльмануровадан алынды. РЕКЛАМА

«БЕЗ БӨТЕН КРИЗИСЛАРНЫ ДА ҮТТЕК, ҺӘМ БЕЗГӘ БЕРНӘРСӘ ДӘ КУРКЫНЫЧ ТҮГЕЛ»

Гөлнара Шәйхетдинова, 2003 елдан «ПЕЧАТЬ-СЕРВИС-XXI ВЕК» ЖЧЖ компаниясе – гаилә нәширлек бизнесын җитәкли.

НИ ӨЧЕН НӘШИРЛЕК ЭШЕ?

Белемем буенча мин физика һәм информатика укытучысы. Педагогика университетын тәмамлаганнан соң, берничә ел мәктәптә эшләдем. Ләкин язмыш мине университет типографиясе базасында эшләгән зур нәшрилек компаниясенә алып килде. Шунда мин булачак ирем белән таныштым, ул Татарстан Республикасы районнарына RISO минитипографияләрен кайтару белән шөгыльләнә иде. Кыскасы, үз эшебезне башларга ниятләгәндә нинди юлны сайлаячагыбыз ачык иде.

БАШЛАП ҖИБӘРҮ АВЫРМЫ?

Бүген яшь эшкуарларга дәүләт тарафыннан зур ярдәм күрсәтелә – укыту, грантлар, остазлык, форумнар, очрашулар. Элек боларның берсе дә юк иде.

Яңа эш башлау беркайчан да җиңел булмый, әмма без барысын да җиңеп чыктык. Эшкуарлык нигезләрен өйрәндек, дус типографияләр белән тәҗрибә уртаклаштык, яңа элемтәләр булдырдык, күтәрелдек һәм үстек. Үз типографиябез базасында нәшрият ачтык, соңрак мөһер һәм штамплар эшләү юнәлешен дә үзләштердек.

ТИПОГРАФИЯГӘ НИНДИ ХЕЗМӘТЛӘР СОРАП МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ БУЛА?

Без бик күп төрле хезмәт күрсәтәбез, ләкин төп юнәлеш – китаплар бастыру. Без рус, татар һәм инглиз телләрендә язылган фәнни һәм матур әдәбият юнәлешендәге 1000 нән артык исемдәге китап, методик һәм уку әсбаплары бастырдык.

Без клиентларга карап эш йөртәбез: корпоратив (предприятиеләр, вузлар, мәктәп һәм балалар бакчалары) заказчылар белән дә, шәхсиләре белән дә эшлибез. Журналлар, каталоглар, брошюралар, визиткалар, монографияләр, шигырь һәм хикәяләр җыентыклары да бастырабыз.

Мәсәлән, хәзер шәҗәрәләр бастыру бик популяр – бәйрәмнәргә, гаилә тантаналарына, юбилейларга менә дигән бүләк. Кешеләр үз тамырларын, ата-бабаларын, туганнарын, аларның биографияләре, тарих, фотографияләрен табалар. Мондый шәҗәрә һәр битендә аерым бер гаиләнең тарихы чагылыш тапкан китап кебек бик саллы күренә.

Безгә районнардан, авыл һәм шәһәрләрдән киләләр. Безнең фишка – кечкенә тиражлар бастыру. Бөтен типографияләр дә кечкенә күләмнәргә теләп алынмый. Бездәге җиһазлар һәм тәҗрибәбез сыйфатлы басмаларны зур булмаган тиражлар белән чыгарырга мөмкинлек бирә. Клиентларыбыз һәрвакыт безнең эштән канәгать кала.

СЕЗ ҮЗ ЭШЕГЕЗНЕ ЯРАТАСЫЗМЫ?

Кызларым да еш кына миңа әлеге сорауны бирә. Әйе, яратам! Миңа гамәли хезмәт ошый. Мин үземнең китап продукциясен җитештерүгә турыдан-туры катнашлыгым булу белән горурланам. Үз клиентларыма файда китерә алуыма шатланам.

Кызларымны да үз куллары белән нәрсә дә булса эшләргә өйрәтәм. Җәйге каникулда алар еш кына безгә ярдәм итә, кызларым өчен бу тәҗрибә һәм вак-төяккә акча эшләп алу.

Олы кызыбыз Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясендә укый, психолог булырга әзерләнә, кечесе быелдан 131 нче лицейда белем ала – икесе дә горурлыгыбыз.

УҢЫШЫГЫЗНЫҢ СЕРЕ НӘРСӘДӘ?

Мин уңышымның сере туктаусыз үсүдә дип уйлыйм. Мин укырга, яңа белем һәм күнекмәләр үзләштерергә яратам. Мин – гомер буе укый торган кеше. Сертификат һәм дипломнарым белән әллә ничә диварны каплап буладыр. Метафизика, психология белән кызыксынам, эшкуар буларак гел үсәргә омтылам. Әлеге этапта миңа «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» клубында очрашулар бик рәхәт һәм файдалы. Анда без тере форматта үзебезнең компетенцияләрне күрсәтәбез, эшебезне таныту ысулларын, бизнес, мода һәм сәнгать яңалыкларын тикшерәбез.

Һәм инде, әлбәттә, гаиләм һәм дусларымның яратуы һәм хуплавы мине зурдан-зур уңышларга һәм яңа офыкларга этәрә!

Фото: А. Ганиева. РЕКЛАМА

МАХСУС ПРОЕКТ

Татарстан юбилярлары

ЭШТӘ ИҢ МӨҺИМЕ – НӘТИҖӘ

11 март көнне ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Дәүләт Советында «Бердәм Россия» фракциясе җитәкчесе **Юрий Камалтыновка** 65 яшь тула

Рифнур Сөләйманов, «Татэнергосбыт» АҖ директоры:

– Хөрмәтле Юрий Зимелевич!

Республика Дәүләт Советында шактый вакыт бергәләп эшләү дәверендә төрледән-төрле мәсьәләләрне шактый күп хәл итәргә туры килде. Үзегезнең чыгышларыгызда Сез депутатлар корпусы каршына нәкъ менә сайлаучылар наказларын хакимиятнең башкарма һәм муниципаль органнары белән бергәләп мөмкин булганча нәтиҗәлерәк үтәүне өстенлекле бурыч итеп куясыз. Наказларның күбесе әлеге еллар дәвамында республика һәм максатчан программаларны кабул итү юлы белән тормышка ашырылды.

Шул ук вакытта үз эшегездә Татарстан халкына адреслы ярдәм күрсәтүгә күпме игътибар һәм вакыт сарыф итүегез сокландыра. Әлеге ярдәм төрле булырга мөмкин: лифт ремонтлау яисә авыл мәктәбе өчен җиһазлар сатып алу, әмма күләменең нинди булуына карамастан, әлеге эшләр әһәмиятен җуймый. Депутатлар корпусы эшендә иң мөһиме – нәтиҗә.

Сезнең тирән белемегез, тәҗрибәгез, аралашу осталыгыгыз илнең икътисадый системасында республикабызның әйдәп баручы позициясен саклап калуга, төбәкнең иминлегенә, тормыш сыйфатын күтәрүгә зур өлеш кертә.

Шәхсән үз исемемнән һәм «Татэнергосбыт» АҖ коллективы исеменнән Сезгә, Юрий Зимелевич, ихлас күңелдән партия һәм депутатлык эшләрендә алга таба да уңышлар юлдаш булуын телим! Тарафдарлар һәм фикердәшләрегез, туганнар һәм дусларыгызның хуплавы, ярдәме Сезгә һәрвакытта да яңа идея һәм проектларыгызны башкарып чыгарга көч-куәт биреп, илһам өстәп торсын! Янәшәгездә Сезнең белән бергә бара алырлык лаеклы кешеләр булсын! Эшегездән һәм аның нәтиҗәләреннән канәгатьлек тоеп яшәгез! Бәхет, иминлек, сәламәтлек, иң кыю ниятләрегезнең гамәлгә ашуын телим!

Фото: tatarstan.er.ru

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
facebook.com/protatarstan
twitter.com/protatarstan
БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
instagram.com/protatarstan
Реклама. 16+

ДЕМИДОВ

Татарстан тарихы төбәгебездә туып-үскән, бүген дә аның тарихын язучы шәхесләр язмышыннан тора. Алексей Иванович Демидов – шундый шәхесләрдән берсе. Лаеш районы Урта Девятово авылы халкы үз җирлекләре тарихын аңардан башка күз алдына китерми. Алексеевск районы халкы да үз якларының тарихын аңардан башка күзаллый алмый. Аңардан башка Татарстанда бадминтон спорты тарихы да тулы булмас иде. Татарстан Хисап палатасы тарихы да Демидовтан башка языла алмый... Шуңа күрә бүген Алексей Иванович Демидовның 70 яшьлек күркәм юбилее уңаеннан басмабыз битләрендә туганнары, дуслары, хезмәттәшләре һәм язмышларында аның эзе калган гади кешеләрдән җылы сүзләр, ихлас котлаулар кабул итәбез.

Фотолар Алексеевск муниципаль районы матбугат үзәгеннән алынды.

НАМУСЛЫ ҺӘМ ГАДЕЛ КЕШЕ

Минтимер Шәймиев,
Татарстан Республикасының беренче Президенты

– Иманым камил: теләсә кайсы җитәкче эшчәнлегендә иң мөһиме – кешеләр белән эшләү. Һәркайсыбыз җитәкче булып эшли башлагач, әлеге зур җаваплылыкны тирәнрәк аңлый бара. Минемчә, теләсә нинди рангтагы җитәкче кешеләрне яратырга, аларны тыңлый һәм ишетә белергә, аңларга тырышырга тиеш.

Минем өчен тагын кешенең кайда тууы һәм үсүе, ата-анасының кем булуы да мөһим. Татарларда: «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр», дигән мәкаль бар бит.

Безнең бәйрәмдарыбыз – Алексей Иванович Демидов – үзенең республика иминлеге хакына күп еллар дәвамында фидакарь хезмәте белән мин кузаллаган чын җитәкче сыйфатларының барысына да ия шәхес булуын раслый.

Ул – Лаеш районы Урта Девятово авылыннан, совет чорындагы атаклы «Россия» совхозыннан, республикадагы иң танылган, уңышлы һәм куәтле династияләрдән берсе Демидовлар нәселенең лаеклы вәкиле.

Демидовлар белән күп еллар буе аралашу һәм эшләү тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: нинди генә җәмгыятьтә эшләмәсеннәр, бу – намус династиясе, Ватанга һәм туган җиргә хезмәт итүнең менә дигән үрнәге.

Минем Демидовлар белән танышуым Николай Ивановичтан башланды, 1967-1971 елларда ул Түбән Кама районы башкарма комитеты рәисе иде. Мин, ул чакта партия өлкә комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире урынбасары, Түбән Кама районында еш була, аның белән еш аралаша идем, аннан күп нәрсәгә өйрәндем. Искиткеч эшлеклелек һәм кешелеклелек сыйфатларыннан тыш, мине аның сәнгатьне бик шәп белүе, күренекле Россия шагыйрьләренең әсәрләрен яттан сөйләве сокландыра иде. Безне аның белән озак еллар буе эшлекле һәм дустанә мөнәсәбәтләр бәйләп торды. Николай Иванович озак еллар илнең эчке эшләр органнарында хезмәт итте, Татарстан ЭЭМ башлыгы, СССР ЭЭМ башлыгы урынбасары, РФ ЭЭМ Академиясе җитәкчесе буларак, җинаятьчелеккә каршы көрәшкә, эчке эшләр органнары эшчәнлеген фәнни нигезгә коруга гаять зур шәхси өлешен кертте, көч структураларында күренекле җитәкчеләрнең берничә буынын тәрбияләде. Ул үзен белгән һәм аның белән хезмәт куйган барыбызның да хәтерендә тирән эз калдырды. Уллары Виктор һәм Юрийның да этиләре юлыннан китүе мәгълүм.

Өч энесе дә бөтен республикага танылды – алар бер үк вакытта диярлек партия район комитетларында беренче секретарьлар булып эшләде: Югары Осланда – Юрий Иванович, Лаешта – Анатолий Иванович, Алексеевскида – Алексей Иванович. Шунысы да игътибарга лаек, алар барысы да әлеге югары вазыйфага ул чаклар өчен шактый яшь вакытларында билгеләнде. Юрий Ивановичка 38 яшь иде, аннары ул ТАССР җирле сәнәгать министры булды, «Татарместпром» ААҖ җитәкләде. Анатолий Иванович 35 яшьлек чагында Лаеш районы белән җитәкчелек итә башлады һәм 12 елдан артык туган районы башлыгы булып эшләде, кызганычка, безне бик яшьли ташлап китте...

1983 елда без бик яшь Алексей Ивановичка Алексеевск районын җитәкләүне ышанып тапшырдык. Район белән «адаш» җитәкчегә нибары 31 яшь иде. Аның беренче хисап җыелышына килүемне хәтерлим. Шунда ничек җаваплы эшләвен һәм кешеләрнең аны ничек яратуларын күрдем. Яшь булуына карамастан, мине аның зирәк акылы һәм кешеләрне яратуы таң калдырды. Бу минем хәтердә калды. Нәкъ менә шуңа күрә дә Алексей Иванович анда чирек гасырга якын эшләде. Шунысы сөендерә: бүген Демидовларның Алексеевск белән тарихи элемтәсе кабат яңарды – районның хәзерге башлыгы Сергей Анатольевич Демидов, Алексей Ивановичның абыйсының улы, үз вазыйфасын яхшы башкара. Аның улы Алексей Демидов исә – райондагы уңышлы эшкуарлардан берсе.

Бөтен илдә бюджет финансларын дәүләт контролендә тотуның яңа формасы кертелгәч һәм Хисап палаталары төзелгәч, республикабызда да ТР Дәүләт Советының парламент контроле комитеты урынына Хисап палатасы оештырылды. Без аны Сергей Вадимович Степашин җитәкләгән Россия Федерациясе Хисап палатасы белән тыгыз хезмәттәшлектә булдырдык. Шунысы хәтеремдә: ТР Хисап палатасы турында ТР законын мин аның катнашында, 2004 елның 7 июнендә республика Дәүләт Советы депутатлары белән очрашуда имзаладым.

2004 елның июлендә ТР Дәүләт Советы утырышында мин республика Президенты буларак Хисап палатасы рәисе вазыйфасына Алексеевск районы хакимияте башлыгы Алексей Демидов кандидатурасын тәкъдим иттем. Шунысын әйтергә тиешмен: әлеге яңа һәм үтә җаваплы урынга билгеле бер тормыш тәҗрибәсе туплаган җитәкче генә түгел, ә тагын да мөһимрәге – намуслы һәм гадел кеше кирәк иде. Алексей Иванович исә нәкъ шундый шәхес. Без дөрес кешене сайлаганбыз булып чыкты – ул хәзергә кадәр шул вазыйфасында хезмәт куя.

Хөрмәтле Алексей Иванович!

Ихлас күңелемнән, зур ихтирам белән Сезне 70 яшьлек юбилеегыз белән тәбрик итәм һәм иң изге теләкләремне җиткерәм!

Фото Татарстан Дәүләт киңәшчесе матбугат үзәгеннән алынды.

1

2004 елның 5 июле. ТР Алексеевск районы халык депутатлары Советының чираттан тыш сессиясе. ТР Хисап палатасы рәисе постына билгеләнгән Алексей Демидов урынына администрациянең яңа башлыгы итеп Владимир Козонков сайлана.
Сулдан уңга:
Владимир Козонков, Минтимер Шәймиев, Алексей Демидов.

2

Казан, 2008 елның 28 июле.
Сулдан уңга:
ТР Президенты Минтимер Шәймиев, ТР беренче вице-премьеры Равил Моратов, ТР Хисап палатасы рәисе Алексей Демидов, РФ Хисап палатасы рәисе Сергей Степашин.

«УЛ ЭШЛӘДЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, УЛ ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ ИТТЕ»

2004 елның 4 июлендә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев катнашында узган Алексеевск район Советы сессиясендә депутатлар район башлыгын Татарстан Республикасы Хисап палатасы рәисе вазыйфасына изге теләктә озата.

«Ул эшләде генә түгел, ул халыкка ХЕЗМӘТ ИТТЕ!» – ди ул вакытта Бөек Ватан сугышы ветераны Сөләйман Гарипов.

«Чыннан да шулай булды бит», – дип раслый район халкы да.

Бу бүген дә шулай.

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН

Бүгенге Алексеевск районы 1980 нче еллар уртасында ныклы үзгәреш кичерә башлый. Тирән үзгәрешләр тормышның бөтен өлкәләренә дә кагыла: икътисадка да, социаль тармакка да. Әлеге казанышларны алексеевскилылар ул чакта районны җитәкли башлаган Алексей Иванович Демидов исеме белән бәйли. Күп еллар үтүгә дә карамастан, районны төзекләндерүгә һәм һәр гаиләнең тормыш сыйфатын яхшыртуга керткән бәһаләп бетергесез өлеше өчен халык аңа һаман да рәхмәтле.

Демидов 1980 елдан 2004 елга кадәр – чирек гасыр дәвамында – көн саен шактый зур территориянең проблемалары, борчу-мәшәкатьләре белән шөгыльләнеп, бөтен көчен халкына хезмәткә юнәлтә. Тормыш-көнкүрешнең бер генә өлкәсе дә, мөгаен, аның игътибарыннан һәм ярдәменнән мәхрүм калмагандыр: яңа күперләр, юллар, сууткәргечләр, мәктәпләр, балалар бакчалары, клублар, хастаханәләр – районда барысы да пәйда була, җитәкче барысына да өлгерә. Һәм район зур уңышларга ирешә.

ИГЕНЧЕЛЕК

Алексеевск – авыл хуҗалыгы районы, территориясе гаять зур, биредә һәрвакыт җир икътисадның нигезе санала. Шуңа күрә беренче чиратта терлекчелек объектлары төзи һәм реконструкцияли башлыйлар – дистәләгән сыер, дуңгыз абзарлары, фермалар, 20 дән артык терлек симертү мәйданы, 30 ындыр табагы пәйда була... Терлекчелекне үстерү, малларның токымнарын яңарту, хуҗалыкларны заманча техника белән тәэмин итү мәсьәләләрен бергәләп хәл итәләр.

Чәчүлек мәйданнарына азык культураларының аксымга һәм шикәргә бай перспективалы сортларын кертүнең кирәклегенә бәйле рәвештә 1990 елда төбәктә бердәнбер Кама аръягы зона селекция-орлык сынау станциясе оештырыла. Ә 1997 елда алексеевскилылар дәүләткә кыйммәтле сортлы бодайны гына да 40 мең тоннадан артык тапшыра. Бу район тарихында беренче мәртәбә була. Район иген уңышы буенча Татарстанның иң алдынгы бишлегенә керә!

ГАЗЛАШТЫРУ

1990 нчы еллардан башлап авылларга газ кертү республика халык хуҗалыгы үсешенең өстенлекле юнәлешенә әйләнә. Һәм 1995 елда районнарны, шәһәрләрне һәм авыл җирлекләрен газлаштыру буенча 2033 елга кадәр исәпләнгән Президент программасы кабул ителә. Кыска гына вакыт эчендә 59 торак пунктлы Алексеевск районы киң колачлы газлаштыру программасын төгәлләп бетерә диярлек. Заманы өчен бу гаять зур казаныш, авыл халкы өчен олы куаныч була!

«Мелиорация» Алексеевск күчмә механикалаштырылган колоннасы, «Закамская» КМК, «Алексеевскдорстрой» ААҖ, «Алексеевская МСО» төзелеш компаниясе, «Алексеевск керамикасы» ААҖ, «Эдем» ҖЧҖ кебек бүгенге көндә танылган предприятиеләр дә шул вакытта оештырыла.



ТАРИХ САГЫНДА

Зурлыгы буенча районның икенче торак пункты Биләр авылын һәм бөтен тирә-як зонаны үстерү буенча хакимият башлыгының шәхси кайгыртучанлык күрсәтүен билгеләп һәм бәяләп үтми китәргә ярамый. Биредә киң тармаклы сәүдә һәм җәмәгать туклануы системасы булдырыла, авыл урамнарына асфальт җәелә, мәктәп, балалар бакчасы һәм нәтиҗәдә 2000 нән артык номерга хезмәт күрсәтүче Биләр РУЭС бинасы төзелә һәм реконструкцияләнә, шулай ук урман хуҗалыгы бинасы һәм тулы бер хастаханәләр комплексы пәйда була. Биләр авыл мәдәният йорты бинасын яңарту халыкның мәдәни тормышын яхшыртырга мөмкинлек тудыра.

Биләр җирлегендә федераль әһәмияткә ия уникаль һәйкәл, район һәм республикабыз горурлыгы Биләр шәһәрлеге – Идел-Кама Болгарстаны башкаласы Биләр шәһәренең археологик калдыклары да урнашкан. 1997 елда борынгы ядкарь – «Изге чишмә» комплексын тәртипкә китерү, төзекләндерү буенча киң колачлы эшләр башкарылганнан соң, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев һәм күпләгән кунаклар катнашында ул тантаналы төстә ачыла.

2002 ел. Кама елгасы аша күпер кичүе (соңрак – Алексеевск күпере) төзелеше. РФ Президенты Борис Ельцин, ТР Президенты Минтимер Шәймиев, Алексеевск районы башлыгы Алексей Демидов.

ЮЛЛАР ТӨЗЕЛЕШЕ

Алексей Ивановичның хезмәт биографиясендә юл өслекләрен яңарту, асфальтлау һәм төзүгә бәйле ун ел дәвамындагы михнәтләр, җәфа чигүләр дә бар.

Шул вакыт эчендә 35 күпер төзелә. Соңгы, 36 нчысы – атаклы Кама күпер кичүе иң катлаулысы санала. Берничә дистә ел дәвамында күпме буын көткән әлеге газаплы проектка 1986 елда ук керешәләр. Ә 2002 елда, ниһаять, республика өчен гаять зур вакыйга була, һәм күперне файдалануга тапшыру документларына нәкъ менә Алексей Иванович кул куя.

ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ

1985 елда, Җиңүнең 40 еллыгына, тантаналы төстә «Мәңгелек ут» мемориаль комплексы ачыла. Ә ике елдан соң гаять бай коллекциягә ия туган якны өйрәнү музее үзенең кунакларын кабул итә. 2003 елда «Йолдыз» хәрби-тарихи музей клубы – эзләнү отряды оештырыла: шуннан бирле анда катнашучылар ел саен Бөек Ватан сугышлары булган урыннарга бара.



ТӨЗЕЛЕШ

Алексей Ивановичның социаль өлкәне үстерүгә керткән өлеше бәһаләп бетергесез. Уйлап кына карагыз: 24 ел эчендә 16 мәгариф объекты – мәктәпләр, балалар бакчалары, Алексеевск аграр көллияте комплексы (ә бу 250 урынлык уку-укыту корпусы, тулай торак, ашханә, ябык ындыр, орлык складлы) нульдән башлап салына. 10 авыл клубы һәм мәдәният йорты үз ишекләрен ача; үзәк район хастаханәсенең 100 еллыгына тулы бер хастаханә комплексы төзелә – йогышлы авырулар хастаханәсе бинасы, балалар һәм стоматология поликлиникалары. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү үзәге, балалар һәм яшүсмерләр өчен «Забота» приюты һәм Большие Полянки авылында «Алексеевск картлар һәм инвалидлар интернат-йорты» ачыла. Бирелә ел саен дистәләгән объект кулланышка тапшырыла!

ДУСЛЫК

Алексеевск районында төрле милләт вәкилләре һәм ике дин – ислам һәм православие, бер-берсен баетып, хөрмәт итеп янәшә яши. 1994 елда район үзәгендә беренче мәчет төзелә, бер елдан Алексеевск православие мәхәлләсе торгызыла һәм гыйбадәт кылу йорты ачыла. Алдагы елларда 13 татар авылында – мәчет, Кыркүлдә Троицк чиркәве төзелә, Новоспасская чиркәве, Речное, Биләр, Родники авылларында гыйбадәт кылу йортлары торгызыла, Ахтыр Изге Ана кәшәнәсе һәм бистәнең яңа һәм иске зиратларында өч кәшәнә төзелә.

1996 елда Герман Сергеевич Боровиков җитәкчелегендәге сөт-консерва комбинаты көче белән Алексеевскида тугыз гөмбәзле Воскресение Христова храмы төзелешенә керешәләр. Алексей Иванович Демидов төзелешне башлауга бәйле барлык эшләрдә дә ярдәм кулын суза. Кызганычка, 1998 елда Герман Сергеевич бакыйлыкка күчә... Аллаһ ярдәме һәм республика җитәкчелеге, Алексеевск районы халкы, иганәчеләр, Алексей Ивановичның дуслары булышлыгы белән храм төзелеше 2008 елда тәмамлана.

Әле төзелеш эшләре тәмамланганчы ук, 2003 елда, беренче мәртәбә «Алексеевские перезвоны» Чаң кагу фестивале уздырыла, шуннан соң бәйрәм ел саен оештырыла һәм халыкара төс ала.

СПОРТ

Районда спортны үстерүгә бик зур игътибар бирелә. 1988 елда волейбол залы булган беренче спорт комплексы төзелә. Аннан соң тәрбияләнүчеләре дөнья, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы чемпионнары булачак балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе һәм заманча чаңгы базасы ачыла.

Биләр һәм Түбән Тигәнәле авылларында, 1 нче Алексеевск урта белем бирү мәктәбендә спорт комплекслары файдалануга тапшырыла.

2003 елның декабрендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында район үзәгендә тантаналы төстә 25 метрлы йөзү бассейны булган заманча спорт комплексы ачыла.

ДЕМИДОВЧА

Әлеге игелекле гамәлләр барысы да кайсыдыр бер мизгелдә күркәм нәтиҗәләр бирә башлый. Бердәм Демидов командасының егерме елдан артык вакыт дәвамындагы фидакарь хезмәте һәм тырышлыгы нәтиҗәсендә Алексеевск районы ныклап аякка баса.

Район халкының тормыш шартларын җиңеләйтү, аларга эшләрендә, иҗатларында, балалар тәрбияләүдә ярдәм итү – лидер әлеге стратегик максатына ирешә.

1998 елда Татарстан парламенты абруйлы җитәкче буларак Алексей Демидовны эшеннән азат итмичә генә Дәүләт Советы Рәисе урынбасары итеп сайлый.

Һәм нәкъ менә ул 2008 елда Алексеевское бистәсенең 300 еллыгын уздыруның инициаторы, рухландыручысы, республика Хөкүмәте рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкләгән оештыру комиссиясе әгъзасы була.

Республика бюджетыннан бүленгән шактый акча хисабына Алексей Демидовның турыдан-туры шәхси катнашында әлеге вакыйгага әзерләнү һәм бәйрәм итү буенча киң колачлы социаль әһәмиятле эшләр башкарыла.

БЕЗ ҺӘРВАКЫТ СЕЗДӘН ӨЙРӘНӘЧӘКБЕЗ

Сергей Демидов,
Алексеевск муниципаль районы башлыгы

– Хөрмәтле Алексей Иванович! Сезнең исемегез Алексеевск районы тарихы елъязмасына мәңгелеккә язылган. Хезмәт юлын агроном булып башлап, үзегезгә хас югары һөнәри һәм кешелеклелек сыйфатларына таянып, Сез үз потенциалыгызны тулысынча ачтыгыз һәм бүгенге көндә дәүләт финанс контроленең иң мөһим органнарыннан берсе – Татарстан Республикасы Хисап палатасын җитәклисез.

Гаҗәеп күркәм тормыш юлыгызда авыл кешесенә хезмәт итү өстенлекле бурыч саналды. Авыл кешесенең яшәү рәвешен тирәнтен аңлап, Сез Алексеевск районы кешесе буларак та, җитәкче буларак та, көн саен төбәк халкының тормышы сыйфатлырак һәм яхшырак булсын өчен гаять зур көч куйдыгыз. Фидакарь хезмәтегез нәтиҗәсендә меңләгән эш урыны булдырылды. Сезнең җитәкчелектә һәм турыдан-туры катнашыгыз белән Алексеевск районында күпләгән мөһим объектлар төзелде: күперләр, юллар, спорт комплекслары, балалар бакчалары, газүткәргеч, мәктәпләр, храм, мәчет. Һәм боларның барысын да гомуми кытлыкка бәйле катлаулы чорда югары дәрәҗәдә сыйфатлы итеп гамәлгә ашырырга мөмкин булды. Киң колачлы иҗтимагый проект һәм инициативалар алексеевскилылар тормышын күпкә яхшыртты.

Өлкәннәргә ихтирам-хөрмәт, бабаларыбыз хәтерен саклау – боларга без Сездән өйрәнәбез. Сез безне тормышта төп үрнәк – өлкән иптәшләр һәм остазлар дип өйрәттегез. Аларның бәһасез тәҗрибәсен хөрмәт иткәндә яңа казанышларга ирешүе дә җиңелрәк. Без дә, Сезнең казанышларны истә тотып, игътибар үзәгенә район халкының мәнфәгатьләрен куеп, тупланган мирасны яхшыртырга һәм баетырга тырышабыз.

Исәпсез-хисапсыз игелекле гамәлләр кылган хәйрияче буларак Сез безне яхшылыкны шау-шуларсыз гына башкарырга өйрәтәсез. Һәм халык моның өчен Сезгә бик рәхмәтле.

Татарстанда Сезнең канат астында һәм җентекле игътибарыгыз үзәгендә спортның Олимпия төре булган бадминтон уйнау хәрәкәте үстерелә. Алексеевскидагы спорт объектлары, Бадминтонны үстерү үзәге кебек үк, менә дигән спорт кадрлары әзерләү мәйданчыгына әверелде.

Хөрмәтле Алексей Иванович! Алексеевск районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне күркәм юбилеегыз белән котлыйм! Сезгә республикабызның алгарышлы үсешенә китерәчәк дәүләт эшчәнлегегездә уңышлар, шулай ук нык сәламәтлек һәм гаиләгезгә иминлек-муллык телим!

Фото Алексеевск муниципаль районыннан алынды

«ДЕМИДОВ ЮЛЫ» КАЯ АЛЫП БАРА

Михаил Константинов,
шагыйрь, Бөек Ватан сугышы ветераны, Чуваш Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы

– Мин ветеран буларак бер нәрсәне генә әйтәм: әгәр Алексей Иванович безгә игътибар итмәгән булса, авылыбыз ташландык булыр иде.

Ул шәхсән үзе клубны, мәктәпне төзетү, храмны төзекләндерү өчен күп эшләде. Менә бу Чуваш Майнасына кадәр күперле юлны ул салдыртты, мин аны «Демидов юлы» дип атыйм. Әгәр бу юл булмаса, без бүгенгә кадәр пычракка батып йөрер идек.

Бик күптән, ул районыбызда хезмәт юлын башлаганда таныштык. Без аның белән ахирәт дуслар кебек аралашабыз, бер-беребезне бик шәп аңлыйбыз. Бервакыт ул миңа болай диде: «Менә бит, Михаил Петрович, без төрле энилләрдән туган, төрле заманда яшәдек, ә фикер сөрешебез бертөрле!» Без бер камырдан булуыбызны аңладык...

Кайчак кунакка кергәли. «Михаил Петрович, чәйләп алабызмы?!» – ди. Ә кайвакытта кичләтеп минем өй янына сөйләшеп утырырга килә. Утырабыз, тегесе-бусы, тормыш турында гәпләшәбез...

Мин – 18 китап авторы, аларның бер өлеше Алексей Иванович ярдәме белән басылды. Ничектер бервакыт мин болай дигән идем: «Беркем укымас та инде, бәлки язып та торырга кирәкмидер?» «Тынычланырга иртәрәк, яз. Вакыты җиткәч укырлар», – дип җавап бирде ул. Менә язам инде...

Туган көне алдыннан аңа сәламәтлек, нык сәламәтлек телим. Гади кеше булды, гади кеше булып яшәде, шундый булып калсын да! Шундый ук киң күңелле кеше, гади авыл егете булып калсын!

БИЛӘР ЗОНАСЫН ЯҢАРТУ – АНЫҢ КАЗАНЫШЫ

Александр Гайнуллин,
Биләр авылы кешесе,
Татарстан Республикасының
атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре

– Язмыш мине Алексей Иванович Демидов белән 1985 елда, мин «Дружба» колхозының сөтчелек-товарчылык фермасы мөдире булып эшли башлаганда таныштырды. Алга таба мин әлеге колхозның рәисе, «Чирмешән» ҖЧҖ рәисе, Биләр җирле үзидарә советы рәисе булып эшләдем... Шуңа күрә мин – Демидовның бөтен хезмәт эшчәнлегенең шаһиты, чөнки ул Алексеевск районын нәкъ шул заманнарда җитәкләде.

ҖИТӘКЧЕ ТАЛАНТЫ

Миңа аның кешелеклелек һәм куелган бурычларны үтәр өчен ныклы омтылышны үз эченә алган җитәкче талантының шаһиты булу бәхете туры килде. Башта ул куйган эш темпына ияләшү җиңел булмады. Ләкин алга таба, ни гаҗәп, без үзебездә интенсив эшкә ихтыяҗ сизә башладык. Һәм нәтиҗә үзен озак көттермәде.

КҮПЕРЛӘР ҺӘМ ЮЛЛАР

Үз хуҗалыгым – Шама һәм Биләр җирлеге турында сөйләп үтим.

Көзен-язын, юлсызлык вакытында, Биләр зонасында йөрерлек юл һәм күперләр юк иде. Миңа Биләрдә, Шама, Татар Майнасы, Приозерная, Рус Морасасы, Муллино, Рус Майнасы, Арбузов-Баран, Чуваш Майнасы һәм Красная Горкада күперләрнең пәйда булуын күрергә туры килде. Безнең Биләр зонасы торак пунктларында юлларга асфальт җәелүен, Шама, Урманасты Шынталасы, Байчыклы Барангулда шлюз плотиналары төзелгәнен күрдем.

Мәйданчыгы асфальтланган, өсте ябык ындырлар салынды. Шамада тегермән һәм пекарня ачылды. Шул ук чорда районны актив газлаштыру алып барылды! Чәчү һәм урып-җыю чорларында еш кына планеркалар турыдан-туры кырда уздырылды. Чәчкеч, чылбырлы трактор руле яисә комбайн штурвалында кинәт кенә Алексей Ивановичның пәйда булуы беркемдә дә гаҗәпләнү уятмады. Демидовның тәнкыйтен барысы да тиеш кебек кабул итте, чөнки аның авыл хуҗалыгы белеме булган агроном һәм зур совхоз директоры тәҗрибәсенә ия белгеч буларак кабул иттеләр.

АРЕНДА МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ

Хуҗалык бүлекчәләренең аренда мөнәсәбәтләренә күчүен хәтерлим. Безнең инициатива төркеме Алексей Ивановичка сөтчелек юнәлешендәге МЭТ үрчетү буенча күмәк хуҗалык эшен оешыру өчен бина бүлеп бирү үтенече белән мөрәҗәгать итте. Безгә рәшәткә идәнле, тирес пешкәкле җайланма ярдәмендә чыгарыла торган яңа сыер абзары, 200 баш башмак тана, бульдозерлы ДТ-75 тракторы, азык тараткычлы һәм төягечле Т-25 тракторы, шулай ук авария очракларында кирәк булачак дизель генераторы бүлеп бирделәр... Нәтиҗәдә менә дигән сөтчелек көтүе алдык!

«Дружба» колхозы сыерларны бәйләмичә генә тотуны кертү өчен база хуҗалык итеп сайланды. Ләкин ул заманда бер хуҗалык көче белән генә әлеге методка күчү мөмкин түгел иде. Һәм тагын Алексей Ивановичның ярдәменә таянып сыер абзарын реконструкцияләүне вакытында төгәлли алдык.

ЯҢА ЧАБЫШ ЮЛЫ

Демидов район халкының ялы турында да кайгыртты. Мәсәлән, Федоровское урманы янында уздырыла торган Сабан туенда ат чабышлары туры сызык буенча оештырыла иде. Әйтик, «А» ноктасыннан «Б» ноктасына кадәр. Һәм тамашачылар ат чабышының зур өлешен күрми кала.

Демидовка яңа вариант тәкъдим ителде – чабышны әйләнә буенча оештыру. Һәм Алексей Иванович Алексеевкида әйләнә буенча салынган чабыш юлы төзелеше турында карар кабул итте. Хәзер инде чабышлар вакытында узышларның бөтен кызыгын күреп торырга мөмкин иде.

Ә ветераннар турында кайгырту? Бу Демидов эшчәнлегендә һәрвакыт өстенлекле юнәлеш. Большие Полянки авылында картлар йорты төзелде, караучысыз калганнар биредә тиешле тәрбия алды, гаилә җылысы тапты.

БОРЫНГЫ БИЛӘР ҺӘМ ИЗГЕ ЧИШМӘ

Биләрнең тарихи өлеше – борынгы Биләр һәм Изге чишмә – гел мондый матур түгел иде. 80 нче еллар ахырында әлеге чишмә янына кереп тә булмады. Демидовның турыдан-туры катнашы нәтиҗәсендә Изге чишмә яңы тәртипкә китерелде, төзекләндерелде.

Алексей Ивановичның күптәнге бер хыялы була – Биләр авылында тормыш дәрәҗәсен район үзәгенекенә кадәр күтәрү. Ай саен барлык җитәкчеләр белән бик җитди киңәшмәләр уздырылды һәм Биләр үзгәрде, матурланды. «Халык саны аз булганга, район оештырып булмас, – ди Минтимер Шәймиев ничектер Биләрдә ветераннар белән бер очрашу вакытында. – Шулай да булышырга тырышырбыз...» Һәм һәрвакыт булышты, ярдәм кулын сузды.

Биләр зонасын торгызу, яңарту бары тик Демидов һәм аның командасының максатчан рәвештә эшләве нәтиҗәсендә генә мөмкин булды. Моны беркем дә инкарь итә алмый.

Бүгенге көнгә кадәр Алексей Ивановичның шәхси ярдәмен тоеп яшим – ул һәрвакыт булышырга әзер. Шаккатам – ул ничек барыбызга да булышырга өлгерә!

Сабыр, зирәк, чын кешенең минем тормыш юлымда очравы өчен язмышыма рәхмәтлемен!

Юбилеегыз белән! Саламәтлек, озын гомер, көяшлы көннәр телим! Әшегездә, максатларыгызга ирешүдә бары тик уңышлар гына юлдаш булсын!

Николай Леденцов,
«Инженерлык челтәрләре» ЖЧЖ генераль директоры, Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре

ТАЛӘПЧӘНЛЕК ҺӘМ ЯРДӘМ

– Тормыш юлында бөтен нәрсәдә тигезләнерлек, үрнәк алырлык көчле шәхес, остаз, укытучы очрау зур бәхет ул.

Демидов – һәр яктан үрнәк: эшкә, янәшәндәгеләргә карата мөнәсәбәтләрдә дә, язмыш биргәннең кадерен белү ягыннан да.

Алексей Иванович безнең районга килгәндә, мин «Тельман» совхозында баш инженер булып эшли идем, ә 1981 елдан яңа оештырылган «Войкинский» совхозы директоры итеп билгеләндем һәм әлеге хуҗалыкны унике елдан артык җитәкләдем. Бу катлаулы, ләкин кызыклы һәм уңышлы, нәтиҗәле эшләр башкарылган еллар булды.

Хуҗалыкка биш торак пункт керде. Шуның өчесе, ул вакытта әйтелгәнчә, перспективасыз авыллар иде. Алар территориясе буенча, авылларны һәм җитештерү объектларын бер-берсеннән бүлеп, Актай елгасы ага. Әйтик, Войкино авылы – уң як ярда, ә ферма икенче ярда урнашкан. Язын, боз кузгалгач, сыер савучыларны, терлекчеләрне, сөт тутырылган бидоннарны көймәдә икенче ярга ташыйлар – бер генә күпер дә юк.

Кырыктан артык техникасы булган машина-трактор паркының ремонтлау өчен ике генә урыны бар. Базяково һәм Войкино авылларында ике телефон ноктасы исәпләнә, юллар юк... Якынча шундый ук проблемалар ул чакта районның башка торак пунктларына да хас иде.

Әмма иң мөһиме – кадрлар: яшьләр авылда калмый, Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәрләренә төзелешләргә агыла.

Миңа әлеге проблемалар арасында югалып калмаска кирәк. Менә шул чакта райбашкарма комитеты рәисе Алексей Иванович төзелеш юнәлешен алып баручы буларак миңа ярдәм кулы сузды, кайда гына эшләсәм дә, күп еллар дәвамында әлеге ярдәмне тоеп яшәдем. Ул яңа кран, экскаватор һәм башка махсус техника кайтартырга булышты – ә ул заманнарда ай-һай җиңел эш түгел иде бу! Демидов төзелеш буенча өстенлекле юнәлешләрне билгеләде.

Торак салудан башладык. Елына сигез-тугыз йорт тапшырыла, һәм һәр икенче йортка яшьләр күчә, балалар туа. Һәм монда да ярдәм сизелә: бер ел эчендә МСО аша район программасы буенча балалар бакчасы төзелде, Базяково авылында АТС салып, бөтен авылларга да телефон элемтәсе кертелде.

Алексей Ивановичка хас тагын бер мөһим сыйфат – район кешеләре белән турыдан-туры аралашу. Совхозга килүен фермадан яисә кырдан башлый. Иртәнге дүрттә, савым башланганчы, сыер савучылар белән очраша – алар белән аралаша, эшләре белән генә түгел, шәхси тормышлары белән дә кызыксына, һәркайсына хөрмәт белән, исеме-атасының исеме белән эндәшә. Әгәр үтенеч белән мөрәҗәгать итсәләр, барысы да бик тиз хәл ителә.

Алексей Иванович инициативасы белән Пановка, Ямкино кебек кечкенә авыллар сакланып калды. Башка объектлар да: ике ындыр табагы, Войкино авылында ашлык киптерү урыны булган икмәк чистарту комплексы, Базяково авылында АВМ, остаханә, модульле җылы техника кую урыннары. Шулай да халык өчен иң зур төзелеш дип Левашеводан Базяково авылына кадәр юл салуны атар идем. Әлеге максатта районда махсуслаштырылган юл-төзелеш оешмасы төзелде.

Шул ук вакытта башка хуҗалыкларда юл төзелеше район хуҗалыклары көче белән алып барылды, алардагы техника язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң һәм игеннәрне урып-җыю башланганчы әлеге эшләргә җәлеп ителде.

Газ кертү шулай ук гадәттәгечә алып барылмады – проектлаштыру һәм төзү параллель рәвештә эшләнде, бартер буенча АГРС лар кайтартылды. Газүткәргечләрне төзү барышында Алексей Иванович халыкны газ казаннары һәм плитәләр белән бушлай тәэмин итәргә булышты. Халыкның ничек сөенгәнен күрсәгез иде!

Шунысын да әйтергә кирәк: Демидовта кырыслык, кул астында эшләүчеләргә карата таләпчәнлек кешегә хөрмәт һәм ярдәмчеллек (авыр чакта һичшиксез ярдәм кулы сузачак!) белән органик рәвештә үрелгән.

Алексей Иванович! Ихлас күңелдән юбилеегыз белән котлыйм! Сезгә иң мөһиме – нык сәламәтлек, җан тынычлыгы, үзегезгә һәм гаиләгезгә игелек һәм иминлек телим!



УЛ БЕЗНЕҢ СӨТЧЕЛЕК ГИГАНТЫН КРИЗИСТАН ЧЫГАРДЫ

Елена Макарихина,
Алексеевск сөт-консерва заводының элекке җитәкчесе

– Демидовның хезмәт юлы безнең гүзәл Алексеевск районы белән туры-дан-туры бәйле. Без аны тәҗрибәле, зирәк һәм җаваплы җитәкче буларак беләбез. Профессиональлеге, максатчанлыгы, кешеләр турында әчкерсез кайгыртучанлыгы лаеклы рәвештә бөтен район халкының ихтирамын һәм абруен казанды.

Мин егерме елдан артык сөт-консерв комбинатында эшләдем, 1985–2007 еллар иде бу. Башта бухгалтерияне, аннары комбинатны җитәкләдем. Бу вакыт эчендә без ни генә кичермәдек: югары күтәрелүләр дә, түбән төшүләр дә, җитештерүнең гөрләп үскән чорлары да, упкынга тәгәрәгән авыр вакытлары да булды.

Барысы да булды. Әмма район башлыгы безнең җитештерүне һәрвакыт күз уңында тотты. Ул вакытта бер генә җыелыш та, бер генә киңәшмә дә сөт әзерләү, эшкәртү һәм сөт продукциясен сатуга бәйле беренчел мәсьәләләр турында сөйләшүләрсез узмады. Ә башкача булмый да! Сөт комбинаты Алексеевскиның 350 кешесен эш белән тәэмин иткән иң эре предприятие иде бит, монда тәүлегенә 300 тоннадан артык сөт эшкәртелә, цехлар өч сменада, тәүлек буе эшли иде.

Демидов булышлыгы белән җитештерү артты, ярдәмче хуҗалык үсте, завод хезмәтчәннәре өчен йөзләгән уңайлы фатир төзелде, спорт комплексы, йөзү бассейны, гыйбадәтханә калкып чыкты, урта мәктәп сафка бастырылды.

Әмма 90 нчы еллар ахырында башланган икътисадый кризис безнең сөт эшкәртү гигантын да читләтеп узмады, бурычка баттык.

Сөт җитештерү тармагына һәм шул ук вакытта бик күп, бик күп кешеләрнең язмышына Демидов ярдәмгә килде. Ул предприятиене һәм бөтен коллективны критик вазгыятьтән коткару юлларын тапты.

Берничә ай эчендә җитештерү цехлары ремонтланды, иске җиһазлар алыштырылды, сөт ташу өчен яңа автопоездлар сатып алынды, яңа казылык җитештерү цехы төзелде, эш урыннары саклап калынды. Боларның барысы да – аның казанышы гына!

Хөрмәтле Алексей Иванович!

Завод халкы һәм аларның гаиләләре, производство ветераннары исеменнән юбилеегыз уңаеннан иң җылы һәм ихлас котлауларны кабул итегез! Сезнең катнашыгыздан, үткен күзегездән башка Алексеевск районында яшәүне күз алдына да китерә алмыйбыз. Сезне белгәнебез өчен, безнең өчен кылган эшгамәлләрегез, булганыгыз өчен бик зур рәхмәт!

Сезгә бәхет, сәламәтлек, иминлек һәм үзегезгә билгеләгән максатларыгызга ирешүегезне телибез!



РЕКЛАМА

ҮЗЕ КЕШЕЛӘРНЕ ЯРАТКАНГА, ХАЛЫК ТА АНЫ ҮЗ ИТӘ

Нургазиз Кыямов,
Кыр Шонталысы авылы кешесе,
Татарстан Республикасының
атказанган икътисадчысы

– Вахитов исемендәге колхозны җитәкләгәндә, миңа Демидов кул астында егерме елдан артык эшләү бәхете тәтеде. Ул – тумыштан талантлы, үз эшен белүче һәм яратучы җитәкче. Ул эшләгән чорда безнең районда зур үзгәрешләр булды. Матди-техник база бик ныгыды һәм, нәтиҗәдә, хуҗалыкларның, предприятие һәм оешмаларның җитештерү тармагына, финанс-икътисад хәленә бәйле күрсәткечләре яхшырды.

Безнең хуҗалык хезмәтчәннәре дә, Алексей Ивановичның һәрдаим ярдәмен тоеп, район үсешенә саллы өлеш кертте, авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерү һәм сатуны арттыруга ирешә. Хуҗалыгыбыз бөтенсоюз масштабындагы социалистик ярышта ике тапкыр җиңүче дип табылды һәм ике тапкыр КПСС ҮК, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮК Мактау грамотасы һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнде.

Алексей Иванович капиталь төзелеш тармагына аеруча игътибар бирде. Бу чорда безнең хуҗалыкта да барлык ашлык җыю-саклау һәм терлекчелек объектлары, машина-трактор паркы яңадан төзелде, торак һәм төрле инфраструктура төзелеше актив барды. Район үзәге матурланды, төзекләндерелде, районның барлык торак пунктларында да зур үзгәрешләр булды.

Алексей Ивановичның турыдан-туры җитәкчелегендә 1980 нче еллар ахырында ук районның барлык авылларын газлаштыру мәсьәләсе хәл ителде, юллар һәм урамнар асфальтланды.

Теләсә кайсы җитәкче өчен хезмәт уңышының нигезендә, барыннан да элек, кешеләр белән аралаша белү ята. Алексей Иванович эшче катламга, хезмәт кешеләренә зур хөрмәт белән карый. Игенчеләр һәм терлекчеләр белән очрашканда, ул әлеге очрашуларга чын күңелдән шатлана, һәркемне игътибар белән тыңлый һәм аларның төрле проблемаларын хәл итә иде. Аның кеше йөзен хәтердә калдыру сәләте искиткеч. Билгеле бер вакыттан соң теге яки бу кеше белән кабат очрашкач, ул аларга исеме һәм атасының исеме белән һич ялгышмыйча дәшә иде. Әлбәттә, үзләрен онытмаганлыкларын белүдән бу кешеләрнең бик күңеле була.

Әле ул ветераннарның, өлкән буын кешеләренең гозерләренә һәм мөрәҗәгатьләренә дә бик хөрмәт белән карый. Ул кешеләрне ярата һәм кешеләр аңа шундый ук мөнәсәбәт белән җавап бирә.

Һәм бүген мин, Алексей Ивановичны туган көне белән тәбрик итеп, барлык изге теләкләргә кушылам, аңа нык сәламәтлек, озын гомер, актив тормыш, бәхет һәм эшендә уңышлар телим!

Фото: Александр Ефремов

ТАТАРСТАНДА, КАМА ЯРЫНДА АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ БАР...

Дамир Фәттахов,
Алексеевск Үзәк район хастаханәсенең стоматология поликлиникасы мөдире, табиб-стоматолог

– Алексеевск районы Татарстанның табигать һәм рухи байлыкларына юл ача торган көньяк-көнчыгыш капкасы булган кебек, Сез дә күп кенә районнардашыбыз һәм татарстанлылар өчен мөмкинлекләр капкасын ачасыз.

Мин зур горурлык белән үземне Сезнең ярдәмегездә тормышта юл тапкан кешеләрнең берсе дип атыйм! Сезнең булышлык нәтиҗәсендә мин эшлим һәм иҗат итәм, үзем һәм әйләнә-тирәдәгеләр белән гармониядә яшим, үземне үз урынымда хис итәм һәм моның белән горурланам.

Сез заман сулышын һәм дөньяда, илдә, республикада, аерым урыннарда барган вакыйгаларны тирәнтен тоемлый аласыз. Теге яки бу хәлнең вакытлы гына булачагын яисә озакка сузылачагын тәгаен беләсез. Хирургларча төгәллек белән вакыйгаларны минутына кадәр исәпләп чыгара аласыз. Сез кайсы кешене кая юлларга кирәкне, аның шунда төпләнеп, уңышлы эшләп, үзе һәм янәшәсендәге кешеләр өчен файда китерә алачакны яхшы беләсез.

Сез кешеләрне һәм тирә-юньдәге мохитне үзгәртү көченә ия – инсаннарны үзгәртердәй, авыруларны терелтердәй, үксезләрне бәхетле итәрдәй, мохтаҗларга сыенер урын бирердәй процессларны эшләтеп җибәрәсез. Үз проектларыгыз белән Сез күпләр өчен югары әхлак һәм әдәплелек үрнәге күрсәтәсез. Сез кешеләргә карата игътибарлы, авыр мизгелләрдә аларга ярдәм итәсез, кеше рухлансын өчен тырышлыкны кайчан кая юлларга кирәклеген беләсез!

Сез кешеләргә ышанасыз, үзегезнең игътибарны конкрет инсанга юнәлтәсез, нәкъ ул булдыра алырлык бурычлар куясыз. Һәм алга таба хуҗалыкчан игътибар, кайгыртучанлык һәм кырыслык белән конкрет хәлдә мөмкин булган иң югары нәтиҗәгә ирешергә булышасыз. Сез һәрвакыт иң югары потенциалны күздә тотасыз һәм кешегә мөстәкыйль рәвештә аңа омтылу мөмкинлегe бирәсез. Сез югары казанышлар спорты тренеры кебек үз канатыгыз астындагы һәр кешене Олимпия алтынына илтәсез. Күпләр өчен Сез маяктай барыр сукмакны яктыртасыз, кешегә кайчан кая таба йөзәргә, әмма мөстәкыйль йөзеп җитәргә тиешле юлны күрсәтәсез.

«Эш кыйммәт түгел, эшли белү кыйммәт», – диясез Сез. Шуның белән хезмәткә хөрмәт һәм ярату тәрбиялисез һәм кешедә әлеге халәтне иң югары ноктага җиткерәсез. Үзегезгә карата югары стандартлар куеп, Сез сүзегез, эшегез, һәр гамәлегез белән үрнәк күрсәтәсез.

Сез минем тормышымда Пётр I не хәтерләтәсез – мин бүгенге көнгә кадәр рәхәтләнеп хезмәт иткән стоматология поликлиникасы төзелеше өчен урынны киң, ышанычлы адымнар белән карап, үлчәп йөрүегез һаман күз алдыннан китми. Һәм шулай ук аны үстерү өчен ресурсларны да дөрес итеп бүлдегез – барысы да эш, иминлек, олы бурычларны хәл итү хакына!

Сезгә ышанып тапшырылган Алексеевск районында кулыгыз нәрсәгә генә кагылмасын, барысы да эшләп китте, хәзер дә үсә һәм гөрли. Сез төбәкне генә түгел, безне – район халкын да үзгәрттегез! Сез чәчкән орлыклар, яңарткан традицияләр һәм куйган стандартлар җимеш китерүен дәвам итә, кешеләрдә өмет һәм ышаныч уята. Без ихлас күңелдән барысы өчен дә бик рәхмәтле, һәм һәрвакыт Каманың сул як ярына караганда безне, алексеевскилыларны, аерым бер җылылык белән искә төшерүегезгә ышанабыз.

УЛ РУХИ ТОРМЫШНЫ ЯҢАРТТЫ

Павел Чурашов,
Алексеевск протоиерее, Алексеевск районы православие мәхәлләсе халкы исеменнән

– Моннан чирек гасыр чамасы элек Алексеевскига эшкә килгәч, мин районның алга китүен күрдем: торак пунктларга илткән юллар асфальтлана, авыл өйләренә газ керә, торак йортлар төзекләндерелә, социаль сфера, аграр һәм сәнәгать комплекслары интенсив үстерелә. Бу район башлыгының зирәк җитәкчелеге, үлчәнелгән һәм төптән уйланылган гамәлләре нәтиҗәсендә мөмкин булды.

Демидов җитәкләгәнгә, Татарстанда Алексеевск районын һәрвакыт ышанычлы санадылар һәм саныйлар. Әмма Алексей Ивановичның иң яхшы сыйфаты – үз тирәсенә акыллы, инициативалы, җаваплы, уңай, иҗади фикерләргә сәләтле кешеләрне җыя белүе, аларга карата кирәк чакта катгый таләпчәнлеге, әмма авыр вакытта ярдәм кулы сузуы. Мөгаен, шуңа да 1994 елда, Изге китапта язылган «Кеше икмәк белән генә түгел, Ходай сүзе белән дә яши» дигән сүзләрне истә тотып, Алексей Демидов Алексеевское бистәсендә җимерелгән храм урынына яңасын төзү башлангычы белән чыкты. Нәкъ менә Воскресение Христова храмы төзелеше Алексеевск төбәгендә рухи тормыш яңарышына сулыш өрде һәм мәхәллә җәмгыятенең оешуына нигез салды. Алексей Иванович аның ышанычлы иганәчесенә әверелде.

Воскресение Христова храмын төзегәндә һәм бизәгәндә, Демидов һәрвакыт башкаларга караганда ераккарак карап эш итте. Шуңа күрә бүген Алексеевск төбәгендәге храмнар һәм кәшәнәләр, һәркемгә дини тормышка кагылу мөмкинлеге биреп, район халкын гына түгел, кунакларны да шатландыра, чөнки чиркәү – ул бина гына түгел, ул тере рухи организм да.

Алексей Демидов химаясендә мәхәлләдә изге урыннарга барулар оештырылды, балалар һәм өлкәннәр өчен якшәмбе мәктәпләре ачылды, фестивальләр, бәйрәмнәр, концертлар да үткәрелде... «Алексеевские перезвоны» Чаң кагу фестивале, мәсәлән, Россиянең күп кенә төбәкләре һәм чит илләрдән килгән атаклы чаң кагучылар өчен әлеге сәнгать буенча тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгына әверелде. Ә килгән кунаклар өчен бу бәйрәм православиенең матди булмаган мирасы – чаң кагу сәнгате белән танышу, күрү мөмкинлеге. Безнең җәмгыять белән хезмәттәшлек буенча файдалы тәҗрибәне нәкъ менә рухи бердәмлек дип атарга буладыр. Алексеевск төбәгендә тормышка яңа сулыш өргән тәҗрибәне!

Хөрмәтле Алексей Иванович!

Сезне ихлас күңелдән юбилеегыз белән котлыйбыз! Тәҗрибә һәм зирәклек, бүләк һәм хөрмәт кенә түгел, чигаләргә бәсләр дә өстәп еллар ага тора. Мәңгелек кыйммәтләрне үзләштерүдә Ходай Сезгә тән һәм иман ныклыгы бирсен! Кешеләргә тараткан яхшылыгыгыз һәм яктыгыз үзегезгә йөзе белән әйләнеп кайтсын, изге гамәлләрегезне тарафдарлар һәм укучыларыгыз, балалар һәм оныкларыгыз дәвам итсен, алар арттырылсын!
Сезгә хәерле озын гомер насыйп булсын!

Фото: Александр Ефремов

PRESSA

УРТА ДЕВЯТОВО: УРЫНЫ БУЕНЧА– УРТАНЧЫ, ХИСАП ЯГЫННАН– ТУГЫЗЫНЧЫ



УРТА ДЕВЯТОВО

Фото: Александр Гайнетдинов

1

Бу авылга рус әкиятләрендәге «тридевятый» – җир читендәге патшалыкка эләккән сыман килеп керәсең, бу тирә салаларның исеме дә шуңа охшаган бит. Һәм әлеге әкият Оренбург трассасыннан сулга борылып, 200 метр узуга ук башлана. Менә юл күрсәткеч такта да Урта Девятово дип кычкырып тора.

Татьяна Вафина

Ни өчен шундый сәер исем бирелгәнлеге һәм Урта Девятово авылының бу якты дөньяда кайчаннан бирле яшәгәнлеге турында мондагы мәдәният йортында белешәбез. Җирле халык үз тарихы белән шулкадәр горурлана ки, Казаннан килгән кунакларга, бусагадан атлап керер-кермәс үк, бу темага тулы бер лекция укыдылар.

ӨЧ ДЕВЯТОВО ЯГЫ

– Безнең авылга 16 нчы гасырда Казан ханлыгын яулап алганнан соң күченеп килгән руслар нигез салган, – дип сөйли мәдәният йорты директоры Ольга Демидова. – Казанны яулап алып, унбиш ел узгач, Тургай, Мамалово, Күмкәч, Үкрәч-Култык, Смолдеярово (Исмәгыйльдияр), Тәүкәч кебек урыннар бушап кала. Аларның күбесе җир йөзеннән бөтенләй юкка чыга, ә кайберләре акрынлап аякка баса. Әйтик, күрше Смолдеярово авылы зур чиркәү мәхәлләсенә әверелә. Аның составына өч күрше авыл – Иске Девятово, Ерак Девятово һәм Урта Девятово кергән.

– Димәк, өч Девятово авылы булган, ни дисәк тә, әкияттәге «тридевятый» килеп чыга бит…

ТУГЫЗЫНЧЫ ЗМЕЕВ

– Авыл атамасының барлыкка килүенә кагылышлы ике фараз бар, – дип дәвам итә Ольга Викторовна. – Беренчесенә күрә, авыл 1618 елда Лаешка «башлык» (голова) итеп җибәрелгән Казан дворяны Змеев хөрмәтенә аталган. Никита Федорович Змеев 1568 елда Казан воеводасы карары белән Тәүкәч авылының хуҗасына әйләнгән этисе Федор Семенович Змеевның тугызынчы улы булганга, аңа Тугызынчы (Девятый) кушаматы тагыла.

2

3


4

5

1

Истәлекле урын буларак, биредә сәүдәгәр Щетинкинның шактый яхшы хәлдә сакланган агач йортын күрсәтәләр.

2

Урта Девятово авылындагы чишмә.

3

– Балык Бистәсеннән алып Казанга кадәр Оренбург тракты буйлап юл тотканда, 18 торак пункт очрый. Шуларның тугызынчысы хәзерге Урта Девятово була. Әнә шулай итеп ул үзенең сәер исемен ала да инде, – дип сөйли Ольга Викторовна.

4

Демидовларның туган йорты.

5

Яңа мәктәп.

6

Урта Девятово мәктәбендә 1 сентябрь бәйрәме.

Девятый (Никита) Федорович Лаеш төбәгендә берничә алпавыт биләмәсенең, шул исәптән безнең авылның да хуҗасы булып куя.

Икенче версия дә «тугызынчы» сүзе белән бәйле: Балык Бистәсеннән алып Казанга кадәр Оренбург тракты буйлап юл тотканда, 18 торак пункт очрый. Шуларның тугызынчысы хәзерге Урта Девятово була. Әнә шулай итеп ул үзенең сәер исемен ала да инде.

СӘҮДӘГӘР ЩЕТИНКИН ЭЗЛӘРЕННӘН

Тарих сәхифәләрен актарып алга атлаган саен, кызыклырак кына була бара, төрле нечкәлекләре, бигрәк тә персонажлары мавыктыргыч үткәннәргә алып кереп китә. Федор Змеев варислары Урта Девятово авылына 1861 елга кадәр хуҗа булып тора. Аннары авыл алпавыт Степан Могилатов кулына күчә. Ә 1880 нче елларда биләмәне беренче гильдия Казан сәүдәгәре, Смолдеярово, Сокуры һәм Янсуар авылларында да биләмә тоткан Павел Васильевич Щетинкин сатып ала.

Танылган хәйрияче Щетинкин акчасына Казандагы Үзәк керәшен-татар мәктәбе һәм дини училище биналары төзелә, күп кенә башлангыч мәктәпләр җиһазлана һәм уку әсбаплары белән тәэмин ителә... Сәүдәгәр авыл җирлегендәге хәйриячелек эшенә дә зур игътибар бирә. Ул Казан губернасы авылларында берничә чиркәү төзетә. Урта Девятовода аның изге эшләрен әле дә хәтерлиләр – Павел Васильевич 1884 елда Смолдеярово авылында земство мәктәбе ача, чиркәү төзетә. Моннан тыш, язгы



7
Авылның тагын бер бизәге – күл буенда агачтан юнып-кырып ясалган зур чатыр. Тик никтер бу күлне Птичник дип атыйлар.

8
Сәүдәгәр Щетинкин вакытында чатыр менә шундый булган.

9
Чишмә янында истәлеккә фото.

кыр эшләре һәм урып-җыю вакытында балалар өчен ясле оештыра...

Биредә, истәлекле урын буларак, аның шактый яхшы хәлдә сакланган ике катлы агач йортын күрсәтәләр. Совет чорында анда мәктәп, почта һәм медпункт була, аннары, янгыннан соң, аны ремонтлап, авыл кешеләренә фатир итеп бирәләр. Өлкәннәр сәүдәгәр йортының арткы ягында ике фонтан белән бизәлгән гаҗәеп матур җиләк-җимеш бакчасы булганлыгы турында сөйли. Бер фонтанның үзәк өлешендә малай сыны торган, ә икенчесен балык сыны бизәгән. Фонтаннарга су Тәүкәч елгасыннан килгән, анда моның өчен махсус зур буа ясалган. Революциядән соң бакчаны юк иткәннәр. Бер аллеяның күпмедер өлеше һәм фонтанның нигез чокыры гына сакланып калган. Әмма авыл халкы әлегә кадәр бу урынны Бай (Барин) бакчасы дип йөртә.

Авылның тагын бер бизәге – күл буенда агачтан юнып-кырып ясалган зур чатыр.Тик никтер бу күлне Птичник дип атыйлар.

– Күл өчен сәер исем...

– Сәүдәгәрнең кош-корты күп булу белән бәйле ул: үрдәкләре, казлары – барысы да монда йөзеп йөргән, – дип аңлата Ольга Викторовна.

– Ә хәзер?

– Хәзер монда балык күп, барысы да балык тотарга килә. Ә чатыр реставрацияләнгән, ул Щетинкин вакытында нинди булган, шундый ук диярлек.

ЧИШМӘ БУЕ ХОЗУРЛЫКЛАРЫ

Урта Девятовода төзекләндерелгән истәлекле урыннарның күплегенә гаҗәпләнәбез, чөнки мондый хәл бик сирәк авылда гына очрый.

– Сез безнең чишмәне күрмәдегез әле! – дип әйтеп сала Ольга Викторовна зур горурлык белән һәм безгә чишмә юлын күрсәтә.

Чишмәдә халык кайнап тора. Чиратка тезелеп, төрледән-төрле савытларына бәллүрдәй саф, чиста су тутыралар. Әтиләр сабыр гына үз чиратлары җиткәнен көткән арада, әни кешеләр балалары белән чишмә тирәсендә йөреп тора. Монда карап-хозурланып йөрерлек, фотога төшәрлек урыннар аз түгел. Кара атлар игътибарны бигрәк тә җәлеп итә – алар чын ат зурлыгында ясалган... Шундый хис туа: әйтерсең, хәйрияче Щетинкин үзенең игелекле эшләрен хәзерге көндә дә дәвам итә.

АВЫЛ ИГЕЛЕКЛЕ КЕШЕЛӘРДӘН УҢА

– Авыл игелекле кешеләрдән уңа, – ди Урта Девятово мәктәбе директоры Алёна Жесткова. – Бу кешеләр үзләренең изге эш-гамәлләре белән балаларда туган төбәккә мәхәббәт тәрбияли. Мәсәлән, Татарстанның Хисап палатасы рәисе Алексей Демидов кебекләр. Ул – безнең якташыбыз, биредә туып-үскән, авылын онытмый. Алексей Иванович туган

йортына даими кайтып йөри, авылны төзекләндерү турында кайгырта, якташларына ярдәм итә һәм мондагы мәктәпкә бик күп игътибар күрсәтә.

Мәктәп 1982 елда ачылган. Балалар бакчасы да урнашкан кечерәк генә бина өчен йөз укучы шактый күп була. Вакытлар узу белән, аңа капиталь ремонт таләп ителә. Ул 2018 елда Алексей Демидов ярдәме белән башкарыла. Бина бөтенләй диярлек яңа сулыш ала, матурая, яктырып, җылынып китә.

Эше никадәр генә тыгыз булса да, Татарстан Хисап палатасы рәисе уку йорты тормышында шәхсән катнашу мөмкинлеге таба. Беренче сентябрь линейкалары бик сирәк очракта гына аның катнашыннан башка уза. Алексей Демидовның һәр сәфәре укучылар өчен бүләкләре, сюрпризлары, кызыклы чаралар булган бәйрәмгә әйләнә. Узган көздә республика Хисап палатасы ярдәме белән Урта Девятово авылының 100 баласы Казан Кремленә зур сәяхәт кыла, монда аларга Кремль тарихы турында тәфсиллəп сөйлиләр, ни дисәң дә, Белем көнենә иң яхшы бүләк – белем үзе ул. Алексей Демидов мәктәпне Татарстанның Алексеевск районы бадминтончылары белән таныштыра һәм дуслаштыра. Спортчылар һәм тренерлар Урта Девятовога килеп, осталык дәресләре уздыра, ә мәктәп укучылары Казанга Бадминтон үзәгенә ярышларны тамаша кылырга бара.

– Без Алексей Ивановичка игелекле эшләре өчен бик рәхмәтле. Ул безгә бик игътибарлы, булышудан беркайчан да баш тартмый. Укытучылар өчен дә, балалар өчен дә бу ярдәм бик кадерле, – ди Алена Петровна. – Бер фәлсәфәче: «Күңелнең барлык изгелекләреннән һәм уңай сыйфатларыннан иң зурысы– игелеклелек», – дигән. Күренекле якташыбыз үз эш-гамәлләре белән моны елдан-ел раслап килә. Юбилее уңаеннан Алексей Ивановичка бетмәс-төкәнмәс оптимизм, сәламәтлек һәм иминлек телим!



9

ТУГЫЗЫНЧЫ БУЛАСЫЗМЫ?



Әңгәмәдәшебез Ольга Викторовна әлеге күренекле затның бертуганының кызы булып чыкты. Ул безне изгеләрдән изге урын – авыл китапханәсенә алып бара. Мондагы иске һәм яңа китаплар арасында бүген бу гаҗәеп авылның искиткеч кешеләре турында ишеткәннәребезне, укыганнарыбызны да, әле белергә өлгермәгәннәребезне дә табып була. Шуңа күрә Урта Девятово авыл китапханәсенә язылабыз да... «Демидовлар» дип аталган менә бу зур, калын китапны укырга алабыз. Шушы җирдә туып, бу төбәкне экияти урынга әйләндерер өчен кулдан килгәннең барысын да эшләгән атаклы гаилә турында бу китап. Николай, Виктор, Юрий, Тамара, Фаина, Александр, Алексей, Анатолий – Иван Герасимович һәм Лукерья Афанасьевна Демидовларның балалары – сигезәү генә булсалар да, Урта Девятово «шәҗәрәсе»ндә бик лаеклы урын алган. Изгелек кылу өчен, тугызынчы булу бер дә мәҗбүри түгел. Т

НИЧЕК БАРЫРГА

Бик җиңел. Казаннан Оренбург юлы буйлап «Урта Девятово –0,2» дип язылган күрсәткечкә кадәр барабыз. Шәһәрдән авылга кадәр барлыгы – 50 чакрым.

НИ КАРАП СОКЛАНЫРГА:

Җәй көне монда бигрәк тә матур, диләр. Тик кышкы сәяхәтчеләргә дә хозурланыр урыннар җитәрлек. Сәүдәгәр Щетинкин йорты, Птичник күлендәге чатыр... Шулай ук башка йортлар фонында архитектурасы белән аерылып торган америкалы йортына да сокланып карарлык. Америка кешесенең исеме Джон, диләр. Шунысы кызык: ул Урта Девятовоны бернинди Америкага да алыштырырга җыенмый икән. Һәм дөрес тә. Ни калган ул Америкада?

НИ ЭЧӘРГӘ:

Саф чишмә суы. Ул дәвалый да, исертә дә – дарулар, хәмер бер читтә торсын! Мөгаен, нәкъ менә шуңа күрә һәркем Урта Девятовода яшәргә һәм эшләргә омтыладыр да, әйтерсең, монда бал сылаганнар. Тормыш-көнкүреш өчен дә, хезмәт өчен дә барлык шартлар тудырылгач, ник омтылмасыннар, ди әле.

КАЗАНЫШЛАР ЮЛЫНДА

Фоат Вәлиев,
«Алексеевскдорстрой» ААҖ директорлар советы рәисе

– Кайчандыр безнең Алексеевск районында бер генә асфальт юл булып, әлеге Казан–Оренбург зур автотранспорт магистрале безне Казан, Чистай, Әлмәт белән тоташтыра иде. Ә минем районым эчендә язгы пычрак вакытында, яңгырлы көздә бер машина да йөри алмады. Алексей Иванович Демидов булмаса, бу хәлнең күпмегә сузыласын да белмим.

Билярдән Алексеевск сөт комбинатына сөтне ничек ташыганнарын яхшы хәтерлим. Моның өчен теләсә нинди юлда йөри ала торган К-700 «Кировец» тракторын эшкә җигәләр иде. 1991 ел. Ул чактагы район хакимияте башлыгы Алексей Иванович, гел болай була алмый, юллар төзи башлыйбыз, дигән бурыч куйды! Аны хәл итү җиңел булмады: ул чакта бездә юл-төзелеш техникасы юк иде, ә асфальт-бетон заводлары турында сүз дә була алмый! Төзелеш өчен кирәк нәрсәләрнең барысын да каян алырга? 90 нчы елларда базар мөнәсәбәтләре ниндидер стихияле һәм аңлаешсыз нәрсә иде – «тере» акча юк диярлек, бөтен җирдә бартер хөкем сөрә. Үзебезнең беренче асфальт-бетон заводын да без нәкъ шундый схема буенча сатып алдык.

КИҢ ҖИЛКӘСЕНӘ ЫШЫКЛАНЫП

Бартер өчен кирәкле материаллар һәм җиһазлар исемлеген ничек төзегәнебезне дә хәтерлим әле. Һәм Алексей Иванович бөтен республика буйлап безнең «валюта» булырга тиешле нәрсәләрне эзләргә чыгып китте. Шулай итеп без асфальт болгаткыч таптык. Ә битумны каян алырга? Демидов тегенең белән, моның белән сөйләшергә дип, тагын юлга кузгалды – монысында инде нефть төбәгенә. Вак таш дигәннәре тагын бер проблема! Анысына дип Жигулевскига китте. КАМАЗда берничә төн кунды – ничек тә безгә, юл салучыларга, үзбушаткычлар алырга иде. Алексеевск – Биләр юлы төзелеше нәкъ шулай башланды.

Бу бик колачлы эш булды, анда күпләргә катнашырга туры килде. Бу юлны без күмәкләп, бергәләп төзедек. Җирнең өске катламын күтәртергә кирәк, ә моның өчен кирәкле техника җитешми, чөнки ул вакытта безнең өчен эш күләме артык зур иде. Хуҗалыкчыл кеше һәм җитәкче буларак, Алексей Иванович чираттагы тапкыр үзенең осталыгын күрсәтте – бу юлы инде кешеләр белән эшләүдә. Төзелеш буенча һәр планеркада шәхсән үзе катнашты, колхоз-совхоз җитәкчеләрен юл төзүчеләргә ярдәм итәргә үгетләде.

Мәзәк хәлләр дә булды. Бездә күмәк юл төзү идеясен хуплаган бер танылган совхоз директоры бар иде. Барлык планеркаларда да ул беренче рәтләрдә: «Дөрес сөйлисез, Алексей Иванович! Юл салырга кирәк, моңа барысы да катнашырга тиеш!» – дип җөпләп торды. Юлның ныгытылган катламы аларның авылына барып җиткәнче шулай булды. Аннары исә бөтенләй башкача сөйли башламасынмы: «Алексей Иванович, ә юл төзүчеләргә үзләренә генә төзергә вакыт түгелме? Без аларга ни өчен ярдәм итәргә тиеш әле?» «Без синең акыллы җитәкче икәнеңне беләбез, – дип җавап бирде ул вакытта Демидов. – Тик юл бер сиңа гына кирәк түгел. Ничек төзедек, шулай төзиячәкбез, һәм син дә бу эштән кача алмаячаксың». Әйе, Алексей Иванович – бик таләпчән җитәкче, әмма ул һәрвакыт тигезлек һәм гаделлек принципларына таянды. Теләсә нинди ситуациядә һәм һәркем өчен дөрес сүзләр таба белде. Безнең күбебез, бүгенге предприятие җитәкчеләре, Алексей Ивановичның катлаулы мәсьәләләрне ничек хәл итүен, барча халыкны уртак хезмәткә ничек кызыксындыра белүен күреп, аның тәҗрибәсен сеңдереп, җитәкче булып формалаштык.

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАНГА КҮПЕР

Сиксәненче еллар ахырында республикада Кама аша күпер төзү турында карар кабул ителде. Алга таба бу күпер, Чулман аръягы төбәген Татарстанның үзәге һәм көньягы белән ел әйләнәсе файдаланып була торган тиз йөрешле имин юл белән тоташтырып, икътисадыбызны үстерүдә мөһим роль уйнады. Сүз уңаеннан, күпер салу урыны турында кызу һәм озын-озак бәхәсләр булды. Аны Алексеевскидан түбәнрәк яки, киресенчә, югарырак, Чистайга табарак төзү турында сөйләшүләр барды. Демидовның бу мәсьәләне хәл итүгә керткән өлешен без, Алексеевск районы халкы, хәтта бәяләп тә бетермибез.

Аннары, инде эш барышы вакытында, Алексей Иванович проектантлар белән дә, тикшеренүчеләр белән дә тыгыз элемтәдә торды. Кешеләр һәм табигатькә кагылышлы эшләрдә ул һәр детальне өйрәнә, бик чокчынучан, таләпчән затка әйләнә иде. Әйе, бу проектның экологик ягына да аерым бер мөнәсәбәт, игътибар күрсәтте. Идел аша күпер төзегәндә ясалган хаталарның кабатлануын теләмәде ул. 2002 елда күпернең беренче чираты ачылды, чынлыкта ул өч күпердән тора – Чулман, Архаровка һәм Көрнәле аша күперләр. Аларның гомуми озынлыгы 14 километр тәшкил итә. Ул вакыттан бирле егерме ел узды, һәм хәзер инде бу күпер үзен икътисадый яктан гына түгел, экология ягыннан да аклады дип ышанып әйтергә була.

Күпер төзелеше этабында ук Демидов алдыбызга киләчәк бурычын куйды – юл сервисын үстерергә

Фотолар «Алексеевскдорстрой» ААҖннән алынды.

кирәк. Нәрсә соң ул? Бу, гомумән, нигә кирәк? Ул чакта бу безнең барыбыз өчен дә аңлаешсыз нәрсә – үзенчә яңалык иде! Тик Алексей Иванович, күп очраклардагы кебек, алдан күреп эш йөртте. Без кечкенә сәүдә нокталарыннан башладык. Ә хәзер, карагыз әле, Алексеевск районы автомобильчеләр өчен нинди уңайлыга әйләнде!

Шундый бәхетле көн килеп җитте һәм предприятиебезгә инде туган төбәгебездә генә кысан була башлады. Без барлык торак пунктларга диярлек асфальт юллар салып чыктык, Алексеевск бистәсен төзекләндердек. Ул чакта Алексей Иванович яңа тәкъдим белән чыкты һәм, «Алексеевскдорстрой» үз эшчәнлегенең географиясен киңәйтә алсын өчен, күрше район башлыклары белән сөйләшүләр алып бара башлады. Әйе, ул таләпчән җитәкче иде, тик шул ук вакытта үзе шәхсән ярдәм итмәгәндә, теге яки проблеманы хәл итүдә дилбегәне үз кулына алмаганда, аның таләпләре тулысынча үтәлеп бетмәячәген аңлый иде. Аның киң җилкәсенә ышыкланып, илдә теләсә нинди икътисадый вазгыять очрагында да, бездә барысы да уңышлы булачагына ышанып, тынычлыкта эшләдек.

«ГАЛСТУКСЫЗ» ТҮРӘ

Безгә менә мондый күренешне еш күзәтергә туры килде: Алексей Иванович, кайсы авылга килсә дә, беренче эш итеп хуҗалык җитәкчесе белән түгел, гади халык белән аралашырга бара. Агроном һәм механизаторның кулларын кыса, сыер савучының хәл-әхвәлен сораша. Юк, ул беркайчан да кабинетта утыра торган башлык булмады, күп кенә хезмәт алдынгыларын шәхсән белә һәм хөрмәтли иде. Аның тагын бер гаҗәеп сыйфаты – яхшы эш өчен рәхмәтле булу һәм һәр кешегә, статусына бәйсез рәвештә, бу рәхмәтне җиткерә белү.

Социаль мәсьәләләр Алексей Иванович өчен һәрвакыт өстенлекле, беренчел булды. Нәкъ менә Алексеевск районының республикада тулысынча газлаштырылган беренче районнар исемлегенә керүе гаҗәп түгел. Демидов авыл хуҗалыгын үстерү һәм авылда уңайлы тормыш булдыру өчен искиткеч зур эш башкарды. Клублар дисеңме, мәктәпләрме, медицина хезмәте күрсәтүне көйләүме... Бу хакта бик озак сөйләргә була. Алексей Иванович безнең предприятиегә дә шундый ук максималь социаль юнәлешле булырга ярдәм итте. Без үз хезмәткәрләребез өчен йөздән артык йорт төзедек. Һәм бу аның белән бергә кабул ителгән уртак карар һәм эш булды. Беренче вакытта нинди авырлыклар кичерергә туры килүен бүген күз алдына да китереп булмый, чөнки 90 нчы елларда төзелеш материаллары табу батырлыкка тиң иде.

Алексей Иванович бүген дә бездәге балалар һәм яшүсмерләр социаль приютының химаячесе булып кала – хәйриячелек аның канына сеңгән. Алексеевскидагы Бадминтонны үстерү үзәгендә дә ул бик еш кунак була, бу үзәк нигездә аның тырышлыгы белән барлыкка килде. Мондый заманча спорт комплексына һәм бадминтончыларның җиңүләренә хәтта мегаполис та көнләшерлек. Алексеевск районы Алексей Иванович өчен туган төбәккә әйләнде. Бу аның йорты – башкача була да алмый, чөнки монда халык яхшырак яшәсен өчен, күпме хезмәтен куйды. Безнең кеше ул! Шуңа күрә аның белән һәр очрашуыбызга, аның һәр кайтуына шатланабыз.

Хөрмәтле Алексей Иванович, юбилеегыз белән! Сезнең фикердәшләрегез, хезмәттәшләрегез һәм Алексеевск районы халкы өчен бу көн – Сезгә ихлас хөрмәтебезне белдерергә тагын бер рәхәт сәбәп һәм тагын бер мөмкинлек. Сезнең кешеләргә кылган игелекләрегез үзегезгә һәрвакыт рәхмәт белән әйләнеп кайтсын. Сезгә нык сәламәтлек, һөнәри уңышлар һәм гаилә иминлеге телибез!

ДУС ТА, ОСТАЗ ДА

Габделәхәт Хәкимов,
Әтнә районы башлыгы

– Алексей Иванович Демидов белән юллар беренче тапкыр 1985 нче елларда кисеште. Гел бер тирәдә кайнадык. Хәтта, хәрби хезмәтне дә бер үк җирдә узганыбыз соңрак булса да билгеле булды.

Мин белгәндә үк Алексей Ивановичның абруе зур иде – егерме сигез яшендә районның беренче секретаре булган кеше бит! Әйе, башта мөнәсәбәтләр хәл-әхвәл сорашудан әллә ни узмады. Шул чагында ук сиздем – Алексей Иванович чын кешелеклелек сыйфатларына ия. Ә соңрак моның нәкъ тә шулай икәнлегенә инандым.

Илдә үзгәртеп корулар башлангач, Әтнә районын кабаттан торгызу буенча эшләр башланды. Бу мәсьәлә буенча ТАССР Министрлар Советында дүрт утырыш кына булды. Шуларның берсе Әтнәнең үзендә узды. Мәсьәлә гел безнең якка хәл ителмәде – Әтнәне Арчадан аерып алу икътисадый яктан отышлы түгел дигән карарлар чыгарылды. Мөстәкыйль район булып яши алмаячакбыз икән... Ләкин без югарыдагыларга моның киресен ышандыра алдык – районны кайтаруга хәер-фатыйхаларын алдык! Аллага шөкер, күпләрне көнләштерерлек итеп барлык юнәлештә дә эшне башладык. Безнең бу уңышлар барлык кешеләргә дә ошап бетмәгән күрәсең – күпсенүчеләр, көнләшүчеләр булды. Шул вакытта безгә ышанган, безнең өчен борчылган, дөреслекне тиешле кешеләргә җиткергән шәхес ул – Алексей Иванович. Шулай булгач, Әтнәнең бүгенге уңышларында аның да өлеше бар, чөнки ышаныч – зур әйбер ул.

Ышаныч турында сүз чыккач, юбиляр сөйләгән бер вакыйга искә төште. Алексей Ивановичның сабый чагы. Авылның колхоз рәисе ишле гаиләгә килеп керә. «Лёша, бар кара, мин сезгә нинди ат белән килдем. Чын юртак!» Малай капка төбенә йөгереп чыга. Җигүле атны күреп, якынрак килмәкче була. Ә ат пошкырып җибәрә, сикереп куя. Лёша шүрләп өенә йөгереп керә. Колхоз рәисе көлеп җибәрә: «Иван, малаең аттан курка икән», – ди. Ата кеше югалып калмый, гадәттәгечә, аңа гына хас булган акыллылык белән: «Курку түгел ул, кыюсызлану гына. Ә ул сыйфат узачак. Әллә нинди зур эшләргә сәләтле, батыр егет булачак әле ул. Менә күрерсең!» – ди. Ир бала тәрбияләгән әтиләр өчен зур сабак бу. Улыңның дәрәҗәсен төшермәү генә түгел, ә киресенчә, аны үстерү үрнәге! Алексей Иванович әлеге очракны гомергә истә калдырган.

Бу шәхесне белгән, бергә эшләгән кешеләр иң әүвәл аның кешелеклелек сыйфаты турында сөйли. Һәм ул чынлап та шулай. Кайда гына булса да, Алексей Иванович тырышып эшләп кенә калмый, ә халыкка хезмәт итә. Алексеевск районы башлыгы булып торганда, ул аралашмаган, ярдәм итмәгән гаилә калдымы икән? Кайгы, хәсрәте, борчуы бармы, һәрберсеннән хәбәрдар. Кеше үзе ярдәм сорап барганчы, ул инде үзе килеп җитә иде.

Әлеге сыйфатлар гаиләдән килә дип уйлыйм. Алексей Ивановичның әтисе Урта Девятово авылының иң хөрмәтле кешесе саналган. Югыйсә, җитәкче-фәлән дә түгел, гади бер мал табибы. Ә зирәк фикере, кешелеклелеге өчен аны барысы да хөрмәт иткән. Катлаулы хәлләрдә киңәш сорап иң беренче аңа килгәннәр. Авылда соңгы сүзне ул әйткән.

Ата кеше бу сыйфатларны сигез баласына да бирә алган. Демидовлар – атаклы, затлы нәсел. Әниләре исә холкы буенча сабыр, нечкә күңелле. Андый аналар турында әдәби әсәрләр күп языла. Алексей Ивановичка әнисенең шушы сыйфатлары да күчкән.

Ул минем өчен дус та, остаз да. Чордашлар булганга да фикер сөреше, тормышка карашлар тәңгәл килә. Ихластан хөрмәт итәм.

Хөрмәтле Алексей Иванович, гомер бәйрәмегез котлы булсын! Сезгә нык сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс энергия, гаилә иминлеге телим. Барлык план-максатларыгызны тормышка ашырырга язсын!



Фото: БизнесOnline

ЗИРӘК СТРАТЕГ, КИҢ КҮҢЕЛЛЕ ШӘХЕС

Илдус Зарипов,
Лаеш муниципаль районы башлыгы

– Алексей Иванович Демидовны аерым бер җылылык белән, бик шатланып күркәм юбилее белән котлыйм. Урта Девятово авылы һәм бөтен Лаеш районында яшәүче һәр кешенең тирән ихтирамын яулаган шәхеснең исеме бары тик уңай үзгәрешләр һәм игелекле гамәлләр белән бәйле.

Мин һәрвакыт Алексей Ивановичның һөнәри һәм кешелеклелек сыйфатларына, аның гаять көчле энергиясенә, кешеләргә, туган республикага файда китерү хакына фидакарь хезмәтенә, кешеләрне дәртләндерә һәм илһамландыра белү сәләтенә сокланам. Авылны төзекләндерү, яшьләр турында кайгырту, булышу... – әлеге игелекле эшләрнең исемлеген чиксез дәвам итәргә була. Чишмәләрне төзекләндерү үзе генә дә ни тора! Чишмәләр бүген Лаеш районы халкын җәлеп итүче урын гына түгел, бирегә бүген бөтен Татарстан халкы эчәр өчен тәмле су алырга килә. Һәм монда якташларны туплауга зур өлеш кертә торган бәйрәмнәр киң колач белән оештырыла.

Сезнең хезмәт эшчәнлегегез безнең өчен Ватан иминлеге хакына лаеклы хезмәт итү үрнәге булып хезмәт итә. Катлаулы бурычларны хәл итүгә югары профессиональ һәм дәүләти якын килә, киләчәкне алдан күреп эш итә белү, стратегларча зирәклек һәм кеше ихтыяҗлары турында даими кайгыртуыгыз нәтиҗәсендә Сез лаеклы рәвештә Лаеш районы халкының гына түгел, бөтен Татарстанның ихтирамын яуладыгыз.

Хөрмәтле Алексей Иванович! Шәхсән үз исемемнән һәм Лаеш районы халкы исеменнән туган төбәгебезнең иминлеге хакына эшләгән барлык эшләрегез өчен Сезгә зур рәхмәт әйтәсем килә! Яулаган үрләр яңа казанышларга ирешүдә ышанычлы нигез булсын, ә инициативаларыгыз һәрвакытта да фикердәшләр һәм дусларыгыз арасында яклау һәм хуплау тапсын.

Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, актив озын гомер, дәрт-дәрман, күңел күтәренкелеге телим! Барлык изге эшләрегездә дә уңышлар гына юлдаш булсын! Гаиләгезгә – игелек һәм бәхет, йортыгызга тынычлык һәм иминлек-муллык телим!

ДӨНЬЯНЫ ЯХШЫГА ҮЗГӘРТЕП

Рәгать Хөсәенов,
Лениногорск муниципаль районы башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры

– Хөрмәтле Алексей Иванович!

Сез 18 елга якын Татарстан Республикасы Хисап палатасын җитәклисез. Республика һәм муниципаль бурычларны тирәнтен аңлау, идарә итә белү таланты һәм һөнәрмәндлек Сезгә ТР Хисап палатасы эшен Идел буе федераль округында гына түгел, ил буенча да иң югары дәрәҗәләрнең берсенә күтәрергә мөмкинлек бирде. Бу муниципаль контроль-хисап органнарына аның белгечләреннән бәһасез методик һәм гамәли ярдәм алырга мөмкинлек тудыра. Моның өчен без Сезгә бик рәхмәтле.

Эшегез күп булуга да карамастан, Сез беркайчан да үз эшегезнең юнәлешләрен әһәмиятлерәккә-әһәмиятсезрәккә бүлмисез. Бу кешеләрнең тормыш сыйфатына йогынты ясаучы социаль проектларга, бигрәк тә балаларга бәйлеләренә дә кагыла.

Мәсәлән, ТР Бадминтон федерациясенең Кузәтчелек советы рәисе буларак, Сез кыска гына вакыт эчендә бадминтонны зурлар гына түгел, яшьләр һәм әле бөтенләй нәни татарстанлылар арасында да иң популяр спорт төрләренең берсенә әйләндерә алуга ирештегез.

Шунысы куанычлы: Сезнең ярдәм белән лениногорскилылар бадминтон белән дуслашты. Без спортның әлеге төрен дүрт юнәлеш: балалар, зурлар, өченче яшьтәгеләр һәм сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында үстереп, бик яхшы нәтиҗәләргә ирештек.

Бадминтон – ул, әйтергә кирәк, Сезнең оештыру сәләтен ачык күрсәтә алырлык иҗтимагый эшчәнлекнең бик күп төрләренең берсе генә. Тормыш үзе күрсәткәнчә, дөньяны тегеләй яисә бу ысул белән яхшыга үзгәртүчеләр алай ук күп тә түгел. Нәкъ менә аларның гамәлләре нәтиҗәсендә җәмгыять үсеш кичерә, ә үсеп килүче буын сәламәт һәм көндәшлеккә сәләтле булып җитешә.

Кешеләрне ишетә һәм бүген кирәк булганны гына түгел, иртәгесе көн өчен таләп ителгәнне дә эшли белү кебек сыйфатларыгыз, Алексей Иванович, Сезгә эшегезне шәп итеп башкару белән беррәттән, күп нәрсәләрдә республика халкының лаеклы киләчәген билгеләргә дә ярдәм итә.

Алексей Иванович! Лениногорскилылар Сезгә иң мөһиме – сәламәтлек, эшегездә уңышлар, гаиләгезгә тынычлык һәм иминлек тели!

ТАТАРСТАН ҺӘМ ИЛ БӘХЕТЕ ХАКЫНА

Михаил Афанасьев,
Яшел Үзән муниципаль районы башлыгы, Яшел Үзән мэры

– Хөрмәтле Алексей Иванович! Сезне ихлас күңелдән юбилеегыз белән котлыйм!

Бүген Яшел Үзән районы – Татарстанның актив үсештәге төбәге, ул туристлар өчен дә, потенциаль инвесторлар өчен дә тигез дәрәҗәдә кызыклы. Күп очракта бу – район һәм аның халкына игътибарлы, кайгыртучан мөнәсәбәт күрсәтүче тәҗрибәле һәм җаваплы җитәкче буларак Сезнең казаныш. Без күтәргән сорауларга Сездән күп тапкырлар уңай җавап алынды, алар конкрет эш һәм бурычлар аша гамәлгә ашырылды.

Сезнең хезмәт биографиягез – Татарстан Республикасы һәм илебез бәхете хакына үз эшен яратып башкаручы эшлекле һәм максатчан кеше тормышы үрнәге!

Күркәм юбилей көнендә Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, гаҗәеп дәрт-дәрманыгыз һәм күңел күрлеген саклавыгызны, яңа казанышларга һәм зур җиңүләргә ирешүегезне телибез!

Хөрмәт белән,
Михаил Афанасьев

ҺӘР КЕШЕДӘ КОЯШ БАР

Азат Вәлиев,
Әгерҗе муниципаль районы башлыгы

– Хөрмәтле Алексей Иванович! Сезне ихлас күңелдән 70 яшьлек юбилеегыз белән котлыйбыз! Зирәклек, хезмәт сөючәнлек, инициатива, эштә даими рәвештә яңа юл һәм ысуллар эзләү, кешеләр турында ихлас кайгыту – Сез ирешкән югары һөнәри казаныш һәм гаять зур абруйның нигезе.

Һәр кешедә кояш күрә белүегез тирә-юнегездәгеләргә үз сәләтләрен ачарга, иң кыю ниятләрен тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Уңыш көчлеләр, катлаулы мәсьәләләрне хәл итүгә курыкмыйча, ышаныч һәм тәвәккәллек белән алынучылар ягында. Бу Сезнең үрнәктә дә ачык күренә. Япь-яшь җитәкче булсагыз да, үз вакытында Алексеевск районын Татарстан Республикасының алдынгы районнары сафына чыгардыгыз.

Тирән белем, кешеләр белән бергә, иңне иңгә куеп эшләү, тапшырылган эшкә җаваплы мөнәсәбәт, намуслылык, лидерлыкка омтылыш Сезнең җитәкчелектәге Татарстан Республикасы Хисап палатасын төзүдә уңышның нигезе булып торды. Ул – Россия Федерациясендә иң яхшы төбәк хисап палаталарының берсе, халыкара финанс контроле җәмәгатьчелегендә дә танылу алды.

Сезнең мәктәпне узу, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өлкәсендәге бай тәҗрибәгезгә, иң күркәм традицияләргә кушыла алу мөмкинлеге өчен язмышыма рәхмәтле.

Сезнең үзегезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, бәхет, иминлек, җаваплы эшегездә яңадан-яңа уңышлар, дусларыгыз һәм фикердәшләрегезнең хуплавын тоеп яшәвегезне телим! Туганнарыгыз һәм үзегезгә якын кешеләр җылысына тиенеп, аларның кайгыртучанлыгын күреп яшәгез!

Хөрмәт белән, укучыгыз
Азат Вәлиев

ЧЫН ВАТАНПӘРВӘР

Александр Никошин,
Әлки муниципаль районы башлыгы

– Хөрмәтле Алексей Иванович! Әлки районы халкы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Сез республикабызда зур хөрмәт казандыгыз, Татарстанны үстерү, кешеләрнең тормыш дәрәҗәсен яхшырту өчен бик күп эш башкардыгыз.

Тормышның ачысын да, төчесен дә татырга туры килгән кебек. Әмма бер акыл иясе: «Кеше гомере тукыма түгел, аның озынлыгын үлчәмиләр, ә алтын кебек, авырлыгын үлчәп алалар», – дип әйткән. Сезнең тормыш, чыннан да, шактый саллы, чөнки аның бәһасен еллар саны түгел, ә игелекле эшләр билгеле.

Гомер юлында өлге итеп алырлык көчле шәхес, остаз, укытучы очрау – һәр кеше өчен зур уңыш. Алексей Иванович, Сез – бөтен нәрсәдә өлге булырлык, ничек эшләргә, әйләнә-тирәдәгеләргә нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклеген күрсәткән үрнәк шәхес.

Кеше язмышы – кабатланмас тормыш китабы, һәм аның һәр сәхифәсе – тарихның бер өлеше. Ә тарих Сезнең кебек кешеләр хезмәте белән языла. Хезмәт сөючәнлек белән ныгытылган җаваплылык, намуслылык һәм максатчанлык Сезгә искиткеч һөнәри үрләр яуларга, җәмгыятьтә абруй казанырга мөмкинлек бирде. Сез читен юллардан барырга курыкмыйсыз. Сез башкаларга гына түгел, үз-үзегезгә карата да таләпчән. Алдыгызда торган күпсанлы бурыч-мәсьәләләрне Сез һәрвакыт бик җентекләп, җиренә җиткереп хәл итәсез.

Сез – югары профессиональлек, компетентлык һәм иң беренче чиратта үз-үзегезгә таләпчәнлек белән бөтен республикада һәм Россия Федерациясендә хезмәттәшләрегез арасында какшамас абруй һәм ихлас ихтирам яулаган шәхесләрнең берсе.

Бөтен тормышыгыз Татарстан белән өзлексез бәйләнгән: гомер юлын гади хезмәткәр булып башлап, республикадагы иң мөһим учреждениеләрнең берсе – Хисап палатасы җитәкчесе дәрәҗәсенә ирештегез. Бу исә хезмәт сөючәнлек, тырышлык һәм эшкә җаваплы мөнәсәбәт турында сөйли. Сез, җитәкче буларак, дәүләт акчаларының максатчан һәм законлы кулланылышын күзәтәсез. Муниципаль югарылыкта финанс контролен үстерүгә һәм камилләштерүгә керткән өлешегез һәм күпьеллык намуслы хезмәтегез республика җитәкчелеге тарафыннан берничә тапкыр билгеләп үтелде.

Алексей Иванович! Без Сезне искиткеч кеше, югары белемле принципиаль белгеч, ил үсешенә лаеклы өлеш керткән чын ватанпәрвәр буларак беләбез һәм чын күңелдән хөрмәт итәбез. Сездә зур практик тәҗрибә, оста оештыручы һәм грамоталы җитәкче таланты бик уңышлы яраша. Сез туплаган белем-күнекмәләрегезне һич саранланмыйча уртаклашасыз һәм яшь белгечләр өчен үрнәк булып торасыз.

Миңа калса, Сезнең өчен ничә яшьтә булу әллә ни мөһим түгел, чөнки Сез күңелегез белән яшь, бар көчегезне биреп эшли торган җаваплы хезмәтегез бар. Гомерегезнең һәр елы иҗади энергия, якыннарыгызның йөрәк җылысы белән тулып торсын, ә тирән белем, зирәклек һәм тәҗрибәгез киләчәктә дә республиканы үстерүгә хезмәт итсен!

Туган көнегез белән ихлас тәбрик итәм! Мин чын күңелдән Сезгә күтәренке кәеф, төкәнмәс дәрт-куәт, күңел тынычлыгы, алдыгызда торган авыр һәм мөһим бурычларны тормышка ашыруда көч һәм түземлек телим. Идеяләр һәм инициативалар уңышлы, ә фикердәшләрегез ышанычлы булсын.

ҖИТӘКЧЕБЕЗ–
РУХЛАНДЫРУЧЫ ШӘХЕС

Кеше намуслы булырга тиеш, бу теләсә нинди шартларда, теләсә кайсы хакимияттә үтәлерлек нәрсә. Намуслылык геройлык таләп итми, ул кабахәтлектә катнашмауны аңлата.

Фазыл Искәндәр

Татарстан Республикасы Хисап палатасы коллективы үз җитәкчеләрен ихлас күңелдән туган көне белән тәбрик итә!

– Татарстан Хисап палатасы рәисенең шәхси абруе һәм саллы тормыш тәҗрибәсе инде унсигез ел буе гомумән бөтен коллектив һәм шәхсән һәрбер хезмәткәрнең уңышлы, нәтиҗәле эшенең ышанычлы нигезе булып тора.

Алексей Иванович Демидов җитәкчелегендә без аякка бастык, үсешкә ирештек, төбәктәге коллегаларыбыз арасында лаеклы урын алдык, Россиядәге иң абруйлы контроль-хисап палаталарыннан берсе саналабыз.

Республикабыз дәүләт финанс контроле органы рәисенең лидерлык һәм оештыру сыйфатлары Россия һәм халыкара дәрәҗәдәге һөнәри берләшмәләр эшчәнлегендә югары бәяләнә.

Алексей Иванович күп еллар буе финанс контроле төбәк органнарының Европа оешмасында Дәүләт аудиторлары гомумроссия берләшмәсенең вәкиле булып тора, ул шулай ук Россия Хисап палатасы каршындагы Контроль-хисап органнары Советы Президиумы әгъзасы да, Советның Идел буе федераль округындагы бүлеген дә җитәкли, дәүләт-финанс контроле мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты Указы белән оештырылган һәм финанс-бюджет даирәсендә тикшерү һәм хокук саклау органнарының уртак нәтиҗәле эшенең Россиядәге тиңдәшсез тәҗрибәсе дип танылган Ведомствоара координацияләр советы эшчәнлеге белән дә идарә итә.

Үзенең күп кеше язмышында никадәр мөһим роль уйнаячагын, туган Татарстанындагы тормышны яхшыртуга никадәр зур өлеш кертәчәген, мөгаллим һәм остаз сыйфатында танылачагын, бик күп дәүләт һәм җәмәгать бүләкләренә лаек булачагын, ихлас рәхмәт сүзләренә күмеләчәген гади авыл егете үзенең хезмәт юлы башында гөманлый алдымы икән...

«Яшьлегемдә журналистика факультетына керергә хыялландым – мәктәптә әдәбият белән мавыга идем. Әмма нәтиҗәдә документларымны авыл хуҗалыгы институтына тапшырдым. Каникул вакытында өч ел рәттән совхозда йөкче булып, өч ел тракторда, еш кына төнге сменада, эшләдем. Хезмәт юлымны гади эшче булып башладым. Аннары – агроном-мелиоратор, бүлек агрономы. Армиядә хезмәт иткәннән соң Лаеш районындагы иң зур «Россия» совхозында башта баш агроном, аннары директор булдым. Аннары 20 елдан артык Алексеевск районы белән җитәкчелек иттем. 2004 елның июленнән исә республикабызның Хисап палатасын җитәклим».

Гаиләдә нигез салынган һәм еллар буена сакланган хезмәт сөючәнлек һәм кешеләр белән аралашуның мөһимлеген яхшы аңлау аңа тормышның барлык юнәлешләрендә ярдәм иткән, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын чарлаган, фикердәшләр табарга булышкан.

Алексей Иванович гомере буе халык зирәклегенә тугры булып яши: кешенең төп булышчылары – дисциплина һәм физик та, рухи да хезмәт, ә иң зур дошманы – тәкәбберлек һәм зарлану, болар көн саен шәхси үрнәк белән раслана торган хакыйкать.

Рәхмәтле һәм ихтирамлы бала һәм бертуган, кече ватанга тугрылык үрнәге, юмарт күңелле ата, принципиаль җитәкче, сабыр остаз, ышанычлы һәм сизгер дус, рус сөйләменең матурлыгына, поэзия һәм музыкага гашыйк зыялы шәхес. Тормышның кадерен аңлаган һәм көч-куәтен белгән гаҗәеп якты шәхес Алексей Иванович белән таныш һәркем аңарга шуларның барысы да хас булуын дәлилли ала.

Кадерле Алексей Иванович!

Игелек эшләү, шәфкать күрсәтү, гореф-гадәтләрне саклауның сафландыргыч куәтен Сез безгә искиткеч яратү һәм аталарча сабырлык белән тапшырасыз. Башлаган һәрбер эшкә тугрылык, һәр яңа эш, проект белән илһамланып яшәү, аларны һәрвакыт уңышлы башкарып чыгу – иҗади һәм талантлы җитәкчегә хас асыл сыйфатлар.

Сез төзегән 70 катлы йортның 18 каты безнең күз алдында салынды.

Татарстан Республикасы Хисап палатасының һәр хезмәткәренә шәхсән керткән өлешегез, кеше язмышы өчен үтә җаваплылыкны аңлауны таләп иткән сак һәм ихтирамлы мөнәсәбәтегез өчен Сезгә рәхмәтебезне җиткерәбез!

Киләчәк яңа идеяләр белән тулы. Сезгә хас батырлык һәм ныклык, рухи һәм физик көч беркайчан да ташламасын үзегезне, гаиләгездәге мәхәббәт һәм гармония, дуслар һәм якыннарыгызның җылы мөнәсәбәте исә барлык планнарыгызны тормышка ашырырга булышсын!

Ихтирам белән,
Татарстан Республикасы
Хисап палатасы коллективы

РЕСПУБЛИКАНЫҢ БАШ АУДИТОРЫ

Татарстан – һәрбер муниципалитетта контроль-хисап палатасы төзелгән Россиядә беренче төбәк ул. Һәм хәзер республикадагы муниципаль финанс контроле системасы Россиядә иң яхшылардан санала. Бүген республика контроль-хисап палаталары хезмәткәрләре әлеге эшнең ничек башлануын һәм үсүен искә төшерә. Һәм ТР Хисап палатасын оештыручылардан берсе, үзләренең җитәкчеләре Алексей Демидовны юбилее белән тәбрикли.

УЛ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ, ТИКШЕРҮ ҺӘМ ХОКУК САКЛАУ ОРГАННАРЫН БЕРЛӘШТЕРДЕ

Алексей Иванович Демидовның турыдан-туры катнашында Татарстан муниципаль контроль-хисап органнары рәисләренең муниципаль вазыйфаларны да башкарачагы турында закон кабул ителгән Россиядәге беренче төбәккә әйләнде.

Демидов җитәкчелегендәге, Татарстан Республикасы Президенты Указы белән оештырылган Дәүләт-финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләр советы Россия төбәкләре өчен тиңдәшсез булып тора. «Ул контрольдә тоту, тикшерү һәм хокук саклау органнарын берләштерде», **– ди Казан шәһәре контроль-хисап палатасы хезмәткәрләре.**

НОВАТОРЛЫК СТИЛЕ ҺӘМ ИҖАДИ ЯКЫН КИЛҮ

Республика баш аудиторы вазыйфасында Алексей Демидов дәүләт контроле бурычларын гамәлгә кертүдә новаторлык стиле һәм иҗади якын килү күрсәтте.

Яр Чаллы шәһәре контроль-хисап палатасы коллективы муниципаль контрольне булдыру һәм үстерүдә турыдан-туры катнашуы өчен Алексей Ивановичка рәхмәтле.

– Ул талантлы оештыручы, законлылык һәм хокукны үзен аямыйча яклаучы, – дип искә **ала Минзәлә районы контроль-хисап палатасы** белгечләре. – Шул ук вакытта ул һәрвакыт бик ачык һәм ярдәмчел кеше булып кала.

ҺӨНӘРИ ФИНАНС КОНТРОЛЕРЛАРЫНЫҢ АТАСЫ

Татарстандагы барлык контроль-хисап палаталары компьютер җиһазлары белән тәэмин ителгән, республиканың контроль-хисап органнары Советында исә тәҗрибә алмашырга да, методик ярдәм алырга да була.

– Ә иң мөһиме, – дип саный **Чүпрәле районы контроль-хисап палатасы** хезмәткәрләре, – Алексей Демидовның компетентлыгы һәм җаваплылык хисе һөнәри финанс контролерлары формалашуга булышты.

«КОСМИК ПОЭЗИЯ»ГӘ ГАШЫЙК КЕШЕ

Демидов – искиткеч олы, олпат шәхес, шул ук вакытта бик тыйнак та, дип саный коллегалары гына түгел, аның ведомствосына бөтенләй катнашы булмаган кешеләр дә.

– 2008 елда Алексей Иванович, Россия Хисап палатасы рәисе Сергей Степашин белән бергә, Чистайдагы Борис Пастернак мемориаль музеена кергән иде, – дип искә ала **музей хезмәткәрләре. –** Һәм соңрак бу турыда «Үзем өчен көтмәгәндә бөек шагыйрьнең поэтик космосын ачтым», - дип сөйләде.

Музейга өстәмә мәйдан таләп ителүен белгәч, әлеге йортта яшәүчеләрне башка торакка күчерү өчен акча бүлергә карар кылалар. Алар бөтен уңайлыклары булган фатирларга күчерелә, музейга исә 230 кв. метр мәйдан өстәлә, реконструкция ясала, шул рәвешле ул шәһәрнең төп брендларыннан берсенә әйләнә.

– Алексей Иванович, Сезнең ачык, зыялы булуыгыз, һәркайсыбызның кадерен белүегез сокландыра, без исә Сезнең һәрчак ярдәмгә әзер булуыгызны яхшы беләбез. Татарстан Республикасының барлык муниципаль контроль-хисап палаталары исеменнән Сезне котлыйбыз һәм ихластан үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет, бөтен эшләрегездә уңышлар телибез! Ышанычлы дусларыгыз һәм коллегаларыгыз исә һәрвакыт таяныч булсын!

БАДМИНТОН ЯРАТУЧЫЛАР АРТА

Фәрит Вәлиев,
ТРның атказанган физик культура хезмәткәре, Татарстанда бадминтон спортына нигез салучы

– Спортта, калган башка өлкәләрдәге кебек, оештыручы мөһим. Максатларны ачыкларга, аларга ирешү юлларын билгеләргә, тупларга сәләтле кеше. Әгәр мондый кеше табыла икән, нәтиҗә булачак. Бадминтон кебек спорт төрендә сыйфат ягыннан без ирешкән ыргылыш – моңа чын дәлил.

Бүген республикада 15 меңнән артык кеше – тулы бер армия! – бадминтон белән шөгыльләнә. Әле ун ел элек кенә без бу турыда хыяллана да алмый идек. Спортның иң массакүләм төрләреннән берсенең асылда җитди перспективалары юк иде. Гәрчә ТРнда бадминтонны үстерү алты дистә еллык тарихка ия булса да. Дөрес, беренче елларда бөтен республикага иллеләп кенә спортчы саналган.

ТР Хисап палатасы рәисе Алексей Демидов ТР Бадминтон федерациясенең Күзәтчелек советы рәисе итеп сайланган 2011 ел кискен үзгәреш елы була. Алексей Иванович үзе болай дип искә төшерә: ул вакытта бадминтон турында бөтенләй диярлек белми. Ләкин Бадминтон буенча милли федерация президенты Сергей Шахрай (ул вакытта Россия Хисап палатасы Аппаратын җитәкли) Рөстәм Миңнехановтан республикада бадминтонны үстерү һәм популярлаштыруга ярдәм итүне сорагач, Татарстан Президенты Демидов кандидатурасын тәкъдим итә. Спортка битараф булмаган кеше, Татарстанда да, аннан читтә дә зур абруйга ия, аның оештыру сәләте вакыт белән сыналган – Алексей Иванович файдасына дәлилләр үзләре өчен үзе сөйли...

Тормыш мондый сайлауның дөреслеген раслады. Федерациянең Күзәтчелек советы рәисе итеп сайлануга ук Демидов төп бурычларны төгәл билгеләде: беренчесе – массакүләм спортны күтәрү һәм шөгыльләнүчеләр санын арттыру, икенчесе – югары казанышлар спортын үстерүгә тиешле этәргеч бирү һәм Россия җыелмасында Татарстанны лаеклы күрсәтә алырлык бадминтончылар әзерләү.

Яңа бурычларга ярашлы рәвештә Алексей Иванович эшне оештыруны, спортның перспективалы төрен финанслауны төптән үзгәртә. Табигый ки, федерация, тренерлар, спортчыларда ышаныч пәйда була: республикада бадминтонны билгеләнгән югарылыкка күтәрү безнең хәлдән киләчәк. Нәтиҗәләрне озак көтәргә туры килми. 2021 ел ахырына республикада бадминтон белән шөгыльләнүчеләрнең саны берничә мәртәбә артуыннан тыш, матди база сыйфат үзгәрешләре кичерә. Казанда хәзер Россиядә тиңе булмаган Бадминтон үзәге оештырыла, бадминтон буенча Олимпия резервы республика спорт мәктәбе эшли, зур халыкара ярышлар үткәрелә. Бадминтон белән шөгыльләнүче спортчыларның ышанычлы тылы һәм иртәгәсе көнгә өмете бар.

Хөрмәтле Алексей Иванович! Татарстанның барлык бадминтончылары исеменнән Сезне юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез! Сезгә хас зирәклек һәм кешелекле мөнәсәбәт алга таба да озак еллар дәвамында ориентир булсын, ә киләчәктә безне әле тагын уртак җиңүләр көтеп торсын!

ИГЕЛЕККӘ СӘЛӘТЛЕ ЗАТ

Фәнил Әһлиуллин,
Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры

– Безнең тирә-ягыбызда хезмәт вазыйфабыз кушканга, эш буенча аралаша торган кешеләр аз түгел. Сүз Алексей Иванович Демидов турында барган очракта исә «хезмәт вазыйфабыз кушканга» дигән коры сүзтезмә бөтенләй килешми. Җитештерүгә бәйле җитди мәсьәләләрне хәл итү, хезмәттәшләр, дуслар, якташлар белән очрашу, кем булуы мөһим түгел... – Алексей Иванович һәрвакыт ачык, игътибарлы, ярдәмчел. Килешәсездер, болар – хәзерге заман идарәчеләре өчен сирәк сыйфатлар. Ә аның якыннарына, фикердәшләренә карата әчкерсезлеге, кече күңеллелеге – минемчә, үрнәк итеп алырлык мисал. Бу хакта ишетеп кенә белләм дип әйтә алмыйм. 2006 елда, мин Кырымда ял иткән вакытта, Алексей Иванович шалтыратты да абыйсы Анатолий Ивановичка кулдан килгәнчә күзколак булуымны сорады – ул мондагы шифаханәләрнең берсендә дәвалана икән. Аның үтенечен игътибарсыз калу мөмкин түгел, чөнки сүзләреннән, тавышыннан ук ничек борчылганлыгы сизелеп тора иде. Демидовлар гаиләсе белән әнә шулай дуслашып киттек, һәм бу дуслык гомерлек булып чыкты.

Алексей Иванович – искиткеч намуслы, әдәпле, хезмәт сөючән кеше. Мин аның республикабыз, барлык татарстанлылар өчен күпме яхшы, мөһим эшләр башкаруын күрәм. Җаваплы урында утырган хәлдә дә, ул кешеләргә карата кайгыртучанлык сыйфатын югалтмый, булышырга һәм игелек кыларга мөмкинлекләр таба. Туган авылы Урта Девятово, туган районы һәм ике дистә ел җитәкләгән Алексеевск районы – Демидов турында һәр җирдә яхшы яктан гына искә алалар, һәркайда аның изге эшләренең күркәм нәтиҗәләре күзгә ташлана.

Кадерле Алексей Иванович! Сезгә чын күңелдән иминлек, бәхет һәм алдагы эшләрегездә уңышлар телим. Сезнең тәҗрибәгез, белемегез һәм талантыгыз әле озак вакытлар кулланыш табар, ә игелек кыла белү сәләтегез тормышыбызны бераз гына булса да җылырак һәм яктырак итәргә булышыр дип ышанам. Сезгә, туганнарыгызга һәм якыннарыгызга сәламәтлек телим!

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-79
8-9600-487-900
8-9172-740-352

Реклама 16+

ЭШКӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

ИлдарТаҗетдинов,
Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы

– Эшлеклелек сыйфатлары, абруе һәм профессиональлеге шик тудырмый торган җитәкчеләр бездә һәрвакыт алтын исәбендә йөри. Бәлки шуңадыр, гомер буе алар үз җилкәләрендә йөрткән йөк башкалар өчен күтәрә алмаслык була. Татарстанның Хисап палатасы рәисе Алексей Демидов – алтын белән бәһаләнә торганнар исәбеннән.

Алексей Ивановичның профессиональ даирәдәге абруе бәхәссез, ул күркәм нәтиҗәләр белән күп тапкырлар исбатланган. Демидов җитәкләгән Татарстан Республикасы Хисап палатасы – Россия контрольхисаплау палаталары арасында иң абруйлылардан берсе. Төбәк финанс контроле органнарының Европа оешмасында нәкъ менә Алексей Ивановичның озак еллар дәвамында дәүләт аудиторларының гомумроссия җәмәгатьчелеге вәкиле буларак катнашуы да очраклы түгел.

Җитәкче булып тумыйлар – җитәкче булып җитешәләр. Алексей Ивановичның күркәм тормыш юлы – моңа иң яхшы мисал. Лаеш районына кергән зур «Россия» совхозында баш агроном, аннан соң директор, соңрак егерме елдан артык Алексеевск районы башлыгы – барлык бу вазыйфаларда җитәкче Демидов, югары нәтиҗәләргә ирешеп, үзенең иң яхшы сыйфатларын ача. Хәзерге вакытта ТР Хисап палатасы рәисе урынында эшләгәндәге кебек үк.

Алексей Иванович үзенең туган ягын ярата, туып-үскән авылы һәм авылдашлары өчен бик күп нәрсә эшли. Принципиаль һәм кырыс җитәкче, ул аралашуда бик әдәпле, дусларына һәм хезмәттәшләренә карата игътибарлы һәм кайгыртучан.

Хөрмәтле Алексей Иванович! Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм! Идарәче таланты, белем һәм тәҗрибә, Сезгә хас кешелеклелек сыйфатлары әле озак еллар кирәк булачагына, ә Татарстанның үсешенә керткән өлешегез арта барачагына ышанам. Барлык уй-ниятләрегез тормышка ашсын, ә туганнар, дуслар һәм хезмәттәшләрегез Сезнең ышанычлы таянычыгыз, яңа казанышларга ирешү юлында рухи һәм физик көч чыганагы булып калсын. Бәхетле һәм сәламәт булыгыз!

ҖАН ҖЫЛЫСЫ КӨЧЕ

Земля 60 лет
Республиканский кадастровый центр

– Кадерле, хөрмәтле Алексей Иванович!

«Земля» Республика кадастр үзәге коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән тәбрикләргә ашыгам! Бәхет, мул тормыш, якыннарыгызның җылысы – әлеге теләкләрнең һәрберсе күп мәртәбәләр Сезгә әйләнеп кайтсын. Озак еллар дәвамында без Сезнең белән якын рухи элемтәдә торабыз. Сез «Земля» РКҮнең элеккеге җитәкчесе Нәҗип Бакиров белән дә бик дус идегез, бу турыда ул үзе дә кешеләр алдында еш әйтә иде.

Нәҗип Баһман улы шулай ук һәрвакыт Сезнең белән үзара аралашып, бүлешеп яшәү-эшләү турында һәрвакыт аерым бер җылылык белән искә ала иде. Сезнең дуслык бер генә дистә елга сузылмаган, авыр хәлләрдә дә, шатлыклы мизгелләрдә дә Нәҗип Баһман улы һәрвакыт үз уй-фикерләрен Сезнең белән уртаклашты. Без, «Земля» РКҮ коллективы, бу хәлләрнең шаһиты булдык. Эш мәсьәләләре, планлаштыру буенча озакка сузылган уртак әңгәмәләр беркайчан да бушка узмады – һәрвакытта да нинди дә чишелеш, җавап яисә ярдәм табылып килде.

Кешенең нинди генә вазыйфа биләвенә карамастан, Сез һәркемгә ачык, игътибарлы, дустанә мөнәсәбәт күрсәтүегез белән аерылып торасыз. Бөтен кешегә карата ачык мөгамәлә, ихтирамлы-кызыксынучан мөнәсәбәт «Земля» Республика кадастр үзәге коллективына һәм Нәҗип Баһман улына илһам биреп торды. Тормышка һәм аралашуга мондый мөнәсәбәт Сездәге көче күңеллелекне күрсәтә. Әлеге җылыны булдыра алганча озаграк саклагыз! Кирәк чакта ярдәм кулы сузарга әзер игелекле, фидакарь кешеләр Сезнең тормышыгызда гел очрап торсын! Һәм без, «Земля» РКҮ коллективы, бу җылы мөнәсәбәтләрне сакларга һәрвакыт әзер. Сезгә ныклы сәламәтлек телибез! Күркәм юбилеегыз белән!

«Земля» РКҮ коллективы

РЕКЛАМА

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр /

Акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Мөхлисә Бубый **НИЧЕК** беренче хатын-кыз казыя була

Метрика кенәгәләрендә **НӘРСӘЛӘР** теркәлгән

Казакларда **КЕМ** яши

МӨХЛИСӘ БУБЫЙ – МӨСЕЛМАН ДӨНЬЯСЫНДА БЕРЕНЧЕ КАЗЫЯ

Нурия Маннапова

Тирә-юньдә күзне камаштырырлык аклык, тып-тын. Бары тик ат чанасының шыгыр-шыгыр карны ерып баруы гына әлеге тынлыкны боза. Чанада – ике баласы белән толыпка төренеп утырган хатын. Ерак авылларның берсеннән аны, мөселман хатынын, абыйсы белән энесе ире рөхсәтеннән башка аерып алып кайтып бара... Күрелмәгән хәл... 18 елдан соң аның исеме бөтен мөселман дөньясына ишетеләчәк – Мөхлисә Бубый хатын-кызлардан беренче казыя булып танылачак.

Мөхлисә 1869 елның 5 мартында (иске стиль белән 21 февраль) Вятка губернасы Сарапул өязе Әгерҗе волостенең Иж-Бубый авылында дөньяга килә. Заманының барлык татар кызлары кебек, башлангыч аң-белемне энисеннән – Бәдрелбанат абыстайдан ала. Өч яшендә ул инде хәреф таныган, 4 яшендә укырга-язарга өйрәнгән. Соңыннан абыстай кызына гарәп, фарсы телләрен өйрәтә башлаган. Бу гаиләнең йортында бай китапханә булган. Үсә төшкәч, этисеннән, фәнни гыйлемгә ия булган абыйсы Гобәйдулла белән энесе Габдулладан Мөхлисә тагын да тирәнрәк белем алган.

КЫЮ ХАТЫН

Мөхлисәне 1890 елда Минзәлә өязенең Табанлы күл авылы мулласы Җәлалетдин Әхмәтҗан улына кияүгә бирәләр. Һичшиксез, ата-ана кызлары бәхетле булыр, мул тормышта яшәр дип өметләнгән. Инде берничә ел энисенә кызлар укытуда ярдәм итеп килгән Мөхлисә дә, үз эти-энисе кебек, ире белән бергә кулга-кул тотынышып, авыл халкын агарту, мәгърифәтле итү турында хыялланган. Ләкин дуамал, бозык фигыльле, каты күңелле, укыту эшен бер дә яратмаган хәзрәт яшь абыстайның кызлар укыту теләгенә катгый каршы килгән. Ул гына да түгел, мулла Мөхлисә абыстайны китап укудан да тыярга тырышкан. Аның көннән-көн караңгылана, аяусызлана барган тормышында ике кечкенә кыз – ире сүзенә карамастан тәрбиягә алган ятимә Наҗия һәм үз кызы Мөнҗия генә юаныч булган.

Ихтимал, Мөхлисә Бубыйның язмышы да башка күп кенә авыл муллалары хатыннары язмышы кебек барган булыр иде, ләкин кыз туганнарына Минзәлә ярминкәсеннән кайтышлый хәл белергә керген

Фотолар автордан алынды.

абыйсы һәм энесе ярдәм иткән. Мөхлисәнең авыр тормышын, иренең холыксызлыгын күргән абыйсы һәм энесе аны үзләре белән алып китәргә уйлаган. Бу адымга хәзрәтнең рөхсәте булмау аларны ахыр чиктә хәйләгә этәргән. Мөхлисә, ир туганнарын авыл капкасына кадәр озатабыз, дигән хәйлә белән чыга һәм, ике кызын алып, аларның чанасына утырып китә. Атлар чаптырып бик тиз күздән югала. Күрәсең, үз гаебен яхшы аңлаган, Бубыйларның бу тәвәккәл адымына шаккаткан хәзрәт, ачуы килсә дә, хатынын эзәрлекләми, ләкин аермый да. Бары 1917 елда гына казый Ризаэтдин Фәхреддин фәтвасы нигезендә бу аерылышу рәсми төс ала.

МӘГЪРИФӘТ ЮЛЫНДА

Мөхлисәнең кайтуы 1898 елда Габдулла белән Гобәйдулла этиләре мәдрәсәсен үзгәртеп корган вакытка туры килә. Ирләр мәдрәсәсен үзгәртүдәге уңышлары аларда кыз балаларга да нигезле белем бирерлек яңа типтагы кызлар мәктәбе төзү фикерен уяткан. Бубыйлар, хатын-кызлар мәктәбе булдырыр өчен, иң әлек белемле мөгаллимәләр кирәклеген аңлый. Шуңа күрә кыз туганнарын һәм хатыннарын яңача укытырга әзерли башлыйлар. Мөхлисә, бертуганнарының хатыннары Нәсимә, Хөснифатыйма, кичләрен ирләрдән сабак өйрәнеп, көндезен кызларны җәдид ысулы белән укыту-тәрбия эшенә тотына, яңа типтагы хатын-кызлар мәдрәсәсен оештыруда актив катнаша. 1901 елда 6 сыйныфлы татар хатын-кызлар мәдрәсәсе ачыла, һәм Мөхлисә Бубый аның мөдире итеп билгеләнә. Анда дин гыйлеме белән беррәттән төрле дөньяви фәннәр, ә 1905 елдан рус теле укытыла. 1907 елда Сарапул өязе земствосы акчасына 1 сыйныфлы рус-татар училищесы ачыла, ул хатын-кызлар мәдрәсәсенең бер бүлегенә әверелә. 1907 елда Сарапул өяз земствосы бертуган Бубыйларның татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү эшен башкаруларын рәсми рәвештә таный: башлангыч татар училищесы укытучысы дәрәҗәсе өчен имтиханнар кабул итәргә, аларны уңышлы тапшыручыларга «укытучы» таныклыгы бирергә рөхсәт алына. Аларга «татар мәктәпләрендә укытучы-мөгаллим» һәм «укытучы-мөгаллимә» исеменә имтихан алу һәм таныклык бирү хокукы бирелә. Иж-Бубый мәдрәсәсе мөселман мәктәп-мәдрәсәләре өчен мөгаллимәләр әзерләүдә беренче уку йорты була. Мәктәптә дин нигезләре, дөньяви фәннәр, ягъни төрки-татар, гарәп, фарсы, рус телләре, география, гомуми тарих, риторика, математика, физика, зоология, ботаника, моннан тыш хатын-кыз өчен әхлак (һәм психология), гигиена, балалар тәрбиясе, йорт (хуҗалык) алып бару, кул эшләре кебек мөһим дәресләр дә булган. Моңа кадәр мондый исемне рәсми рәвештә ирләргә бары тик Оренбург дини идарәсе генә бирүен искә алыйк. Укытучы хатын-кызларга исә бу вакытка кадәр рәсми таныклык бирүче уку йорты булмаган. Габдулла Бубый сүзләре белән әйтсәк, «Русиядә иң әлек ислах кылынган вә иң әлек мөгаллимәләр чыгара башлаган кызлар мәктәбе менә шушы Бубый кызлар мәктәбе» була.

Беренчеләрдән булып, «укытучы-мөгаллимә» таныклыгы Мөхлисә ханымга һәм кызлар мәдрәсәсенең башка мөгаллимәләренә тапшырылган. Таныклыклар, рәсми документ буларак, барлык административ оешмалар тарафыннан кабул ителергә тиеш була. 1908 елдан башлап Иж-Бубыйда мөгаллим һәм мөгаллимәләр өчен өч айлык җәйге курслар эшләп килә. Мәдрәсәне тәмамлаучыларга хөкүмәт тарафыннан рөхсәт ителгән мөгаллимлек һәм мөгаллимәлек таныклыклары тапшырыла башлый.

Иж-Бубый мәдрәсәсендә Россиянең төрле почмакларыннан,бигрәк тә Казан, Себер, Зайсан (Казахстан), Ташкент, Пржевальск, Бишкәк, Уфа, Бөгелмә, Касыйм, Төмән, Әстерхан һәм башка ерак җирләрдән килеп укучы хатын-кызлар күп булган. Кызлар тулай торакта яши, урын җитмәгәннәр авыл кешеләрендә фатирда тора. Мәдрәсәдә төрле яшьтәге хатыннар белем ала. Аналары белән бер үк вакытта кызлары да укырга килә. Имчәк балалары белән килгән хатыннарны да укырга кабул итәләр.

МӘДРӘСӘНЕҢ ҖИМЕРЕЛҮЕ

1905–1907 еллар революциясеннән соң хакимият революция елларында киң җәелеш тапкан, ләкин рәсми оешмаларның рөхсәтеннән башка гына ачылган җәдид мәктәпләрен ябу эшенә тотынган (мондый мәктәпләрне оештырып җибәргән мөгаллим-мөгаллимәләрнең үзләренең дә күп очракта яраклы документлары булмый). Бу эшне патша хакимияте Иж-Бубый белем учагын җимерүдән башлаган: 1911 елның 30 гыйнварына каршы төндә Иж-Бубыйга йөзләгән атлы стражникны ияртеп жандарм ротмистры Будогоский килә. Бубый мәгариф учагын тар-мар итү өч көнгә сузыла. Ирләр мәктәп-мәдрәсәләре ябыла, барлык мөгаллимнәр һәм Гобәйдулла белән Габдулла Бубыйлар кулга алына, Сарапул төрмәсенә җибәрелә. Уңышлы эшләп килгән Бубыйлар гаиләсе тормышында фаҗигале чор башлана. Мөхлисә ханым җитәкләгән мөгаллимәләр мәдрәсәдә кызларны укытуны туктатмый. Ниһаять, 1912 елның 18 гыйнварында Бубый

кызлар мәктәбе дә Вятка губернасы халык мәктәпләре директоры карары белән ябыла. Мөхлисә Троицк шәһәренә күчеп китә һәм анда 1910 елда Җәмгыятелхәйрия тарафыннан ачылган Габдрахман Әхмәровлар карамагындагы «Сөембикә» хатын-кызлар мәктәбен җитәкли. Бер үк вакытта 1913 елдан хатын-кызлар гимназиясендә дин гыйлеме укыта. 1914 елда сәүдәгәр Яушевларның матди ярдәме белән хатын-кызлар мәдрәсәсе, 1915 елда мөгаллимәләр семинариясен ачуга ирешә. Мөхлисә Бубыйның тормышы 1917 елда тагын бер тапкыр кискен үзгәреш ала. Бу үзгәреш, әлбәттә, илдә башланган үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнештә була. Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (Мәскәү, 1–10 май, 1917 ел) ул Мөселманнар Диния нәзарәте әгъзасы һәм казыя итеп сайлана.

БЕРЕНЧЕ ХАТЫН-КЫЗ КАЗЫЯ

Мөхлисә Бубый, 1917 елның җәендә гомеренең Троицк чорын тәмамлап, Уфага күчеНә. Мөхлисә ханым шөһрәтле дин белгечләре мөфтиләр Галимҗан Баруди һәм Ризаэддин Фәхреддин җитәкчелегендә хатын-кызлар арасында зур оештыру, аңлату эшләре алып бара. Ул 20 ел дәвамында (1917–1937) Диния нәзарәтенең гаилә эшләре бүлеге белән җитәкчелек итә, метрика кенәгәләрен тутыру, гаилә мөнәсәбәтләрен җайга салу, ислам диненә дәгъватлау һ.б. эшләр белән шөгыльләнә.

Мөхлисә Бубый шулай ук хатын-кызлар арасында мәгърифәтчелек эшчәнлеген алып бара, «Өлфәт», «Әхбар», «Вакыт» газеталарында, «Сөембикә», «Ислам мәҗәлләсе» журналларына мәкаләләр яза, аларда хатын-кызларның вазыйфалары, гаиләдә һәм җәмгыятьтә тоткан урыны яктыртыла, телне, милли һәм дини традицияләрне саклау хатын-кызларның төп бурычы буларак бәяләнә. Күренекле авылдашыбыз 20 ел дәвамында (1917–1937) Русия мөселманнарының Дини идарәсе әгъзасы, ислам тарихында бүгенге көнгә кадәр бердәнбер хатын-кыз казыя, ягъни шәригать кануннарына таянып эш йөртүче хөкемдар булып тора.

XX гасырның 20–30 нчы елларында татар зыялыларына кагылган әзәрлекләүләр Дини идарәдә хезмәтен дәвам иткән өлкән яшьтәге Мөхлисә ханымны да читләтеп үтмәгән. Ул 1930 елның 21 сентябрендә беренче мәртәбә НКВД органнары тикшерүчеләре каршына килеп баскан. Бу көнне аны, Җинаять кодексының 59 нчы маддәсе буенча, алтын акча һәм кыйммәтле әйберләрне законсыз саклауда гаепләп, сорау алуга тартканнар. Мөхлисә ханымның Мәккәгә хаҗ кылу ниятеннән җыеп килгән барлык «байлыгы» тартып алынган. Шулай да бу юлы ул үзе иректә калган.

1937 елның 20 ноябрендә Мөхлисә Бубый «Башкортостанның контрреволюцион милләтчеләр оешмасында» катнашуда гаепләнеп кулга алына. Егерме елдан артык гомерен Русия мөслимәләре арасында мәгърифәт таратуга багышлаган сәләтле педагог, тагын шул кадәр үк вакыт Русия мөселманнарының Үзәк дини идарәсендә эшләгән абруйлы казыя Мөхлисә Буби 1937 елның 30 ноябрендә Башкортостан АССР НКВДсы «өчлеге» утырышында «Башкортостанның контрреволюцион милләтчеләр оешмасында» катнашуда гаепләнә һәм үлемгә хөкем ителә. 68 яшьлек Мөхлисә абыстайны һәм аның белән тагын алты мөселман руханиен 1937 елның 23 декабрендә атканнар. Башкортостан АССР Югары суды президиумының 1960 ел 23 май карары белән аларның барысы да гаепсез дип табылган һәм акланган.

Мөхлисә ханым – үзенең фидакарь хезмәтен халкына, аны агартуга багышлаган шәхес. Гомумән, чынбарлык Бубыйлар гаиләсенә, илгә нинди генә сынаулар алып килсә дә, Мөхлисә ханым төшенкелеккә бирелмәгән, яшьлегендә сайланган юлдан тайпылмаган, соңгы сулышына кадәр бөек максатына тугры булып калган. Без Мөхлисә ханым кебек шәхесләр алдында, аларның якты истәлеге алдында баш иябез.

БАЛАЛАРЫ

Кызы М ө н җ и я Мөхлисә Бубый һәм мулла Җәлалетдин Әхмәтҗанов никахыннан туа. Мөнҗия Бубый әнисе җитәкләгән кызлар мәдрәсәсендә укый, соңыннан Троицк шәһәрендә шулай ук мөгаллимлек итә. Әмма Троицк чорыннан соң язмышы билгесез.

Казан (Идел буе) федераль университетының Н.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә Мөнҗия Бубыйның «шәхси эше» саклана. Анда аның 1920 елның 28 маенда өлкәннәр өчен I Уфа хезмәт Татар мәктәбенең ике баскычлы мәктәп курсын тәмамлавы турында язу бар. Таныклык югары уку йортына тапшыру өчен бирелгән була. Шулай ук 1920 елның 29 июнендә Казан университеты ректоры исеменә медицина факультетына керү үтенече белән язылган гаризасы да бар, ләкин «за неимением адреса» формулировкасы белән кире кагыла. Димәк, Уфада Мөхлисә Бубый Диния нәзарәтендә эшләгән вакытны, 1920 елларны ул әнисе янында була. Габдулла Бубыйның кызы Ситдика Бубый хатирәләреннән карасаң, Мөнҗия Бубый 1925–1926 елларда якты дөньядан киткән.

Үз кызы итеп үстергән – Б и г а ш е в а Н а җ и я Дәүләт кызы Минзәлә өязенең

Табанлы күл авылында туган. Анасы баладан үлгәч, Мөхлисә Бубый тәрбиягә ала. 1910 елда Бубый мәдрәсәсен тәмамлый. Шул ук елны Юнә карьясенә мөгаллимә булып җибәрелә, аннан соң Стәрлетамак шәһәрендә бераз укытып ала, 1912 елда Бубыйга кайтып, кызлар мәдрәсәсенә укытырга керә һәм, шул ук елны кияүгә чыгып, Мордыбый кызлар мәктәбендә мөгаллимә булып укыта башлый. Революцияне, совет властен хуплап каршы ала. Ире Кыям Бигашев 1926–1929 елларда Гобәйдулла Бубыйлар белән бергә Үзбәкстанда Коканд һәм Күнә-Үргәнеч дигән шәһәрләрдә укытучылык итә. Ул вакыт мулла-мөәзиннәрне эзәрлекләүләр башланган чор, кулга алу куркынычы янаганга, Кыям Бигашевның гаиләсеннән аерым Урта Азиядә үк яшәве аңлашыла. Бу елларда Нәҗия Мордыбый һәм Кодаш авыллары мәктәпләрендә укытып йөри.

1930–1931 елларда Мордыбыйдагы өйләрен, хуҗалыкларын – барысын да колхозга тапшырып, гаилә белән, Мари Республикасында Параньга (Бәрәңге) авылына күчеп китеп, 7 еллык мәктәпкә һәм педучилище мәктәпләренә эшкә урнашалар. Автономияле республиканың бик актив, күзгә күренгән укытучылары дәрәҗәсенә ирешәләр.

1938 елның июль аенда ире кулга алына, сөргенгә җибәрелә. Бер хәбәрсез 18 ел үткәннән соң, 1956 елда гына аклана.

Нәҗия, 1939 елны Мари АССР Параньга авылында берүзе генә калгач, Каргалы авылына (Оренбург өлкәсе) килеп укыта башлый. Соңыннан Башкортостанның Стәрлетамак шәһәренә, улы Өлфәт янына, 1940 елны аның белән бергә Ташкентка, аннан тагын Сәмәркандка күчеп китә. Анда читтән торып пединститут тәмамлый, диплом алып зур мәгълүматлы педагог була. 1967 елдан үзенең төпчек улы Әнәс гаиләсенә – Навои шәһәренә (Үзбәкстан) күчеп яши. 73 яшендә шунда вафат була.

1 Иж-Бубый мәдрәсәсе.

2 Иж-Бубый авылында Мөхлисә Бубый хөрмәтенә куелган истәлек тактасы.

ТЕРКӘЛГӘНБЕЗ ДӘФТӘРЛӘРДӘ, ЯИСӘ МЕТРИКА ЯЗМАЛАРЫНДА ХАЛЫК ТАРИХЫ

Фотолар автордан алынды.

Эльмира Сәлахова

Кем генә булсак та, һәрбер кеше күңелендә тарихчы, беребез дә үткәнебезгә битараф түгел, кызыксыну ул һәр кешедә була торган табигый халәт. Үз төбәгең, үз нәселең, үз гаиләң турында тарихларда язылган язулар табу аерым ләззәт. Тарихи документларда атаклы кешеләр генә теркәлеп калмый шул, ә безнең барыбызның да үткәнен, тарихын теркәгән уникаль архив документлары – метрика кенәгәләре бар, алар аша без үз тарихыбызны торгыза алабыз.

МУЛЛА ТУТЫРГАН КЕНӘГӘ

Дөньяга аваз салу белән эти-әниебез безгә туу турында таныклык ала, аннан буй җитеп гаилә корабыз – никахлашу турындагы документлы булабыз, кайберләребезнең тормышында аерылышу дигән хәлләр дә булгалый, һәм инде кеше бакыйлыкка киткәч, аның вафаты хакындагы документ та барлыкка килә. Мәгълүм булганча, бу документлар дәүләт оешмаларында рәсмиләштерелә, ЗАГС органнары бу халәтләрне теркәп куя. Безнең бабайлар да андый документлар белән таныш булган. Русиядә 1828 елның сентябрь аенда мөселманнарны да рәсми документларда теркәү турында боерык чыга. 1829 елның башыннан ук инде беренче метрика кенәгәләре тутырыла башлый. Татарлар аны дәфтәр дип йөрткән. Шулай итеп, метрика дәфтәрләре 1918 елда ЗАГС органнары оештырылганчыга кадәр рәсми документ вазыйфасын үтәгән. Аннан соң аларның юридик көче югалса да, метрика язмаларын тутыручы мулла-мөәзиннәр бу эшне традиция буенча 1930 нчы елларга кадәр дәвам иткән. Әлеге кенәгәләрдә туучылар, никахлашучылар, талак һәм вафат булучылар теркәлгән. Беренче карашка, исемлектән генә торган дәфтәрләр бары тик статистик мәгълүмат кына бирә кебек тоела, әмма әлеге саннарны чагыштыру шул чорның демографик картинасын күзаллау мөмкинлеген бирә. Әмма мәхәлләнең метрика язмаларының барысын да тоташтан, тулысынча өйрәнеп чыккан очракта, шул җирлектә гомер иткән бабаларыбызның көндәлек тормышы, яшәү рәвеше, алар кичергән шатлык-кайгылар, аралашу даирәсе һәм башка күп кенә нәрсәләр нәкъ кинодагы сыман күз алдында җанлана. Алар үткән гомер юлыннан бергәләп атлыйсың кебек тоела башлый.

ӘЙ, ГОМЕР-ГОМЕР...

Татар авылларының барысында да диярлек мәчет булган, күп кенә авыллар исә ике, ә кайберләре дүрт яисә аннан да күбрәк мәчетле булган. Татар авылларының үсүе, күпләп мәчетләр салыну чоры XIX йөз ахыры – XX йөз башына туры килә. Никадәр мәчет булса, авылның шулкадәр мәхәлләсе булган. Һәр мәхәлләнең үз метрика дәфтәре тутырылган. Метрикаларда теркәлгән бала санын карасак, балалар күп туган, гаилә ишле булган. Әмма шул ук вакытта вафат булучыларны теркәү сәхифәсендә зур күпчелекне балалар тәшкил иткәнен күреп йөрәк әрни. Бер яшен дә тутырырга өлгермәгән сабыйлар да, яшүсмер чорына җитә алмаган төрле яшьтәге балалар да бик күп. Сабый чакта бала гомерен өзә торган йогышлы авыруларны җиңеп, исән калганнар, ягъни фән теле белән әйткәндә, «табигый сайланыш»ны уза алган балалар гына яшәп китә алган. Бала өчен яшүсмер чорына җитү зур авырлык белән үтә торган бер сынау юлы булган. Ул чордагы йогышлы авыруларның исәбе юк, кайбер эпидемия вакытларында бер көн эчендә берничә бала, яисә ике-өч көн эчендә гаиләнең бар баласы да вафат булган очракларны бу язмаларда күреп, гаиләнең нинди авыр кайгы кичергәнен чамаларга була. Медицинаның юк дәрәҗәсендә булуы, халык дәвасының йогышлы авыруларны җиңәрлек көче булмавын метрика язмаларының вафатлар сәхифәсе язмалары үз саннары, үз фактлары белән дәлилли. Вафат сәбәпләренә килгәндә, рожа, кызамык, үпкә, эч авыруы һ.б. Гомер озынлыгы ягыннан караганда, 55–60 яшендә вафат булучыларны теркәгәндә үлем сәбәбе итеп «картлык»тан дип язу үзе үк гомер озынлыгы хакында сөйли. Шулай да, озын-озак гомер итеп 90 нан узучылар да, 100 яшькә кадәр гомер итүчеләр дә бар, әмма алар бик аз, бары кайбер авыл тарихында гына була торган сирәк күренеш, барлык авыллар да моның белән аерылып тора алмый. Бала тапканнан соң булган ялкынсынулар, төрле авырулар хатын-кызның гомерен дә иртә өзгән очраклар, кызганычка, аз түгел.

ТАТАРНЫҢ ДА БАР ҮЗ ЭРДУГАНЫ

Метрика язмаларында теркәлгән исемнәр аеруча игътибарны җәлеп итә. Соңгы вакытта татарлар арасында яңа туган балаларга татарның борынгыдан килә торган матур элекке исемнәрен кушу күренеше барлыкка килде. Хәзер инде балалар бакчасы-мәктәпләрдә бер төркемдә, бер сыйныфта Камилә, Кәримә, Мәрьям, Әсма, Фатыйма, Гайшә, Сөләйман, Ислам, Кәрим һәм Самат һ.б.лар булу бигрәк күркәм күренеш. Элекке Трактор, Рафинад һ.б.лар буынын мон-



дый исемнәр алыштыруга бары сөенәсе генә кала. Метрика язмалары борынгыдан татарларда кулланыла торган матур исемнәрне саклый торган документ та ул. Казан татарлары арасында XIX – XX гасыр башында балаларга бары тик ислам белән бәйле мөселман исемнәре кушканнар. «Мөхәммәт-», «Әхмәд-», «Габдел-», «Миңле-» кебек алкушымча ялганып ясалган исемнәр күп. Мисал өчен, Мөхәммәдсафа, Әхмәдхуҗа, Габделсәлам, Миңлеәхмәд. Кызлар исеменә «Биби-», «Гөл-», «Миңле-» ялганып, Бибиәсма, Гөлмәрьям, Миңлегөл кебек матур исемнәр пәйда булган. Әстерханда яшәүче татарларда бу кушымчалар бераз башкарак: анда Хаҗисмәгыйль, Хаҗисолтан, хәтта кызлар исеменә дә «Хаҗи-» алкушымчасы ялганган. Әйтик, Хаҗиханым, Хаҗибибә кебек исемнәр очрый. Казан татарларында хатын-кызга карата кулланыла торган «ханым» сүзе анда кыз баланың исем компоненты буларак йөргән. Мисал өчен, Хаҗиханым. Элекке Әстерханның Хаҗитархан дип аталып йөргәнен исәпкә алсак, моңа тарихи аңлатма да таба алабыз. Аларда шулай ук Акбибә, Акгөлсем, Әминәхан, Бибихан һ.б. исемнәр ясый торган «Ак-» алкушымчалы, «-хан» кушымчалы хатын-кыз исемнәре дә бик популяр була.

Актаныш, Сарман, Минзәлә якларында бу чорда да борынгы төрки чордан ук сакланып килгән үзенчәлекле исемнәр кушканнар. Әйтик, Асылкош, Бәхетгәрәй, Гөлҗимеш, Гөлстан һ.б. Хәзерге Актаныш районына кергән Иске Кормаш авылы кешеләренең исемнәре шул як башка авыл кешеләре исемнәреннән үзләренең борынгылыгы, үзенчәлеге белән аерыла. Исемнәр үк бу авылның борынгы төркилек белән бәйле зур тарихы барлыгына ишарә ясый. Бу авылда зур нәсел биргән Әрдуан исемле кеше яшәгән. Мондый исем башка татар авылларында сирәк очрый, Әрдуан, Эрдуган, Иртуган – алар бер тамырдан булган борынгы исемнәр.

НИКАХЫҢ ӨЛГЕРСӘ...

Метрика язмаларындагы никах теркәү сәхифәләре дә халык яшәешенең кызыклы якларын ача. Безнең бабай-әбиләребез никахка бик акыллы караган. Әлбәттә, мәхәббәт мәхәббәт инде ул, әмма тормыш итү, ике кешенең, хәтта ки ике нәселнең кушылуы җаваплы адым. Татар җәмгыяте гомумән бу яктан әлеге мәсьәләгә демократик караган, кочләп кияүгә бирү юк дәрәҗәсендә, шулай да бу процессны акыллы контрольдә тота белгән. Диния нәзарәте кызларга 16 яшеннән кияүгә чыгарга рөхсәт бирсә дә, метрика язмалары кызларның нигездә 18 яшеннән башлап кына кияүгә чыгуларын күрсәтә, күчмәлелек чоры озаграк барган төбәкләрдә, ислам тәртипләре йомшаграк үтәлгән җирләрдә никахлар иртәрәк булса да, 16 яшьтән дә алдарак булмаган. Яше җитмәгән кызга никах укыган мулла үзенең Указын югалтырга мөмкин булган, бер имам да имтихан биреп алган урынын югалтырга теләмәгән, андый никахларны теркәмәгән. Аерым кешенең бу тәртипне бозуы, «законсыз» никах кылуы да татар җәмгыятенең тулы йөзен күрсәтми, бу – аерым кешеләрнең бозыклыгы, андый аерым очраклардан бер җәмгыять тә хали түгел. Ир кешеләргә дә никахка керү яше 80 яшь белән чикләнгән. Никах ике яктан да берәр «вәли вәкил», кыз ягыннан, кайбер очракта кияү ягыннан да икешәр «ризалык шаһидләре» хозурында рәсмиләштерелгән. Никах теркәү документына кызга бирелә торган мәһәр күләме, әйберләтә бирелсә,ниләр бирелгәне тәфсилләп язылган. Никах вакытында бирелгән мәһәр – ул киленнең мөлкәте, ул аны үзенең кирәк-ярагына тоткан. Суммасы илдәге икътисадый шартлар белән дә, гаиләләрнең мөлкәте белән дә, никахның әүвәлгесеме яисә кабат никахмы – шулардан бәйле булган, гомумән, сумма авыл кешеләре арасында урталыкта йөргән, ә шәһәрдәге байлар катламында бу бераз башкачарак булырга мөмкин. Никахлашу даирәсе дә кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә: теләсә кайдан теләсә кайсы авыл кызын киленлеккә алу дигән нәрсә юк, һәр авылның үз аралашу даирәсе булган. Ул авылларны карасаң, алар йә кайчандыр бер Җыенга (халыкта кулланылган территориаль бүленеш, бер Җыен берничә салаңы берләштергән) кергән, йә бу авыллар ара-

сында нәсел туганлыгы булган, кайвакытта ерак урнашкан булса да, кайчандыр бер-берсеннән аерылып чыгып, яңа авыл булдырган очракта да, үз нәсел тамырлары булган авыл белән туганлык җепләрен саклаганнар, кыз алу-бирешүне дәвам иткәннәр.

ТАТАРЛАРДА КҮПХАТЫНЛЫЛЫК БУЛГАНМЫ?

Урта Азия халыклары тарихында күренә торган күпхатынлылык татар җәмгыятендә булмаган. Җәмгыять бертөрле генә була алмый, аның катлаулары да төрле, димәк, халык та төрлечә яшәгән. Шәһәрдәге байлар катламы арасында берничә хатын (ислам дине буенча, тигез шартлар тудырылганда, 4 хатын алу рөхсәт ителә) тотучылар була, чөнки аның матди ягы да, бәлки, статусы да моңа мөмкинлек биргәндер. Әмма мондый катлам XIX – XX йөз башында татар җәмгыятенең бик кечкенә өлешен генә тәшкил иткәнен онытмаска кирәк. Берничә хатын тотучылар булган икән, алар бик аз. Әдәбиятта татар кызының иртә кияүгә бирелүе, ничәнчедер хатын булып карт кешегә баруы сурәтләнү бөтен татар җәмгыятендә шулай булган дигән сүз түгел әле. Әдәби әсәр бит ул, гайре табигый хәлне күрсәтеп, алай булырга тиеш түгел дигән тәрбия чарасын чагылдырган жанр. Аның максаты һәм бурычы да шул. Әлбәттә, татарларда да гаиләдә берничә хатын булган, әмма аның шулай булуга этәргән сәбәпләре бар. Беренче хатын озак вакыт бала таба алмаска яисә, озак авырып ятып, гаиләдәге вазыйфаларын үти алмаска мөмкин. Балаларын тәрбияли алмый башласа, мондый очракта мөселман хатыны, ислам тәртипләрен белгән хәлдә, иренә башка хатын алырга рөхсәт итә. Бу беркем өчен дә трагедия түгел, бу – шул чорның гадәти күренеше. Моннан тыш, абыйсы йә энесе вафат булып, гаиләсе ятим калганда, ир кеше бу тол хатынга өйләнә ала. Моны үзенә күрә татар җәмгыятендә социаль яклау күренеше дип кабул итәргә кирәк. Балалар белән тол калган хатын берүзе ир хезмәтеннән башка тормышны алып бара алмый, икенчедән, аның ятим балаларын чит кеше үзенеке итә алмый, ә туганы – бер каннан булган якыны ул балаларны какмаячак. Нәсел малын читкә җибәрмәү, аны бүлергә теләмәү дә мөһим роль уйнаган. Берничә хатын алу ир кешегә бары тик җаваплылык, бурыч кына өстәгән, ә моны хатын-кызны яклау дип кабул ителгән. Моннан ир откан мы, хатынмы – бу уйланырлык нәрсә. Татар җәмгыяте турында сүз алып барганда бу хәлләрне «күпхатынлылык» дип түгел, ә «икехатынлылык» дип бәяләү дөрес булыр иде. Ир кеше башка хатын алган икән инде, аның икедән дә артык хатын һәм ике хатыннан туган балалардан артык карау, тамакларын туйдырырлык матди мөмкинлеге булмый. Ул чордагы гади татар авылының, гади игенченең тормыш хәле «иркенләп» яшәргә мөмкинлек бирми.

ГАИЛӘДӘ КЕМ ОЛЫ: ИРМЕ, ӘЛЛӘ ХАТЫНМЫ?

Совет җәмгыятенән үк ир кеше хатыныннан берничә яшькә олы булырга тиеш дигән стреотип яшәп килә, бу хәзер бераз үзгәрсә дә, төп масса бу тәртипне саклый. Ә менә метрика язмаларында күп очракта ир кеше хатыныннан яшь булуы күренә. Моны ничек аңлатырга була соң? Бу чордагы тормыш шартларын, тарихта булган вакыйгаларны исәпкә алсак, бу бик җиңел аңлашыла. Беренчедән, югарыда сөйләнгән вакыйгалар, ягъни абыйсы вафатыннан соң аның хатынын үзенә алу, икенчедән, ул чордагы урта яшьтәге ир кешеләрнең күпләп кырылуы, шул ук сугышлар, хуҗалыктагы имгәнү һәм башка фаҗигаләрне исәпкә алсак, бу яшь аермасында да һәм шул ук гаиләдә берничә хатын алуда да роль уйнаган. Тагын бер мөһим момент та бар, яшь кызларны байлар алган, ә гади крестьян гаиләсе өчен кырда эшләрлек «җитешкән» киленнәр кирәк булган. Хатын-кыз бу чорда ир кеше белән тигез эшли торган эш көче, ә балалыктан да чыгып җитмәгән, эш рәтен дә җүнләп белмәгән яшь кыз гаилә өчен «артык кашык» кына булыр иде. 20-25 яшьләр арасында булган хатын-кызның инде тол булуы, ягъни ирләре вафат булып, кабат никахка керүләре метрика язмаларында бик еш күренә.

ҖИДЕ БАБАҢНЫ БЕЛ!

Метрика язмалары безнең һәрберебезнең нәсел тарихын өйрәнү өчен алыштыргысыз документ. Монда без бабаларыбызны, нәселебезнең һәрбер кешесен таба алабыз. Аларның исемнәрен бөртекләп җыю, аларның язмышын белү җанга рәхәтлек, горурлык хисе бирә торган гамәл. Татар-мөселманнарда «җиде буыныңны бел» дигән әйтем бар, ә үзен галим дип исәпләүчеләргә тугыз буын бабасына кадәр белү таләп ителә. Бу глобаль дөньяда нәсел дигән төшенчәне без аңлап бетермибез әле, совет чорында бу төшенчә бөтенләй юк иде. Әмма бу бик мөһим, чөнки мәгълүматның җиде буын дәвамында сакланып килүе, аның нәселдән тапшырылуы инде фәнни яктан да расланган факт, ә безнең бабайлар инде аларны белгән. Без үз гамәлләребез белән бабайлар рухы алдында имтихан тотабыз, шул ук вакытта ул безнең яшәешебездә дә мөһим роль уйный. Элек-электән юкка гына кешенең нәселенә игътибар итмәгәннәр, кешенең кайсы нәселдән булуына карап, аның турында фикер йөрткәннәр, кызларын да үзләре белгән, үзләре кабул иткән нәселгә генә биргәннәр. Хәзерге вакытта нәсел тарихы белән кызыксыну, бабайларның исемнәрен белү, аларның рухына дога кылу өчен архив документларыннан берәмләп эзләгән кешеләр булу бары сөенеч кенә, нәсел җепләре өзелергә тиеш түгел.

ИМИНЛЕК КЫСАЛАРЫНДА

КАЗАН ЭШКУАРЫ КУРКЫНЫЧ СЕРЛӘРНЕ АЧАРГА СӘЛӘТЛЕ СИСТЕМА УЙЛАП ТАПКАН

Бер төркем яшьләр Казан вузларының берсенең фойесына керә. Көлешә-көлешә, төрткәләшә-төрткәләшә алар бөтенесе бергә диярлек металл кыса аша үтә. Сак хезмәте мониторында студентларның фотосы, исемнәре һәм тән температурасы күрсәтелә.

Кинәт кыса хәвеф сигналы бирә һәм кызыл ут яна башлый.

– Көрән рюкзаклы егет, бирегә килегез әле, – дип ресепшеннан сакчы чыга. Егет теләр-теләмәс кенә кире борыла.

– Курткагызның эчке кесәсеннән бөтен нәрсәне алып күрсәтегез әле, – ди сакчы. Башка әйберләр белән бергә студент металл деталь дә чыгара. Ул егет үз кафедрасында җыя торган эксперименталь җиһазның бер кисәге икән. Сакчы кире үз урынына керә.

Кеше тәненең температурасын, аның янындагы металл предметларны һәм аларның урынын ерактан торып ачыкларга сәләтле мондый кысалар белән Казанның «Метаскан» компаниясе инде берничә ел буе бөтен Россияне диярлек тәэмин итә.

ХӘЗИНӘ ЭЗЛӘҮЧЕГӘ ЯРДӘМГӘ

Үз сыйфатламалары буенча тиңдәшсез «Метаскан» аркалы металл детекторларын ясау тарихы моннан 20 еллап элек башланган. Яшь галим Алексей Фоминых өермәле ток күренешләре – индуктив кәтүк тудырган токлар белән шөгыльләнә. Экспериментлар өчен юнәлешләрдән берсе әлеге кәтүкләр файдаланылган металл детекторлары үзлекләрен өйрәнү була. Фоминых сынаулар барышында шуны ачыклый: кәтүк кырының индукция үткәрүчәнлеге параметрын гына түгел, аның электр үткәрүчәнлеген дә тикшерүгә нигезләсәң, металл эзләгечнең күрсәткечләре күпкә төгәлрәккә әйләнә икән.

Казан уйлап табучысының ул вакытка инде беренче патентын алган эшләнмәсе республикада бик тиз таралып бетә. Тәүге заказчылар арасында хәзинә эзләүчеләр һәм металл ватыклары җыючылар була – 2004 елда моның белән шөгыльләнүчеләр саны кинәт арта. Шул рәвешле Алексей Фоминыхның югары төгәллектәге металл детекторлары төзү буенча проекты җитештерүгә әйләнә.

Хатыны Чулпан Юсупова белән Алексей Фоминых металл эзләгечләрне Россиянең барлык төбәкләренә тарата торган дилерлык челтәрен оештыра.

Бервакыт галимгә Татарстандагы файдалы казылма чыгаручы бер компания инженерлары мөрәҗәгать итә. Аларга тимер рудасының нинди тирәнлектә ятканын төгәл билгели һәм файдалы казылманың якынча күләмен ачыклау мөмкинлеге бирә торган әсбап кирәк була.

– Безнең диаметры 30 см лы кечкенә кәтүкле металл эзләгечләребез зур булмаган металл предметларны 30 см га кадәр тирәнлектә таба иде. Руда эзләү өчен тирәнлекне, димәк, кәтүк диаметрын арттыру таләп ителде. Без диаметры 80 см лы һәм сканерлау тирәнлеге 12–16 метрлы детекторлар эшләдек, – дип сөйли Алексей Фоминых.

Ул инженерларга руданың яту тирәнлеген һәм тимернең күләмен генә түгел, бәлки казылма чыганагының буеннан-буена тыгызлыгындагы бөтен үзгәрешләрне дә билгеләргә сәләтле җайланма тәкъдим итә. Мәгълүмат турыдан-ту-

Фото «Метаскан» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

Алексей Фоминых,
«Метаскан» компаниясе җитәкчесе

ры экранның детекторына чыгарыла. Яңа җайланмага ихтыяҗ зур булып чыга: иске коммуникацияләр – торба, кабель, электр челтәрләрен эзләү өчен коммуналь хуҗалык хезмәткәрләренә нәкъ менә шундый аппарат кирәк икән. Аерым заказлардан экренләп җитештерү үсә башлый. Алексей Фоминых грунттан металл эзләгечләрнең эш принцибын кысалы детекторларга күчергәч, ул тагын да киңәя.

ДИАГНОЗНЫ ДЕТЕКТОР КУЯЧАК

Бүген «Метаскан» детекторлары Татарстандагы гына түгел, бөтен илдәге мәктәпләрдә, судларда, спорт объектларында, Эчке эшләр министрлыгы һәм Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсе учреждениеләрендә, сәүдә үзәкләрендә куелган. Соңгы берничә елдагы бер генә зур чара да Алексей Фоминыхның аркалы детекторларыннан башка үтмәгән. Җитештерү башланганнан бирле компания 20 мең данәдән артыграк кыса саткан. Шундый башка җайланмалардан «Метаскан»ның аермасы шактый зур.

Әгәр башка детекторлар 10 нан 30 ваттка кадәр электр энергиясе сарыф итсә, «Метаскан» аппаратларына тапшыргычлары эшләсен өчен нибары 100 мВт җитә. Бу аларны файдалануда тагын да куркынычсызрак итә, шул исәптән кеше сәламәтлеге өчен дә һәм электр магнитлы яки радиодулкыннар чыгара торган башка җайланмалар өчен дә.

Казан кысаларының металл предметны табу төгәллеге ГОСТ таләп иткәннән югарырак. Детекторлар металл предмет алып керүчене 100% төгәллек белән генә ачыклап калмый, металлның төсләмe яки карамы икәнен, авырлыгын һәм кайда булуын да билгели, бу исә кысаның нинди дә булса киемгә яки аксессуарга реакциясе булган очракларда бик булыша.

Продукциясенең шактый өлешен «Метаскан» шәхси заказлар буенча чыгара. Күп төрле сыйфатламалар исәпкә алына: кысаның үтү киңлеге, авырлыгы, вандалларга каршы торучанлык үзлекләре, эшләү температурасы, күчереп йөртелә торган һәм ерактан торып идарә ителә торган пультлар булуы. Пандемиягә бәйле рәвештә компания аркалы металл эзләгечләрне тепловизорлар белән җиһазлаган. Әгәр үзе аша үтүче кешенең тән температурасы нормадан артык икән, кыса кисәтү сигналы бирә. Моннан тыш, детекторны йөзләрне таный һәм биттә битлек барлыгын-юклыгын билгели торган ясалма интеллект модуле белән җиһазларга була. «Метаскан» сканерларының тиңдәшсез характеристикасы – кыса аша берьюлы бик күп кеше үткәндә дә һәркайсын тануы һәм параметрларын теркәве. Сак хезмәте температуралы кешене учреждениегә кертмәскә мөмкин. Барлык мәгълүмат кирәк булган очракта учреждениенең иминлек системасына тапшырыла ала.

«Метаскан» аппаратларын корпустан алып тапшыргычларга кадәр җитештерүнең тулы циклы Казанда башкарыла. Компонентларның 80%тан артыгы – үзебезнең илнеке. Болар барысы да компаниягә базар ихтыяҗларына тиз арада яраклашу мөмкинлеген бирә.

– Безнең мөмкинлекләрнең диапазоны киң. Мәсәлән, аркалы детекторларның модификацияләрен без сәнәгать объектлары өчен җитештерәбез – үзагачны пуля яки пычкы эзләрен табу өчен сканерлау яки пластик эшләнмәләр җитештерүендә шөрепләр экструдерга эләкмәсен өчен, – ди Алексей Фоминых. – «Метаскан» технологик прогресстан калышмый. Без, тагын да төгәлрәк һәм кулланучы өчен уңайлырак продукция җитештереп, даими камилләшәбез.

METASCAN
metascan-md.com
тел. 8 800 444-00-27
info@metascan-md.com
grunt. metascan-md.com

ТАТАРСТАН АВЫЛЛАРЫ

ТАТАРЛАР ЯШИ ТОРГАН КАЗАКЛАР

Фото: Александр Ефремов

КАЗАКЛАР

Бездә әллә нинди үзенчәлекле исемле авыллар бар. Сәер яңгырашлылары да җитәрлек. Биектау районында урнашкан Казаклар авылы беренчесенә керәдер. Бер казак та яшәмәгән салага ни өчен мондый исем биргәннәр соң?

Руфия Фазылова

100 ЕЛЛЫК БИНА

Казаклар зур авыл. Олы юлдан килгәндә, чакрымга җәелгән саланы күреп аласың. Тау астына урнашкан ул, шуңа да авыл уч төбендәге кебек күренә. Әнә шулай хозурланып Казакларга кереп барганда, юл өстендә агач бинаны күреп алдык. Тик без аны һич кенә дә мәктәп дип уйламадык, шуңа да узып киткәнбез. Урамда туктап, кешеләрдән сорашып, кире киттек, чөнки безне мәктәптә көтәләр иде.

Өстәп-өстәп салынган агач бина янына туктадык да, эчкә уздык. Юан бүрәнәләргә куелган пластик тәрәзәләр бинага ремонт ясалганлыгы турында сөйли. Күзгә ташланган тагын бер әйбер – өч метрлы агач ишекләр булды. Хәтерлим, безнең авылда да иске мәктәп бинасы бар иде. Дөрес, анда дәресләр алып барылмады, чөнки яңа белем бирү йорты төзелде. Ә без, балалар, нәкъ менә иске мәктәпкә керергә атлыгып тордык. Маҗаралы кинолардагыча, аннан берәр җан иясе чыгар төсле иде. Казаклар мәктәбенә аяк баскач, әнә шул хатирәләр яңарды – тын да алмый тирә-якны күзәттем. Әллә ничә кат буялган ишекләр, киң такталы агач идәннәр – барысы да балачакка алып кайтты...

Казаклар мәктәбендә бүген унөч бала белем ала. Икенче, бишенче сыйныфлар бөтенләй юк. Тугызынчыда бер бала, яңа уку елына янә бер бала керәчәк, ягъни мәктәптә укучы саны үзгәрми. Иң күп балалы сыйныф – өченчеләр, анда дүрт бала икән.

– Укыганда, әлбәттә, балаларга күңелсезрәк инде, – ди Казаклар төп белем бирү мәктәбе директоры Госман Исхаков. – Конкуренция дә юк, ягъни укучы үзенең чын белем дәрәҗәсен башкалар белән чагыштырып карый алмый. Мин аларны кызганып та куям. Кырык биш минут буе укытучы сиңа гына карап торсын әле.

1

– Белем йортыбыз ябылмасын өчен бөтен күңелне биреп эшлибез, – диде Госман Исхаков.

2

– Казакларга 1983 елда килдем, ул вакытта мәктәптә 127 укучы бар иде, – дип сүзгә кушылды математика укытучысы Зөлфирә Саттарова.

Мисал өчен, без утыз өч бала укыдык. Бер дәрестә җавап бирсәң, аннан атна буе ял итә идек. Ә монда һәр көн, дәрес саен җавап бирергә кирәк. Шулай булгач, укучы дәрескә әзерләнмичә килә алмый. Монысы инде сыйныфта бер бала гына булуның уңай ягы – бөтен игътибар үзенә генә.

Госман Рамил улы үзе дә кайчандыр шушы мәктәптә белем алган. Ул чакта әлеге зур булмаган бинада 250 бала укыган. Хәтта ул кайчандыр 300 баланы да сыйдырган – биш чакрым ераклыктагы Матмыр авылы малай-кызлары да бирегә килгән. Алар өчен махсус интернат та булган.

– 1985 елдан бирле әлеге мәктәптә эшлим, – дип сүзен дәвам итте директор. – Ул вакытта бала саны йөз тирәсе иде. Безнең авыл район үзәгеннән ерак. Колхоз бай булмады, шуңа да яшьләр авылдан китү ягын карады. Авыл аша аккан Ашыт елгасы һәр яз саен күперләрне су астында калдыра иде. Ул чорда язын көймә белән йөреш иде. Юллар юк. Күп ата-ана баласын үзләре үк читкә куып җибәрде. Минем дә эти-әни авылда калуымны теләмәде, тик ни генә дисәләр дә, шәһәр тормышын яратмадым. Артка борылып карыйм да, бер генә дә үкенмим. Туган авылыңнан аерылмый яшәү олы бәхет ул. Өстәвенә, яраткан эшем, гаиләм бар. Бүген җәннәттә яшибез, газы, суы кергән, менә дигән юллар...

– Казакларга 1983 елда килдем, ул вакытта мәктәптә 127 укучы бар иде, – дип сүзгә кушылды математика укытучысы Зөлфирә Газиз кызы Саттарова – Шул елны КДПИның физика-математика факультетын тәмамладым. Юллама белән монда җибәрделәр. Дөресен генә әйткәндә, бер-ике ел эшлим дә, аннан китәрмен дигән ният белән килдем. Биектау районының Яңавыл авылыннан мин. Безнең яклар белән чагыштырганда, ул чакта Казаклар шактый караңгы авыл кебек тоелды. Иң начары – юл юк иде. Ашыйсы ризыкларым биредә булган икән. Казаклар егетенә кияүгә чыгып, монда төпләнеп калдым. Йорт салып, балалар үстереп, матур гына яшәп ятабыз, Аллага шөкер.

Казаклар мәктәбендә Мөдәррис Идрисов исемен берничә тапкыр телгә алдылар. Бактың исә, үзе укыган белем йортына аның ярдәме бик зур булган. Янкорма салдыру, мәктәп коридорына плитка җәйдерү, укытучылар бүлмәсен, музейны ремонтлау – барысы да шул эшкуарның хезмәте икән. Гомумән, Казакларда авылын яратучы кешеләр җитәрлек. Хәтта читтә яшәп, авылга күченеп кайткан кешеләр дә, мәктәп эшләсен, дип тырыша. 1953 елда шушы белем йортын тәмамлап, аннан Мәскәүдә гомер иткән Әнисә Вәлиева, берничә ел элек туган авылына күченеп кайта. Казаклар мәктәбенең иске, ватык тәрәзәләрен күреп, улы Рахманга мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә, ананың игелекле улы мәктәпкә пластик тәрәзәләр куйдыра.

– Белем йортыбыз ябылмасын өчен бөтен күңелне биреп эшлибез, – диде Госман Рамил улы. – Авыл өчен мәктәпнең ни дәрәҗәдә кирәк икәнен аңлатып торасы түгел. Без монда бер гаилә. Һәр балабыз өчен янып торабыз. Укытучылар коллективы тәҗрибәле, көчле. Безнең мәктәпне районда да яхшы беләләр, чөнки укучыларыбызның уңышлары зур.

Чыннан да, Казаклар мәктәбендә гаилә җылысы бар. Ә балаларның күзләре янып тора. Шәһәр мәктәпләрендәге кебек укытучыларга исем, әтисенең исеме белән эндәшү юк биредә. Мөгаллимнәр биредә «апа», «абый». Үз итеп, якын итеп эндәшү...

3
Кәлимуллиннар Казакларга егерме ел элек Ташкенттан күченеп кайта.

КҮП БАЛАЛЫ ГАИЛӘ

Сизгәнегез бармы, читтән кайткан гаиләне җирле халык башта инә күзеннән үткәрә. Кабул итәргәме, юкмы икән дип тикшерә. Казакларга да егерме ел элек Ташкенттан Кәлимуллиннар гаиләсе күченеп кайта. Иске генә бер йорт алалар, шуны төзекләндерә башлыйлар. Авыл кешеләрен шаккатырган нәрсә хуҗабикә Минзиннәт апаның бакчасы була. Ни генә үстерми ул!

Бүген әлеге нигездә сигез кеше гомер итә. Минзиннәт апаның төпчек улы Марат, килене Лилия һәм аларның биш баласы. Гаиләгә аяк баскач та аңлашылды – бу йортта дин кануннары буенча яшиләр.

– Мәрхүм ирем белән дүрт бала үстердек, – диде Минзиннәт апа. – Әле дә йөрәк ярасы төзәлми – 1967 елгы улымны хәрби хезмәткә киткән җиреннән табутта алып кайттылар. 1986 ел иде ул. Тугыз ай су асты корабында хезмәт итте. Әле ярый төпчек улыбыз Марат булган, картлык көнемдә кем белән яшәр идем, дим.

Минзиннәт апаның әти-әниләре Нурлат ягыннан. Совет заманында бәхет эзләп башта Чиләбегә киткәннәр. Минзиннәт апа шунда туган. Кызга биш яшь чагында Үзбәкстанга күченгәннәр. Шунда төпләнеп тә калганнар.

– Ташкентта укыдым, аннан заводта эшләдем, лаеклы ялга да шуннан чыктым, – диде Минзиннәт апа. – Үзбәкстанда яшәгән чакта туганнарга Нурлат районына кайтып йөрдек. Ирем исә Ульяновск ягыннан иде.

– Казакларга ничек килеп чыктыгыз? – дим.

– Сеңлемнең улы монда килеп урнашкан иде. Татарстанга күченеп кайтырга ниятләгәч, Казакларны килеп күрдек. Авылны ошаттык. Тиз арада Ташкенттагы бер дигән йортыбызны, ихаталарны арзан бәягә сатып, монда кайтып киттек.

– Ә ни өчен гомер иткән Ташкентны калдырдыгыз?

– Кызым Кама Тамагы районы егетенә кияүгә чыкты. Бер җәйдә Марат апаларына кунакка кайткан иде. Шуннан безгә шалтырата бу: «Әни, минем башка Ташкентка кайтасым килми, монда калам», – диде. Ул вакытта Маратка уналты гына яшь иде. Үсмер баланы ничек итеп үзен генә калдырасың? Әнә шулай ирем белән тиз генә хәл иттек тә ата-бабаларыбыз җиренә кайтып киттек. Бер дә үкенмим, Татарстан яшәр өчен бик уңайлы. Бер генә үкенеч – ирем монда кайткач алты ел гына яшәп калды... Шушы зур йортта оныклар янәшәсендә бергә-бергә ничек күңелле яшәр идек дим.

Марат белән күрешеп булмады, ә менә Лилия өйдә иде. Биш баласын киендереп, безне чәй табыны белән каршы алды ул.

– Марат белән 2006 елда гаилә кордык, – диде күп балалы ана. – Мин дә читтә – Казахстанда туган бала. Аннан Самарада яшәдек. Инде үсмер чакта Биектау районына күчендек. Марат белән без ерак кодалар булып чыгабыз. Унсигез яшемдә аңа кияүгә чыктым. Хәләл көчебез белән шулай йорт җиткердек. Бер-бер артлы балалар туды. Иң олы улыбызга үндүрт, иң кече кызыбызга өч яшь.

– И, Лилияне без барыбыз да яраттык, – дип сүзгә кушылды Минзиннәт апа. – Гаиләләрен дә яхшы беләбез, бик ипле кешеләр. Марат өйләнәм дигәч, шулкадәр сөендем инде. Мондый килен Аллаһы Тәгалә бүләге. (Минзиннәт апа күз яшьләрен сөртте. – Авт.) Унбиш ел бер түбә астында яшибез. «Эх», – дип тә әйткәннәре

4
Гүзәл Адбулхаева тукымадан курчаклар, төрле йорт хайваннары, ерткыч җанварлар тегә.

юк. Марат та шулай. Минем белән киңәшләшмичә йортта кадак та какмыйлар. Оныклар турында сүз дә юк, берсенә эндәшсәм, барысы да йөгереп килә.

Элек бер түбә астында ничек яшәгәннәр икән дип кайчак гаҗәпләнәбез. Олыларга ихтирам – Кәлимуллиннар гаиләсендә иң беренче әнә шул күзгә ташланды.

КУРЧАК ТЕГҮ ОСТАСЫ

Казакларда 337 кеше яши, 274 хуҗалык бар. Авылда ике зур эшмәкәр исәпләнә. Берсе колбаса, ит ризыклары ясый, икенчесе күпләп мөгезле эре терлек тота. Төрле чаралар үткәргәндә ярдәм итәләр икән. Тик аерым сәбәпләр аркасында, фермерлар белән күрешеп булмады. Аның каравы Казаклар мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алсу Минһаҗева безне үзенчәлекле бер ханым янына алып барды. Гүзәл Адбулхаева тукымадан курчаклар, төрле йорт хайваннары, ерткыч җанварлар тегә.

– Казан кызы мин, – диде ул. – Гомер буе шунда яшәдем. Сату-алу өлкәсендә эшләдем. Тик күңелем белән гел иҗат эшенә тартылдым. Шуңа да буш вакыт булган саен кул эшләрен өйрәнә идем. Беренче уенчыкны сеңлемә ясап бирдем. Ул миннән ундүрт яшькә кече. Шулай берсендә кайтты да: «Хезмәт дәресенә курчак тегеп килергә кирәк», – ди. Бер дә авырсынмыйча, кулга тукымалар алып, эшкә керештем. Шактый матур килеп чыкты. Мәктәптә укытучы да яраткан. Әле миңа бер китап та биреп җибәргән иде: «Шуннан карап өйрәнсен», – дигән. Тора-бара андый китаплар күбәйде.

Гүзәл апа гаҗәп кеше – ул барлык ясаган уенчыкларын дус, танышларына бүләк итә. Яңа ел алдыннан гына да егермеләп уенчык ясаган. Һәм аларның барысын да бүләккә таратып бетергән! Шуңа да өендә берничә генә уенчык бар.

– Заказга эшлисезме? – дим.

– Соңгы вакытта эшли башладым дияргә буладыр. Кешеләр берсеннән берсе күреп ясата. Аның инде бәясе кыйммәт түгел. Бик көчләп акча биргәч, ярар, чималга булса да ярар, дип алдым. Дөресен генә әйткәндә, өйдә инде юньле тукымалар да калмады. Гел ясагач, күп кирәк бит.

Безгә дә Гүзәл апа тиз генә аю баласы ясап күрсәтте. Биш минут дигәндә тукыманы кисеп, тегү машинасы янына килеп утырды. Чынлап торып утырса, бер уенчыкка бер сәгать вакыт җитә икән.

– Курчак катлаулырак булган саен, вакыт та күбрәк кирәк, – диде оста.

Гүзәл апаны Казакларга язмыш алып килә. Гомер иткән ире вафат булгач, ул дүрт ел ел ялгыз яши. (Ике улы да гаиләле.) Шуннан очраклы рәвештә Мулланур абый белән таныша. Ир телефон аша Казаклар авылында яшәвен, гомер иткән хатынының вафат булуын сөйли. Һәм очрашырга сүз куешалар.

– Беренче ирем вафат булгач, янә кияүгә чыгармын дип һич уйламаган идем, – диде Гүзәл апа. – Язмыштыр инде. Минә Казакларга килгәнгә дә дүрт ел булды. Авыл халкы белән уртак телне тиз таптык. Күршеләр белән бик тату яшибез. Җәен күп итеп чәчәкләр үстерәм, төрле фигуралар ясыйм. Тормыш дәвам итә, алга карап яшәргә кирәк. Мулланур да, мин дә мәрхүм җәмәгатьләребезне гел искә алабыз. Аларга багышлап көн дә дога кылам...

Авылның иң озак яшәүче парлары – Сафиннар гаиләсенә дә кердек. Хәбибрахман абый белән Гакыйлә апа алтмыш җиде ел бергә гомер итәләр. Биш бала дөньяга китергәннәр, ни кызганыч, бүгенге көндә өчесе генә исән икән. Оныкларның балаларын да күрү бәхетенә ирешкәннәр.

– Малай китсә, кыз кайта, үзебезне генә калдырмыйлар, рәхмәт яусын, – диде Гакыйлә апа. – Яшь бар бит. Бабайга узган ел туксан тулды, миңа сиксән сигез яшь.

...Казакларның зур сөенече – авылга заманча Мәдәният йорты салып куйганнар. Шунда ук бик зур мәчет тә балкып тора. Кешеләре нурлы булгангамы, авылның һәр шундый социаль объекты көлеп тора кебек тоелды.

Кайбер авыллардан: «Тагын бер килергә кирәк әле», – дип кайтыла. Көне буе йөрсәң дә, җитми кала. Казакларга да тагын бер бару нияте калды, чөнки яраттык...

5 Авылга заманча Мәдәният йорты салып куйганнар.

6 Гакыйлә һәм Хәбибрахман Сафиннар алтмыш җиде ел бергә гомер итәләр.

Хәбибрахман абый көрәшче нәселеннән. Уллары да үзләре кебек көрәшкән. Гомер буе колхозда эшләгән – ат җигүдән башлап, зоотехник, ферма мөдиренә кадәр булган. Гакыйлә апа да фермада хезмәт куйган.

– Әни туксан алты яшенә кадәр яшәде, бер йортта гомер иттек, – диде Хәбибрахман абый. – Без эшкә чыгып киттек, балаларны ул үстерде. Әни бик егәрле карчык иде. Безнең нәсел таза, әле мин аның яшенә җитәм, Алла боерса. Әбине дә тартам, – дип кеткелдәде бабай.

Җитмеш елга якын бергә гомер иткән бу парны күзәтү бик рәхәт! Гакыйлә апаның аяклары авырта икән. Шуңа да Хәбибрахман абый гел карчыгы тирәсендә йөрде. «Тигез яшәүнең сере?» – дип сорау биреп аптыратмадым, күренеп тора – бер-береңә өчен янып, борчылып яшәү, гаилә бәхете шул инде.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Галия Сабирҗанова, Казаклар төп белем бирү мәктәбенең тарих, җәмгыять белеме укытучысы:

– Авыл тарихын төрле чыганаклардан өйрәнеп карадык. Элеккеге документларда Казакларның Уразлы атамасы очрый. Урәз бәк җирләре булмадымы икән дип тә уйлыйбыз. Бу җирләрдә йомышлы татарлар яшәгән. Аларга ул хезмәтләре өчен бирелгәндер дигән дә фараз бар.

Казаклар зиратында ике борынгы кабер ташы бар. Анда мәрсияләр, ягъни язулар чокып язылган. Күп еллар аны халык укый алмаган. Менә безгә шул ташларны укып бирделәр. Унсигезенче гасырда яшәгән Исхак бине Габделкәрим язулары булып чыкты. Димәк, ул чорда биредә кешеләр яшәгән. Казан ханлыгын Явыз Иван басып алганнан соң, татарлар Әлдермеш, Дөбъяз якларына килеп урнашкан. Соңрак алар бу җирләргә дә күченеп утырырга бик мөмкин. Һәрхәлдә, тарихчыларга ияреп, без шундый фикердә торабыз.

– Бүген электрон сәүдә перспективалы юнәлеш санала. 2021 ел эчендә маркетплейсларда Татарстан эшкуарларының саны 7 тапкырга артты, – дип сөйләде Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов хатын-кызлар – федераль һәм республика ММЧ вәкилләре белән Халыкара хатын-кызлар бәйрәме алдыннан үткәрелә торган традицион очрашуда.

ТАТАРСТАН БИЗНЕСЫ МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

Очрашу алдыннан журналистлар Татарстанда Ozon логистика комплексында булды һәм Татарстан бизнесының маркетплейсларда ничек үсә барганын үз күзләре белән күрде. Бу турыда тулырак басмабызның киләсе санында.



Фото: Александр Эшкинин



Татарстанның ханым һәм туташлары «Татарстан» тышлыгын бизәсен!

ММЧ вәкилләренең Татарстан Президенты белән очрашуын «Татарстан хатын-кызлары «Татарстан» тышлыкларында» күргәзмәсе каршы алды.

Фотода Татарстан Президенты матбугат үзәге җитәкчесе Лилия Галимова һәм ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов.

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама